КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№9 (136)
27 февраль
1998 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык гәзит

Бүгенге санда:

2 **Роберт МИҢНУЛЛИН.** "ТР гражданлыгы турында" закон проектын кайбер матбугат органнары карачкы кебек итеп бөтен Татарстан халкын куркытмакчы булалар.

6 **Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.** Узган ел Вахитов районының эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре Татарстан халык депутаты Фәнәвил Шәймәрдановны кыйнап, зират янына илтеп ташлаганнар иде.

8 **Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ.** Читтә яшәгән милләттәшләребез Гаяз Исхакыйның бөеклегенә, гаять нәтиҗәле һәм күпкырлы эшчәнлегенә, милли-азатлык хәрәкәтенең дөнья күләм танылган лидеры булуына басым ясыйлар.

13 **Гүзәлия ШӘЙГӘРДАНОВА.** Ананың үзенчәлекле догасы булган бишек җыры иң изге теләкләрне чагылдыра, белем һәм тәрбия бирү көченә ия.

Аксакаллар биргән фатихага
Яши алсак иде йөз төбәп...

Мөхәррир мөнбәре

Өченче меңъеллыкка кереп барганда, татар кайдан килеп чыккан, дип бәхәс куерту үзе үк бәхәсле һәм, әйтергә кирәк, зыянлы бер гамәлгә әйләнде бугай. Әйтик, галим-голәманың бу мәсьәләне матбугатка да өстерәп кертеп сүз көрәштерүе халыкны берләштерүгә түгел, киресенчә, аны таркатуга күбрәк хезмәт итмиме икән? Шулай ук үз сүзеңне өстен итәр өчен бәхәскә Ш. Мәрҗани, Г. Исхакый кебек мәшһүрләрне катнаштыру да әхлак кысаларына сыешып бетми шикелле. Алайга китсә, бөекләрдән һәр очрак өчен үзеңә кулай фикерне табып була. Ә инде уеңны-вөҗүдеңне бәхәс комарлыгы биләп алганда, элгәреләребез төзеп калдырган Тартария карта-харитасына ешрак багарга кирәктер...

Газинур МОРАТ

Мин әйттем

Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе

Мәче койрыгына кыңгырауны кем тагар?



Гражданлык турындагы закон турыдан-туры "Җир кодексы" белән дә, "Дәүләт хезмәте турында"гы закон белән дә бәйләнгән. Озакламый сайлаулар кампаниясе башланачак. Качаклар мәсьәләсе, аларны эшкә урнаштыру проблемалары, Татарстан егетләренең Русия армиясендә хезмәт итү тәртибе, чит илләрдән килеп эшләүчеләр, кибетләр, супермаркетлар тотучылар... Боларның берсен дә Ватандашлык турындагы законнан башка хәл итеп булмаячак.

Бу мәсьәләләрнең һәммәсе дә гаять дәрәҗәдә җитди, әһәмиятле, катлаулы һәм шуңа күрә дә бәхәсләр уята торган. "Татарстан Республикасы гражданлыгы турында"гы закон проекты да күптән көтелгән, күптән эшләнгән, әле сессиягә чыкканчы ук матбугат битләрендә, кулуарларда шау-шулар кузгаткан закон. Ни өчен дисәң, ул сәясәткә дә, социаль хәлебезгә дә, икътисадыбызга да, гомумән, республикабыз язмышына турыдан-туры кагыла.

Дөресен әйтергә кирәк, бу закон моннан берничә ел элек үк кабул ителергә тиеш иде. Кызганычка, без аны һаман сузып килдек. Эт – эткә, эт – койрыкка дигән шикелле, кемдер язганны, кемдер китереп биргәнне, китереп тоттырганны көтеп яттык. Милли хәрәкәт вәкилләре дә "юк, кирәк" дип кычкырудан ары китә алмадылар, галимнәребез, сәясәтчеләребез дә бу зур, четерекле эшкә тотынырга курыкты, үзебезнең арадан да закон язарга атлыгып торучыларыбыз табылмады. Югыйсә, барыбыз да бик милләт җанлы да булгач, барыбыз да аның кирәклеген дә белгәч, әлеге законның берничә альтернатив варианты Дәүләт Советы өстәленә күптән инде куелырга тиеш иде. Әмма без тыныч кына аны Пушкин язар әле дип көттек. Барыбыз да рәхәтне, комфортны, тынычлыкны яратабыз. Бу җәһәттән, бер мәзәк искә төшә. Тычканнар җыелышкамы, сессиягәме җыелганнар. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: "Явыз песидән ничек котылырга?" Җыелыш бик озак барган. Төрле тәкъдимнәр әйтелгән, ләкин аларның берсе дә кабул ителмәгән. Бик озак бәхәсләшкәннән соң катгый бер тәкъдимгә тукталганнар. Песинең койрыгына кыңгырау тагарга кирәк! Барысы да хуплаган бу тәкъдимне. Кул күтәрергә җыенганнар. Шунда тыйнак кына бер тычкан сүз алган. "Бу тәкъдимне мин дә хуплыйм. Бу, чыннан да, явыз песидән котылуның бердәнбер чарасыдыр. Песи койрыгына кыңгырау таксак, без аның килгәнен әллә каян ук ишетеп торачакбыз, ул күренүгә барыбыз да качышып бетәчәкбез. Тик минем бер кечкенә соравым бар иде." "Сора, сора!" – дигәннәр тычканнар. Шуннан теге тыйнак тычкан сорап куйган: "Песи койрыгына кыңгырауны кем тагар икән соң?" Тычканнар тынып калган. Шуның белән мәзәк тә беткән. Песи койрыгына кыңгырау тагарга йөрәге җиткән депутат Рәшит Вәгыйзовның бу хезмәтен, һичшиксез, хупларга һәм кабул итәргә кирәк, дип исәплим. Дөрес, закон проекты әлегә бөтен яктан да эшләнеп бетмәгән. Андый идеаль закон проектларын безнең, гомумән, күргәнебез дә юк. Бу хакта Дәүләт Советы хокук идарәсенең бәяләмәсендә дә әйтелгән. Аларга өстәп тә әйтелер. Ләкин ул кимчелекләрне проектны икенче укылышка әзерләгәндә төзәтеп була. Матбугатта күтәрелгән кайбер бәхәсле моментларны да, сессиядә кузгатылган мәсьәләләрне дә бергәләшеп, киңәшеп уңай якка чишәргә мөмкин булыр, дип уйлыйм. Безнең комиссия әгъзалары да икенче укылышка үзләренең шактый гына төзәтмәләрен, тәкъдимнәрен кертергә җыеналар. Аннары беренче укылыштан соң закон проектын халык тикшерүенә чыгарганда да начар булмас иде. Биредә юристларның, сәясәтчеләрнең, җитәкчеләребезнең акыллы, җитди сүзләре, комментарийлары кирәк булачак. Безнең халык барысын да аңлый. Кешечә аңлата белергә генә кирәк.

"ТР гражданлыгы турында" закон проектын кайбер матбугат органнары карачкы кебек итеп бөтен Татарстан халкын куркытмакчы булалар. Алар, әлбәттә, юкка гына тырышалар. Татарстан халкының курка торган күлмәге күптән тузган инде. Чөнки бу – безгә бик тә таныш сценарий. Декларация кабул итәр алдыннан да куркытучылар күп булды. Декларацияне кабул иттек. Шөкер, бернәрсә дә булмады: җир убылмады, дөнья да бетмәде. Киресенчә, Татарстан халкы Декларация тирәсенә ныграк тупланды. 30 август безнең иң зур бәйрәмебезгә, халык бәйрәменә әверелде. Конституция кабул итәр алдыннан да куркытучылар күп булды. Әмма Татарстан Конституциясе үзебезнең халкыбызга, үзебезнең республикабызга хезмәт итә. Конституциядән берәүнең дә зарланганы юк. Референдум алдыннан да шулай булды. Бөтен Русия җитәкчелеге безгә каршы купты. Янәсе, без Русияне таркатырга җыенабыз. Референдум үтте. Бернинди катаклизмнар да булмады. Киресенчә, Русия күләмендә, дөнья күләмендә мәртәбәбез генә артты. "ТР гражданлыгы турында"гы законны кабул иткәннән соң да, иманым камил, шулай булачак.

Әшулай да без һаман да Декларациябезгә сокланып, Русия белән төзелгән Шартнамә белән горурланып, сәяси яктан бер урындарак таптана башладык шикелле. Югыйсә, Декларациябезне, үзебезнең яулап алган суверенлыгыбызны без күптән инде яңа законнар белән ныгытырга тиеш идек. Ә без – беренче булып суверенлык юлына аяк баскан, федерализм төзелешенең алгы сафында барган республика, һич югында, үзебезнең күршеләребездән калышмаска тиеш. Бу җәһәттән Башкортстан Президенты М.Рәхимовның узган ел фәнни-гамәли конференциядә ясаган чыгышы безнең сессиядә Минтимер Шәрипович әйткән фикерләр белән тулысынча туры килә. "Гражданство для РБ – не внешняя атрибутика, лишь подтверждающая ее высокий юридический статус. Это право мы рассматриваем как один из действенных инструментов защиты каждого отдельно взятого человека и всех людей, проживающих на территории Башкортстана. Используя институт гражданства, нам удалось решить многие важные политические, экономические и социальные проблемы". Күршеләребез дә, күрәсез, тик ятмый. Алар да безнеңчә уйлый. Алар үзләренең мөстәкыйльлекләрен ныгыту йөзеннән саллы-саллы законнарны да күптән кабул итеп куйганнар инде. Менә аларның кайберләре: "О Верховном Суде РБ", "О судоустройстве в РБ", "О правовом режиме чрезвычайного положения в РБ", "О Конституционном Суде РБ", "О Высшем Арбитражном Суде РБ", "Об адвокатуре", "О безопасности в РБ", "О прокуратуре"... Бездә мондый законнар кайчан да булса кабул ителерме? Берәребезне борчыймы бу хәл?

Аннары шуны да онытмыйк: Русиянең аның акылы үзе белән. Кайсыдыр урыс шагыйре әйткәнчә, "Россию умом не понять". Анда теләсә кайсы мизгелдә дәүләт түнтәрелеше булырга мөмкин. Анда теләсә кайчан җиң сызганып социализм, коммунизм төзергә яисә барысын да җимереп, яңадан капитализмга борылырга мөмкиннәр. Анда теләсә кайсы көнне Чечняга бәреп керергә, аның авылларын, шәһәрләрен җир белән тигезләргә мөмкиннәр. Анда теләсә кайсы көнне саклык кассаларындагы кертемнәрне чүпкә әйләндереп, бөтен халыкны ыштансыз калдырырга мөмкиннәр. Анда теләсә кайсы вакытта үз парламентын тупка тотарга мөмкиннәр. Русиядән барысын да көтәргә, барысына да әзер булып торырга кирәк. Тагын шуны да онытырга ярамый. Безнең ике арадагы Шартнамәбезнең вакыты чыгып бара. Аерым килешүләргә ревизия ясарга Русиянең яшь җитәкчеләренең куллары күптән инде кычытып йөри. Яңа килешүләр нинди булыр? Без әле бүгенгеләреннән риза түгел. Ә бит яңаларының боларыннан да начаррак булуы бар.

Чабатаны безгә алдан ук киенеп куярга кирәк. Русия өчен без әле һаман да гади бер субъект. Ул безнең сүзгә колак салмый. Моннан берничә ай элек без Русия паспорты турында сөйләшкән идек, мөрәҗәгать белән чыккан идек, безгә башкалар да кушылган иде. Әмма күрәсез, тавышсыз калдырылды, Русия хакимияте эндәшмәде – безнең белән сөйләшергә теләге тын юк. Русия хакимияте эндәшми.

Татарстан гражданлыгы турындагы закон ул кемдер уйлап чыгарган, кемгәдер кирәк булганга гына язылган закон түгел. Ул Татарстан Конституциясен тормышка ашырыр өчен кирәк. Ә без хокукый, демократик дәүләт төзергә ниятлибез. Димәк, без үз Конституциябезне хөрмәт итәргә, шул Конституциягә таянып яшәргә тиешбез.

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

Шәһәр этләре

Аяз көнне яшен сукты диярсең. Казаныбызның үзәге саналган Бауман урамыннан тыныч кына узып барганда, ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышын ишетеп, сискәнеп киттем.

Тавыш килгән якка борылып карасам, ярдәм сорап кычкыручыны – затлы тун кигән чибәр генә ханымны күреп алдым. Аны унлап урам эте сырып алган. Эреле-вaклы, йоннары чуалган шул җанварлар берсен-берсе уздырып һау-һаулыйлар. Алай гына да түгел, берикесе хатынның тун итәгеннән кабып йолкырга да керештеләр, тырыша торгач, чабуын умырып ук төшерделәр. Зыян күрүчегә берничә кеше ярдәмгә ташланды. Боз, кар йомарлап этләргә атарга керештеләр. Моны көтмәгән этләр ничек килеп чыккан булсалар, шулай ук каршыдагы ишегалдына качышып та беттеләр.

Бу вакыйганы сөйләвемнең сәбәбе шунда – соңгы вакытларда Казан урамнарында мондый хәлләрне еш очратырга була. Аерым төркемгә берләшкән хуҗасыз этләр көтмәгәндә подваллардан, ишегалларыннан килеп чыгалар да кешеләргә ташланалар. 1997 елда гына да, җөмһүриятебезнең дәүләт эпиднадзор мәгълүматларына караганда, 13770 кеше зыян күргән.

Билгеле инде, хуҗасыз этләрдән зыян күрү төрле авырулар китереп чыгара. Ә иң куркынычы – котыру чире. Белгечләрнең әйтүенә караганда, узган елда гына да шундый 49 очрак теркәлгән. Казан һәм башка шәһәр, районнарыбызда хуҗасыз этләрнең артуында кешеләр үзләре гаепле, билгеле. Шәһәр йортларының тар бүлмәләрендә, чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, бозау кадәр этләр асрыйлар һәм соңыннан урамга куып чыгаралар. Монда, әлбәттә, соңгы елларда халыкның фәкыйрьләнүе, этен, мәчесен түгел, үзен, балаларын да тиешенчә ашата алмаулары сәбәпчедер. Сүз уңаеннан хуҗасы булган этләрнең дә урам, ишегалларыбызны пычратып йөрүләрен, инде матбугатта күпме генә сүз алып барылуга да карамастан, санэпидстанция хезмәткәрләренең күз йомып яшәүләрен әйтеп үтү кирәктер. Шулай дигәч, хәтергә үземнең таныш сатирик язучы белән сөйләшүем искә төште әле.

– Мондый этләрне нишләтергә? – дип соравыма каршы ул:

– Хуҗалары белән бергә атарга кирәк!.. – дип җавап биргән иде.

Бу, әлбәттә, артык каты әйтелгән сүзләр. Ә бит юкса алга киткән илләрдә этләр, мәчеләр өчен дә махсус зиратлар булуы мәгълүм. Ә бездә исә юл читләре, урам-тыкрыклар, ишегаллары үлгән эт, мәче үләксәләре белән тулган. Яз җитсә алар сасып-череп тирә-юньгә начар ис, микроб таратып яталар.

...Сүз башында хуҗасыз этләрнең кешеләргә зыян салып йөрүләре турында әйткән идем. Эшләр болай дәвам итсә, тиздән урамнарга коралланмыйча чыгып та булмаячак бит.

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

Әйткән сүз – аткан ук

Фикрәт ТАБЕЕВ, партия һәм дәүләт эшлеклесе:

"Безнең республикадагы татарлар үзләренең интеллектуаль үсешләре ягыннан ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребездән югарырак торалар".

("РТ").

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Полиграфия өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Сарман районы типографиясе директоры **ХӘЙРУЛЛИН Роберт Гыйззәт улы** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Президент сараенда бүләкләр тапшыру

Үткән шимбәдә Татарстан Президенты Сараеның зур залында халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, фән, мәдәният хезмәткәрләренә, икътисадчыларга, төзүчеләргә, машина төзүчеләргә һәм химикларга дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы булды.

Татарстан сәнгате – Мәскәүдә

Мәскәүдәге Шаховских сараенда "Татарстанның бүгенге заман сынлы сәнгате" дигән мәртәбәле күргәзмә ачылды. Анда төрле юнәлештә – реализмнан алып авангардка хәтле – иҗат итүче рәссамнарның 100дән артык әсәре мәскәүләр. хозурына тәкъдим ителә. Рәсемнәрне карау гына түгел, сатып алырга да мөмкин.

Уеннан уймак

Узган елның октябрь аенда 18 яшьлек Марат Камалетдинов, 14 катлы йорт түбәсеннән таш атып (нәкъ менә кешегә тидерүне күздә тотып уйнаганнар), Фәридә Юнысованы үтергән иде. Егетнең уены кыйммәткә төште. Республиканың Югары суды аны 13 елга ирегеннән мәхрүм итте.

Кинотеатрдан – әкияти сарай

Нурлатта кинотеатр бинасын үзгәртеп корганнан соң, ул мәһабәт, әкияти сарайга әверелде. Хәзер яшьләр йортында никахлашу залы, кунак кабул итү бүлмәсе, гаиләне планлаштыру кабинеты һәм башка ял итү, күңел ачу урыннары бар.

Хаҗилар артачак

Быел Русиядә яшәүче 18 мең мөселман Мәккәгә барырга ниятли. Казаннан 126 кеше Хаҗ кылырга, сәфәр чыгарга исәп, тота.

"Курай" моңы

"Курай" радиосы оештырылуга 500 көн булды. Бу уңайдан "Казан" милли мәдәният үзәгендә концерт, "Курай" дискотекасы булып узды.

Иске Татар бистәсе

Министрлар Кабинеты 1994 елда ук Иске Татар бистәсе тыюлыгын оештыру турында карар чыгарган иде. Шуның нигезендә Казан мэры яңа префектура турындагы карарга быел имза куйды. Ул Кабан күленең уң ягына урнашкан Вахитов мәйданыннан Нариман урамы буенча Г.Камал урамына кадәр һәм Сул болак буендагы мәйданнарны үз эченә ала.

Президент күпер сала

Беларусь Республикасының татар яшьләре оешмасы президенты Бәкер Радкевич Казанда булып китте. Ул "Татар-Информ" мәгълүмат агентлыгында, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында, Балалар һәм яшьләр эше буенча дәүләт комитетында, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында, "Азатлык" яшьләр оешмасында, радиода булды, журналистлар белән очрашты.

Беларусьтагы татар яшьләре оешмасы, әле моннан өч кенә ай элек оештырылуына да карамастан, киләчәктә ике төбәктә яшәүче канкардәшләр арасындагы туганлыкны ныгыту, ана телебезне, динне үстерү, күркәм йола, гореф-гадәтләребезне тергезү эшенә җиң сызганып керешт е.

Казан дәүләт татар яшьләр театры "Чулпан" милли мәдәният үзәгендә быелгы сезонда дүртенче премьерасын күрсәтте. Ул – Илдар Юзеевның "Хуш, Хәйбуш!" исемле моңсу комедиясе. Спектакль тамашачылар күңеленә хуш килде. Әсәрне сәхнәгә куючы режиссер – Ленар Садриев, рәссам – Әхәт Закиров, композитор – Фуат Әбүбәкеров.

● *Спектакльдән бер күренеш.* *Мидхәт* ***ШАКИРҖАНОВ*** фотосы.

Хөрмәтле укучылар! Татарстан Элемтә министрлыгы 1 февральдән 31 мартка кадәр 1998 елның икенче ярты еллыгы өчен гамәлдәге бәядә "Мәдәни җомга"га льготалы язылу үткәрә. Димәк, почта бүлекләренә барып, тагын 27 сум акча түләсәгез, газетебез сезгә ел ахырына кадәр килеп торачак. Бу хакта туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга да әйтсәгез икән.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Казанда яшәүче әтиебез Илгиз Якуб улы Шәрифуллинны 60 яше тулуы һәм әниебез Хәлимә Зиннәт кызы белән 35 ел бергә яшәүләре уңаеннан чын күңелдән тәбриклибез, аларга озын гомер, саулык-сәламәтлек һәм бәхетле картлык телибез.

Барлык туганнары, балалары, оныклары исеменнән кызлары Ләлә һәм кияүләре Илһам.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Президент М.Шәймиев Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Президентының шәхси канцеляриясе башлыгы Абдулла Лютар Бәнимәликне кабул итте.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З.Вәлиева Бөекбританиядән килгән кунакларны – Бөтендөнья кулланучылар хокукларын яклау оешмасы генераль директоры урынбасары А.Филдерны, оешманың баш эксперт-консультанты А.Макджорджны һәм Халыкара кулланучылар җәмгыятьләре конфедерациясе президентының тышкы элемтәләр буенча ярдәмчесе В.Вертоградовны кабул итте.

Министрлар Кабинетында республикадагы юлларның торышы, хәрәкәт иминлеге өчен көрәш мәсьәләләрен тикшерү буенча киңәшмә булды.

Татарстан санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитетының коллегия утырышы узды.

Казанда хезмәт ветераннарына (алар 120 меңнән артып китә) "Хезмәт ветераны" дигән кенәгәләр бирү башланды.

Башкалабызга Японияддән айкидо остасы К.Такаянаги килде.

Чаллыда өч ел рәттән иң сәләтле балалар өчен шәһәр хакимияте стипендиясе түләнә.

Татарстан Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы булды.

Бөтентатар иҗтимагый үзәгендә республика мөселманнары корылтаенда, Милли Мәҗлес конференциясендә кабул ителгән карарлар, БТИҮнең милли оешмалар белән бергәләп эшләүгә юнәлтелгән бурычларына багышланган җыелыш эшләде.

Нурлат районында агропромышленность мәсьәләләре буенча ике көнлек семинар-киңәшмә эшләде.

Г.Камал театрында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, актриса, режиссер К.Тумашеваның юбилеена багышланган тантана булды.

Казанның зур концерт залында тынлы музыка фестивале булып узды

Сәхифәдә редакция журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Татарстанның халык язучысы Әмирхан ЕНИКИ (сулда) һәм Мәскәүдә яшәүче күренекле галим Әгъдәс БОРҺАНОВ.** Н.КУРАМШИН фотосы.

Җәнәт әңгәмә

Керәшен аерым милләтме?

Һ гомер, и фани дөнья!.. Барысы да тәкъдирдә язылганча килеп чыга: җиһанга кайчан туачагыңны да, мәңгелек йортына кайчан китеп барасыңны да алдан белеп булмый. Гаять катлаулы гомер юлы үтсә дә, яшәү дәрте белән, иҗат белән канатланып яшәгән Гурий дәдәй ТАВЛИН үзенең яраткан газете "Мәдәни җомга" редакциясенә әле күптән түгел генә килеп киткән иде, югыйсә. Хушлашып китүе булган икән бахырның!.. Соңгы мәртәбә әңгәмә корып китүе булган. Нишләмәк кирәк, теге дөньяда да яхшы кешеләр кирәк, ахры...

– Гурий дәдәй, син инде җитмештән уздың, язучы кеше бу яшьтә нишли?

– Узган юлына йомгак ясый.

– Йомгак ниндирәк соң?

– Канәгатьләнү юк.

– "Афәт" романың сиңа дан китерде...

– Басылмаган тагын биш романым сыкрап ята. Мин үзем теләгәнчә иҗат итә алмадым.

– Ни сәбәпле?

– "Халык дошманы" булганым өчен. Төрмәдә узды яшь гомер. Ирекка чыккач та, шул нахак тамга өстемнән төшмәде, эшкә алмадылар...

– Җитмештән узган язучы алга таба ни кыласын уйлыймы?

– Аңа вакыт калмады.

– Вакытны Гурий дәдәйгә Аллаһы тәгалә күп бирсә?

– Җигелеп эшләр идем. Керәшеннәр турында олы әсәр язар идем. Яртысы язылган инде.

– Керәшеннәр аерым милләтме?

– Юк.

– Ни өчен?

– Бар мишәр кавеме, бар керәшен, әмма без бер милләт – татар кешеләре.

– Керәшен арасыннан чыккан артистлар, язучылар бар, ләкин алар мөселман-татар исемнәрен алып иҗат итәләр. Ни өчен шулай?

– Дискриминация сәясәте аркасында. Үз исемеңнән баш тарту – ул үз халкыңнан оялу. Миңа әллә ничә әйттеләр: мөселман исемен ал, китабыңа мөселман исеме куй, диделәр. Алыштырмадым.

– Мин керәшен сәнгатькәре булсам, мөселман исемен дә, урысныкын да алмас идем, фәкать керәшенчәсен генә язар идем. Григорий түгел – Гөргөри; Яков түгел – Җәкәү, Аксинья түгел – Үкчинҗә. Саф татарча матур яңгырашлы исемнәрне әрәм итеп, йә урысча нөсхәсен, йә мөселман исемен алучыларга син үпкәлисеңме?

– Үпкәлим.

– Зәй шәһәрен керәшеннәрнең башкаласы, дип йөртүчеләр бар. Килешәсеңме?

– Килешәм. Зәй янында гына да керәшеннәр яшәгән 23 авыл бар. Шунда минем туган авылым Урта Баграж урнашкан.

– Керәшеннәрдә бер кешенең өч исеме була. Паспортта урысча, әйтик, Николай, керәшенчәсе – Микулай, шулар өстенә, аны үзара мөселман исеме белән Мансур дип тә йөртәләр. Бу гадәтнең тамырында нинди тарихи сәбәп ята?

– Мин бу йоланы белмим. Керәшен гадәтләрен син миннән яхшырак беләсең, ахры.

– Якын киләчәктәге өметегез?

– "Казан утлары" журналында Казан ханлыгының 1552 елда җимерелүе хакында "Һәлакәт" дигән романым чыгар, дип уйлыйм.

– Иншалла! Көтеп калабыз.

Әңгәмәне
Рабит БАТУЛЛА
үткәрде.

Гурий ТАВЛИН

Татар әдәбияты зур югалту кичерә: озакка сузылган авырудан соң шушы елның 17 февралендә 73 нче яшендә оста каләме, йөгерек теле, тирән эчтәлекле әсәрләре белән танылган Гурий Тавлинның йөрәге тибүдән туктады.

Гурий Иванович Тавлин 1925 елның 25 декабрендә Татарстанның Зәй районы Урта Баграж авылында туган. 1942 елда Югары Баграж урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Түбән Бәеш җидееллык мәктәбендә балалар укыта. Ә 1943 елның февралендә Г.Тавлин армиягә алына, училищеда кыска сроклы әзерлек үткәч, фронтка китә. Днепрны кичүдә, Украинаны, Белоруссияне, Польшаны фашистлардан азат итүдә катнаша.

1946 елда демобилизацияләнеп кайтканнан соң, ул Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Әдәби иҗат белән чынлап торып мавыккан дүртенче курс студентын 1950 елның 23 гыйнварында кулга алалар. Ул Совет строена каршы милләтчелек рухында контрреволюцион агитация алып баруда гаепләнеп, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Шул чакта аның "Дунай дулкыннары" романы юкка чыга.

1954 елның көзендә, ниһаять, Гурий Тавлин өчен дә хакыйкать таңы ата – аның гаебе юклыгын таныйлар һәм иреккә чыгаралар. Институтны яңадан тәмамлап, кулына диплом алса да, аны озак еллар укытучылык эшенә якын китермиләр. Унҗиде ел буена ул төзелештә, аннары республика һәм район газетләре редакцияләрендә эшли. Ә соңыннан Казан, Яшел Үзән шәһәрләрендә мөгаллимлек итә. Бер кешә өлешенә түгел, берничә адәм тәкъдиренә җитәрлек газап һәм михнәтләр дә аның рухын сындыра алмый. Талантлы каләмдәшебезнең иҗат чишмәсе корымый. Гурий Тавлин "Афәт" романы, "Сары яфраклар коела", "Йолдызлар безгә янәшә", "Тәвәккәл таш яра", "Алгы сафта", "Атказанган укытучы" һәм башка китаплары белән киң катлам укучылар ихтирамын казанды.

Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен ул "Кызыл Байрак", "Кызыл Йолдыз" һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә.

Әдәбият язмышы, әдәбиятка килүче яңа буын, татар халкының киләчәге турында кайгыртып яшәгән гаҗәеп үзенчәлекле, җор телле, тынгысыз җанлы бу олы әдип халкыбыз күңеленнән мәңге җуелмас.

Татарстан Мәдәният министрлыгы,
Татарстан Язучылар берлеге.

Халык язучысы – мактаулы академик

Башка илләрдә һәм халыкларда күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләрен мактаулы академиклар итеп сайлау гадәте яшәп килә. Һаман да шул "автономия" булуыбыз аркасындадыр инде, үз вакытында мондый хөрмәт милләтебез горурлыгы Нәкый Исәнбәткә дә, Бакый Урманчега да күрсәтелмәде. Ниһаять, мөстәкыйльлек юлыннан баручы җөмһүриятебезнең Фәннәр академиясе, соңлабрак булса да, әлеге "хата"ны төзәтергә карар кылды: академиянең еллык гомуми җыелышында Татарстанның халык язучысы Гарифҗан Ахунҗан улы АХУНОВ (Гариф Ахунов) ТФАның мактаулы әгъзасы итеп сайланды. Без мөхтәрәм каләмдәшебезне һәм, гомумән, әлеге җыелышта әгъза-мөхбир булуга ирешкән галимнәрне чын күңелдән тәбрик итәбез, аларга саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.

70 яшь ксыну

Курайда сагышлы моң бар

Иҗат кешесенә яшәү бервакытта да җиңел бирелмәгән. Канаты яраланса да үзен аямыйча очарга талпынган ул. Читтән караганда, андый затлар сәер дә күренә бугай. Ә үзләренә артык дәрәҗәдә ышанган эшем кешеләре: "Бу адәм ни кылып йөргән була инде?" – дип сүз атарга да күп сорамыйлар. Ул затлар исә үзен аямыйча гел эшләүдә булыр, иҗат итәр. Милләтенә хезмәт күрсәтер. Һәм милләтенә кылган игелеге өчен әҗер сорамыйча, тавыш-тынсыз гына, ләкин җиһанның, янәшәдәгеләрнең рәхимсез-шәфкатьсезлегенә рәнҗеп фани дөньядан китеп барыр.

Кемгәдер авыр булмасын, әлеге сүзем шуларның берсе – батыр йөрәкле кызыбыз, минем остазым, режиссер Кәшифә апа Тумашева хакында.

Аның турында сүз башлар алдыннан милләтебезнең үлемсез сандугачы – безнең җаннарга җуелмаслык моңнары белән кергән Сара апа Садыйкованы, гомер бакый үзенең баянын, аккордеонын күтәреп юлда йөргән, салкын клубларда чыгыш ясаган Оркыя апа Ибраһимованы искә төшерү кирәктер. Алар – милләтебезгә буыннар чылбырын ялгап киләчәккә баруда бәһаләп бетерә алмаслык хезмәтләр калдырган шәхесләр.

Бездә "Хаксызлыкның йөзен ачар өчен хаклыкны ачу кирәк", дигән мәгънәле гыйбарә бар. Шуны раслау максатыннанмы, үткән елның 20 декабрендә Кәшифә апаның туган төбәге Көнәгердән (Балтач районы) аның тууына 95 ел тулуны билгеләп үтәр өчен чакыру һәм машина җибәрделәр. Без юл буе аның рухы белән күңелдән сөйләшеп бардык...

Кәшифә апаның авылдашлары безне якын туганнары итеп ачык йөз белән каршы алды.

Мәдәният йортының түрендә Кәшифә апаның фотосурәте эленгән. Ул безгә, үзенең эчке ярсуын яшерергә омтылгандай, тыйнак кына карап тора.

Тантана башланды. Заманында Кәшифә апа Тумашеваның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куйган "Күзләр" тамашасында яңгыраган "Хуш, авылым" көе курайда башкарыла. Зал тынып калган. Шушы тынлыкны бозарга базмыйча сак һәм йомшак тавыш белән әлеге тантана-мәҗлесне оештыруда башлап йөргән Дания Кәлимуллина Кәшифә апабызның тормыш һәм иҗаты турында сөйләде. Аны Кәшифә апабызның шәкертләре – Сара апа Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская, Кәшифә апаның якын туганнары Диләрә Тумашева, Зөмәрә Хәмитова һәм башкалар дәвам итте. Алардан соң сүзне Балтач районы хакимияте җитәкчеләре, Көнәгер авылының мөхтәрәм кешеләре – укытучылар, алдынгы укучылар алды. Сара Садыйкованың иҗтимагый фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов чыгыш ясады. Аларның һәммәсе авылдашы, якташы, якыны булган Кәшифә апа Тумашеваның якты шәхес булуы хакында җылы сүзләр әйттеләр. Кәшифә апаның истәлеген сакларга, аның музеен ачарга вәгъдә иттеләр.

Сания ИСМӘГЫЙЛЕВА,
Татарстанның халык артисты.

Буа карабодаена дөнья соклана

Яхшы күңелле кеше белән очрашуыңны хәтердә калдыру өчен бер вакыйга да җитә. Утыз еллар элек Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов белән аның фатирында кыздырылган һәм маринадланган майлы гөмбә ашап сөйләшкән идек. Гөмбәсен гаилә белән Зөя буе наратлыгыннан җыеп эшкәрткәннәр иде. Мөхәррәм ул чагында Буа районында танылган "Ватан" колхозының баш агрономы, бер үк вакытта идарә рәисе урынбасары һәм партком сәркатибе иде. Икенче мәртәбә аны "Искра" колхозында очраттым. Якын танышлар кебек сөйләшәбез. Электән дә таза бу хуҗалыкка колхоз рәисе итеп куелган икән. Колхозчылар "Ватан"дагы эшен белгәнгә яратып сайлаганнар.

Мөхәррәм, тынгысыз җанга хас буларак, мондагы планнары турында сөйли. Мин дә кушылам, хәтта сүзен куәтләп җибәрәм. Чөнки колхоз күптәннән таныш. Хәтта борынгы һөнәре билгеле. Мондагы Яңа Тинчәле авылы крәстиәннәре элек карабодай җитештерү белән шөгыльләнгәннәр. Шунысы кызыклы, ике йортның берендә карабодай яру тегермәне булган, аны җыйнак кына итеп, бер кадаксыз, агачтан эшләгәннәр. Тегермән валлары крәстиәннең үз аты белән хәрәкәткә китерелгән. Шушы искиткеч агрегат авыл гаиләсенең тормышын алып барырга булышкан, чөнки Яңа Тинчәле крәстиәннәре карабодай ярмасы белән сәүдә иткәннәр. Ә табынга 8 төрле карабодай ашы куя торган булганнар.

Картлардан ишеткәннәремне яшь рәискә таслап сөйләдем, хәтта майлы карабодай коймагы турында да онытмадым. Ә хуҗалыкны карап чыккач, юл уңаенда, сөзәк чокыр буена алып килдем. Анда иске авылдан сакланып калган соңгы карабодай яргыч бар иде. Тегермән ташландык хәлдә калган, бинаның түшәме искергән, су үтә иде. Ләкин авыл остасы кулы белән эшләнгән могҗизалы агрегат үзе туздырылмаган. Яшь рәис аны тирәли йөри-йөри карады. Аннары озак кына текәлеп уйланып торды.

Яхшы фикерләр изге сәгатьтә килә һәм гаҗәеп йогынтылы була. "Искра" колхозына кабат баргач, Мөхәррәм теге карабодай яргычның яңа урынын күрсәтте. Атап төзелгән таш бинада келтерәп эшләп ята. Күршесендә тары яргыч та бар. Цехның икенче башында ике он тегермәне бөртек тарта: берсе – колхозчыларга, күмәчлек, икенчесе – колхозга, фуражлык он бирә.

Рәис соңынтын колхоз өчен бу цехның кыйммәте, файдасы турында шатланып сөйләде. Карабодай ярмасы, токмачлык он белән машиналарга теләсә нинди запас часть һәм колхозга төзелеш материаллары табып була икән. Ярма ярдырырга ерак-ерак районнардан, хәтта өлкәләрдән килгәннәр. Яңа Тинчәләнең иске һөнәре кайткан һәм колхозны ныгыту, каралтыларны киңәйтү, яңартуга китергән.

Карабодай тегермәне камилләшкән, киңәйтелгән. "Искра" карабодай мәйданын да 300 гектарга җиткергән һәм, мул уңыш үстереп, ел саен Мәскәүдә, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашуга ирешкән. Бу колхоз хәтта 100 гектарлы мәйданның гектарыннан 34,2 центнер уңыш ала һәм карабодай буенча дөнья энциклопедиясенә кертелә. Бу, әлбәттә, карабодай игүче "Искра" колхозы өчен дөнья таныган һәйкәл сыман тоела.

Акыллы кеше хәерле сәгатьне көтеп кенә тора. Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов та, Яңа Тинчәледә, бабайлар тегермәне базасында, чып-чын карабодай эшкәртү заводы төзү фикере белән яши башлый. Уңай җил дә килеп чыга. Танылган һәм оста колхоз рәисен Республика колхозлар советы рәисе итеп сайлап куялар. Уйлаганын Татарстан күләмендә гамәлгә үткәрергә мөмкинлек туа. Республикада зур мәйданда карабодай игелә башлый, аны эшкәртү мөмкинлекләре эзләнә. 15 колхоз составында карабодай һәм рапс буенча фәнни-җитештерү оешмасы барлыкка килә. Бу система колхозларны технология белән тәэмин итәргә тиеш була. Җиһазлар табу чарасына да керешәләр. Әмма беркем дә комплект тәкъдим итми.

Көтмәгәндә Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов тормышында текә борылыш булып алды. Ул СССР Югары Советы депутаты итеп сайлана, хәтта Югары Советның әгъзасы була, Милләтләр Советының союздаш һәм автономияле республикалар, өлкә, округларның социаль-икътисади үсеше мәсьәләләре буенча комиссиягә җитәкчелек итә башлый. Колхоздан китәргә туры килә.

Әмма фикеренә, гамәленә тугры кеше нинди генә катлаулы, җаваплы эшкә алынса да, үзен һәм шөгылен югалтмый. Мөхәррәм Тимергали улы Мөхәммәтҗанов та шул сыйфатын саклый, тәвәккәллек һәм кыюлык күрсәтеп, карабодай һәм башка культуралар эшкәртү буенча "Зөя" ("Свияга") акционерлык җәмгыяте төзи, үзе җәмгыятьнең идарә рәисе итеп раслана. Бу республика өчен дә зур яңалык иде. Чөнки акционерлар хәрәкәте бөтенләй башланмаган, билгесез чак иде. Соңрак карабодай җитештерүчеләрнең Бөтенсоюз ассоциациясе дә оеша һәм М.Мөхәммәтҗанов анда вице-президент була. Колач киңәю белән бергә, бурычлар да арта. Иң беренче "Зөя" акционерлык җәмгыятенең матди базасын торгызасы бар. Каралтыларын Буа шәһәрендә күтәрәләр. Ә җиһазлар белән хәл авыррак. Тулы комплект машиналарны илдән таба алмыйсың. Менә шундый чакта колхозчыларның IҮ съезды була. Анда СССР колхозларының советы төзелә, һәм М.Мөхәммәтҗанов әлеге советның әгъзасы итеп сайлана. Аңа гаиләсе белән Мәскәүгә күчәргә туры килә.

Хыялларын тормышка ашыру өчен бик уңай очрак. Мөхәррәм әфәнде эшкәртү җиһазларын конкурс нигезендә "Сафарма" фирмасы аша эзләргә керешә. Япониянең "ТАЙРИКУ ТРАЙДЕНГ" фирмасы белән элемтәгә керә. Карабодай үрнәкләрен дә җибәрә. Үзе Япониягә барып кайта. Фирманың заводын, җиһазларын күрә. Җиһазларны вәгъдә итәләр, әмма тулы комплекты белән түгел. Автоматик идарә кампитрын алу өчен Германия фирмаларыннан рөхсәт кирәк. Һәм М.Мөхәммәтҗанов Италиягә, Швейцариягә, Аурупаның башка илләренә бара, йә Колхозлар советы исеменнән мөрәҗәгать итә. Ниһаять, ул чагындагы Көнбатыш Германиянең гигант "Бюлер" концерны белән өметле, хәтта бәхетле элемтә урнаштырыла. Мөхәррәм әфәнде дөньяның бу эре машина төзелеше концерны (аның "Сортэкс" группасы дөнья базарында азык промышленносте өчен җиһазлар җитештереп танылган) белән үзе барып таныша. Килешүгә дә киләләр. Немесләр контрактны берничә айда үти. "Зөя" акционерлык җәмгыятенә кадерле йөк 17 вагон, 102 контейнер белән 1990 елның декабрендә кайтып төшә һәм 4 айда монтажланып бетә. Монда тагын бер кыенлык сизелә: ул чакта валюта юк, нимес белгечләре безгә килә алмыйлар. Барын да әзер схема буенча Буа белгечләре үзләре монтажлый. Буада карабодай эшкәртү заводы агроном, колхоз рәисе хезмәтләрендә чыныккан, дәүләт органнарында идарә итү осталыгына өйрәнгән, икътисадта вакыттан узып барырга омтылган кеше Мөхәррәм Мөхәмматҗанов кыюлыгы белән шулай барлыкка килде. Ул элеккеге Союзда да шундый бердәнбер завод иде.

Аннары "Зөя" җәмгыятендә Көнбатышка игътибар иттеләр. Заводта мәйдан бар иде. Икътисади куәт тә өлгерде. Нимес лицензиясе белән Новосибирскидан май прессы алып кайттылар. Бу көнбагыш кыскыч берничә ел эшли иде. Даны еraklardan әйләнеп кайтты. Көнбагыш уңышын күрше өлкә һәм республикалардан бирегә китереп тапшыралар һәм килешүдә билгеләнгән өлешне саф май килеш алып китәләр. Завод капкасы төбендә Идел буе һәм ерак Кубань машиналарын да күрергә була. Буа заводы үзләрендәгегә караганда көнбагышны кыйммәтрәккә ала, исәп-хисапны вакытында ясый.

Бу юлы гыйнварда көнбагыш сыгу сезонына туры килдем. Монда тәүлеккә 12 тонна шифалы май җитештерәләр. М.Мөхәммәтҗановның эш бүлмәсендә телефон шалтыраудан туктамый. Завод инде сыйфатлы мае (аның составында сәламәтлек өчен кирәкле аминокислота 68 процент исәпләнә) белән танылган. Хикмәт шунда, Буа заводы үсемлек мае алуда экстракцион, химик ысул кулланмый, җитештергән мае хәтта дәва өчен яраклы һәм файдалы була. Аны эзләп, еraklardan киләләр. Тәмен белгәннәр. Түптә калган мае да әрәм булмый, анысыннан кош фабрикалары өчен кадерле, витаминлы азык әзерлиләр. Завод узган ел кошлар, терлекләр өчен 6 мең тонна катнаш азык әзерләп биргән. Ә көнбагыш кабыгын төзү материаллары комбинаты кирпеч җитештерү өчен теләп ала. Былтыр туксан вагонга якын шундый чимал озатканнар.

Завод узган ел 240 тонна көнбагыш мае биргән. Көнбагыштан 50 тонна хәлвә пешереп, сатуга да чыгарганнар. Әмма заманасы шулкадәр катлаулы, системасы усал – хәзерге шартларда продукцияне күбрәк җитештергән предприятие бөлгенлеккә тизрәк якыная. Карабодай җитештерү белән дә шулай: комсыз салым сагалый!

Хәзерге заводның куәте сокланырлык. Тәүлек саен 120 тонна карабодай эшкәртерлек мөмкинлеге бар. Дөнья стандарты дәрәҗәсенә җиткән ярма һәм карабодай оны бирә. "Зөя" нигездә япон технологиясе буенча эшли. Шунысы игътибарга лаек: карабодай ярмасы сыйфатына бәяне дөнья базары бирә. Американың "Хайнц" фирмасы Татарстанның "Зөя" акционерлык җәмгыятендә һәм төрдәш заводларда җитештерелгән карабодай ярмасын дөнья стандартына нигезләп тикшергән һәм гаҗәп мәгълүматлар биргән. Төрдәш заводларда ярдырылган ярмада кадерле витаминнар бөтенләй калмый, ул нигездә крахмалдан тора, ә камил җиһазларда эшләүче "Зөя" заводы, май, углевод һәм аксымнарны саклау белән бергә, күп төрле витаминнарга бай аксыл ярма бирә икән. Завод табыш белән эшли. Эшчеләре хезмәт хакын вакытында алалар. Ә айлык эш хакы искечә 1 миллион 200 мең сумга җиткән. Эшчеләрнең тормыш-көнкүреше яхшырган, Буа шәһәрендә 24 торак йорт та салып куйганнар.

"Зөя" акционерлык җәмгыятенең Буадагы заводы дөньяга билгеле икән инде. "Бюлер" концернының "Diagramm" журналы белән танышам. Ул нимес, инглиз, испан, француз, итальян, урыс, япон һәм кытай телләрендә нәшер ителә. Аның бер санында Фолькер Штробельның "Карабодай белән кызыксыну үсә" исемле кызыклы язмасы урнаштырылган. Ул безнең Буа заводына багышлана. "Буадагы (Татарстан) җайланма карабодай эшкәртү буенча үрнәк булып тора, белгечләр бирегә еш киләләр. Ярдырылган ярманың чисталыгы һәркемне җәлеп итә", – дип соклана автор. Шунда ук карабодай үсемлегенең тарихына туктала: "Бу үсемлек, – ди ул, – Кытайдан чыккан, Урта һәм Төньяк-Көнчыгыш Азия аша Аурупага килгән. Карабодайны Германиядә татар бөртеге дип тә санныйлар..." Автор карабодай ашлары, ярмасының, азык-төлек культурасы буларак, сыйфаты турында да ләззәтләнеп сөйли.

Әйе, безнең карабодайга дөнья соклана. Ә аның ярмасы дөньяның иң яхшы җиһазлары куелган Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов заводында, Буада җитештерелә. Заводның ярмасы да, мае да бар. Сыйфатлы һәм арзан. Ә "Зөя" акционерлык җәмгыяте бу көннәрдә унъеллыгын бәйрәм итә.

Мәрди РАФИКОВ,
үз хәбәрчебез.

● *Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов.*

ГАДЕЛЛЕК ХАКЫНДА уйланыр чак җитте

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ,
парламент хәбәрчебез

Даими эшләүче парламентның 18 февральдәге утырышы ачылуга депутат Фәндәс Сафиуллин сүз алды. Ул РФ Дәүләт Думасы Рәисе Геннадий Селезневның Татарстанга визиты вакытында аның милли-мәдәни оешмалар вәкилләре белән очрашуына ни өчен татар милли хәрәкәтенең бер генә вәкиле дә чакырылмавына ачыклык кертүне таләп итте.

– Бу очрашуны оештырган Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев, Президент аппаратының милләтара мөнәсәбәтләр һәм иҗтимагый оешмалар бүлеге башлыгы Ирина Терентьева безнең алда информация ясасын, – диде Ф.Сафиуллин.

Гадәттәгечә, Фәндәс әфәнде белән килешүчеләр дә, аны якламаучылар да табылды. Сергей Осколок, мәсәлән: "Анда бит бары азчылык милләт вәкилләре генә катнашты, ә татарлар республикада яшәүчеләрнең төп өлешен тәшкил итә", – дип аңлатырга тырышты.

Ф.Сафиуллин аңа сорау белән җавап кайтарды:

– Анда катнашкан урыслар азчылык милләт вәкилләре түгелдер бит?

Алексей Колесник исә, гамәлдәге законнар нигезендә Президент аппаратында эшләүче И.Терентьева хисап тотарга тиеш түгел, дип расларга тырышты.

Шулай гадәткә кергән инде: хәтта юристлар да бер үк закон положениесен төрлечә аңлаталар. Шунлыктан, судларда да хаталар еш кабатлана. Законнарда тыелмаган һәр нәрсә рөхсәт ителә, дигән гыйбарә дә бар бит.

Информация белән хисап бер үк төшенчә түгел. Конституциядә Дәүләт Советына үзе оештырган һәм сайлаган органнар җитәкчеләренең хисабын даими тыңлау канунлаштырылган. Конституциянең 89 нчы маддәсе нигезендә дәүләт органнары һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара мөнәсәбәтләре нигезләрен билгеләү, Татарстан тупрагында барлык милләт вәкилләренең тигез хокукын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне карау шулай ук Дәүләт Советына йөкләнә.

– Без бюджеттан хезмәт хакы алып эшләүченең информациясен тыңлый алабыз, – диде Ф.Сафиуллин.

Ул хаклы иде, билгеле. Әмма депутатлар тынычлана алмадылар. Бәхәс тагын да кыза төште.

– Очрашуда татар халкы вәкиле дә бар иде. Мин катнаштым. – Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисовның бу сүзләре дөрләп янган ялкын өстенә көрәчин сипкәндәй булды. Р.Харисов, милләте белән татар булса да, очрашуда милли хәрәкәт активисты буларак катнашмаган, билгеле. Туфан Миңнуллин да мәсьәләнең нәкъ шул ягына игътибар итте.

– Әгәр Ренат Мәгъсумович татар халкы вәкиле икән, Василий Николаевич урыс халкы вәкиле. Ул чагында урыс милли-мәдәни оешмалары вәкилләренең нигә кирәге бар иде соң? Татар милли хәрәкәте Фәндәс Сафиуллин җитәкләгән Татар иҗтимагый үзәгеннән генә тормый бит әле. "Иттифак", Республика партиясе, "Суверенитет" комитеты, Милли Мәҗлес бар. Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләренең очрашуга чакырылмавы да мантыйкка сыймый, – диде ул.

Р.Харисов:

– Казанда милли-мәдәни оешмалар ассоциациясе бар. Аның составына немецләр, әрмәннәр, чуашлар, урыслар һәм башка кайбер халыклар керә. Очрашуга шушы ассоциациягә кергән оешмалар вәкилләре чакырылды. Монда закон бозу юк.

С.Осколок:

– Лихачев очрашуда урыс булганы өчен түгел, ә Дәүләт Советы Рәисе буларак катнашты.

Г.Кобелев:

– Фәндәс Сафиуллин берәүне дә гаепләми, бары информация генә таләп итә. Моның өчен халык депутатының тулы хокукы бар бит, Аңлатсыннар, ачыклык кертсеннәр.

Озак бәхәстән соң Ф.Сафиуллин тәкъдиме парламент утырышының көн тәртибенә кертелде. Әмма ул көнне депутатлар информацияне тыңлау бәхетенә ирешә алмадылар. Василий Лихачев Мәскәүдә иде. Ирина Терентьева да, ни сәбәптәндер, Дәүләт Советы бинасына килеп җитә алмады. Депутатлар бу информацияне алдагы сессиядә тыңларга килештеләр.

Тәнәфес вакытында мин берничә халык депутаты белән сөйләштем. Депутатлар күптән түгел Президентның да сәяси фиркаләр һәм хәрәкәтләр җитәкчеләрен кабул итүен искә төшерделәр. Анда да татар милли хәрәкәте вәкилләре чакырылмаган икән. Моны ничек аңларга? Очраклы рәвештә онытып калдыруы мы? Әллә инде Татарстанның суверенлыгын, дәүләтчелеген ныгытуга күп көч куйган татар милли хәрәкәте вәкилләрен санга сукмаумы? Ничек кенә булмасын, милли мәсьәләләргә кагылышлы чараларны үткәргәндә нык уйланып, бик сак эш итәсе иде. Юк кына нәрсәләрдә ризасызлык, ыгы-зыгы тудыру беркемгә дә файда китерми.

Парламент утырышында депутат Илсур Хөснетдиновнең белдерүе дә кырмыска оясына таяк тыгып бутагандай җанлылык тудырды. Илсурның әйтүенә караганда, менә өч ел инде аның һәр адымын күзәтеп торалар, телефонын тыңлыйлар, радиотелевидение тапшыруларына чакырмыйлар, сессиядәге чыгышларны күрсәткәндә аныкын кисеп калдыралар. Кемнәрдер малаен кыйнаган. Дәүләт Советына эшкә килгәндә ДАИ хезмәткәрләре 4-5 тапкыр туктатып аның машинасын тикшерәләр икән. Бу хакта И.Хөснетдинов Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачевка да, прокуратурага да язган. Шул уңайдан депутат Дәүләт Советының сайлаучылар алдындагы бурычларын үтәүнең торышын көн тәртибенә кертеп тикшерергә тәкъдим итте.

Мөгаен, депутатлык вазифаларын башкаруда каршылыкларга очраучы бер Илсур Хөснетдинов кына түгелдер. Ник дигәндә, башкалар да аны яклады лар. Ольга Ермакова, гомумән, депутат статусы турындагы законның ничек үтәлүен тикшерергә тәкъдим итте. Сүрия Усманова һич кичекмәстән җыелып аңлашу зарурлыгын белдерде. Утырышны алып баручы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиева парламетта даими эшләүче депутатларның ябык җыелышын үткәрү кулай булыр дигән фикердә торды. И.Хөснетдинв аның белән килешмәде:

– Бу мәсьәләне тикшергәндә журналистлар катнашсын. Алар безгә нинди шартларда эшләргә туры килүен сайлаучыларга җиткерсеннәр, – диде.

Ф.Сафиуллин да депутатлык вазифаларын тулы башкару өчен шартлар тудырылмавы турында сөйләде. Кайбер оешмалар, министрлыклар, ведомстволар депутат соравы буенча кирәкле мәгълүматларны бирмиләр икән.

Депутат статусы мәсьәләсе парламент утырышларында еш кузгатыла. Узган ел Вахитов районының эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре Татарстан халык депутаты Фәнәвил Шәймәрдановны кыйнап, Самосырово зираты янына илтеп ташлаганнар иде. Депутатның әйтүенә караганда, эчке эшләр министры Искәндәр Галимов низагны тудыручы милиция хезмәткәрләренең кайберләрен административ җаваплылыкка тартса да, бу эшкә соңгы нокта куелмаган әле. Суд Шәймәрдановның дәгъвасын кире какты.

Хәтта депутатлар да хакыйкатьне таба алмагач, гади адәми затлар аны ничек тапсын ди?! Статус нигезендә депутат кагылгысыз. Ә аны кыйнау турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Гомумән, башка гражданнарны кыйнарга ярый, дигән законның да кабул ителгәне юк бит әле. Шулай да кыйныйлар, атып та үтерәләр, суеп та китәләр. Югыйсә, соңгы елларда хокук саклау органнарының штаты нык арттырылды. Җинаятьчелек кими бара дип сөйләнергә яратсак та, "Эфир" программасы үтерешләр турында көн саен диярлек хәбәр итеп тора.

Татарстан дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул иткәч үк, хокукый дәүләт төзү ниятен белдерде. Законнар да шактый күп кабул ителә. Әмма алар хәзергә тиешенчә эшләми. Законнарның үтәлешен тикшерүче дә юк. Бу юнәлештә Юстиция министрлыгы да, прокуратура да, Дәүләт Советының парламент контроле комитеты да, Президентның контроль идарәсе дә тиешенчә эшли, дип раслар га иртәрәк әле.

Һәркемгә тигез караш, гаделлек, барлык гражданнарны яклау – җәмгыятьнең төп бурычларыннан берсе. Кызганыч ки, урынсызга җәберләнүчеләр, кимсетелүчеләр адым саен очрап тора. Ә янәшәдә генә ел саен берничә коттедж салучылар, бала-чагаларын, бөтен туган-тумачаларын чит илләрдә эшләнгән машиналар белән тәэмин итүчеләр, типтереп яшәүчеләр дә аз түгел. Айлык хезмәт хакы исәбенә генә андый байлыкның тупланмавы берәүгә дә сер түгел. Әмма хокук саклау органнары моңа игътибар итмиләр. Хәтта республиканың җитәкчеләре дә рәсми чыгышларында да, яши алган кеше яшәсен, салым гына түләсен, дигән фикерләрен яшермичә әйтәләр. Әлбәттә, җәмгыять үсешенең һәр этабында байлар булган. Бай кешедән көнләшергә ярамый. Ләкин байлык коррупция, кешене талау исәбенә түгел, ә фәкать намуслы хезмәт белән генә тупланырга тиеш. Башкача булганда хокукый дәүләт турында сөйләнү чеп-чи сафсата гына булып кала.

Казандагы "Электроконтакт" берләшмәсеннән бертөркем эшчеләр тормыш авырлыгына чыдый алмыйча ачлык игълан иттеләр. Алар хезмәт хакын күтәрү, эштән законсыз куу ларны туктату, социаль яклауны көчәйтү, берләшмә директорын алмаштыру таләбен куйдылар. Биредә эшләүче 460 кешенең 257се инвалидлар, төгәлрәк әйткәндә, сукырлар һәм чукраклар. Инвалидларның айлык уртача хезмәт хакы яшәү минимумыннан да түбәнрәк – бары 300 сум чамасы.

Татарстан Министрлар Кабинеты, Мәскәү район хакимияте тарафыннан оештырылган комиссияләр предприятие эшчәнлегенә анализ ясагач, коллектив белән кат-кат очрашкач кына Николай Заико җитәкчелегендәге бертөркем инвалидлар ачлыкны туктатырга риза булдылар.

Премьер-министр урынбасары А.Конюшеваның парламентта ясаган информациясенә караганда, ачлык игълан итүчеләрнең таләпләре өлешчә канәгатьләндерелгән. Н.Заико кабат үз эшенә кайтарылган. Биредә эшләүчеләрнең хезмәт хакы республиканың уртача минималь хезмәт хакы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Предприятиегә продукция җитештерү өчен дәүләт заказы бирергә килешенгән. Салым түләүдә дә шактый ташламалар ясалган.

Шулай да "Электроконтакт" берләшмәсендә мораль-психологик хәлне тәртипкә салу буенча күп эшлисе бар әле. Бүгенге гаделсезлектән халык нык ярсыган. Берләшмәнең техник җиһазлары искергән. Кул хезмәте өстенлек итә. Шунлыктан продукциянең сыйфаты түбән. Нәтиҗәдә ул сатылмыйча складларда ята. Продукция сатылмагач, берләшмәнең кассасында җилләр уйный. Блюхер урамында төзелә торган торак йорттагы фатирларны да тулысынча бу предприятиегә биреп булмаячак. Чөнки башка оешмалар да аны төзү өчен акча түләгәннәр.

Берләшмәне кризис баткаклыгыннан сөйрәп чыгару өчен күп көчәнергә туры киләчәк әле. Фикер алышу барышында депутатлар да үзләренең тәкъдимнәрен керттеләр. Т.Миңнуллин карашынча, мәсәлән, хәзергә авылда кайбер киң куллану тауарларын табу проблема булып тора. Бәлки, аларны "Электроконтакт" берләшмәсендә җитештереп, арадашчысыз-нисез авылларга илтеп сатаргадыр?!

Хәзергә бюрократия көчле әле. Юк кына нәрсәне хәл итү өчен дә чиновникларның ишекләрен кат-кат шакырга туры килә. Алар янына үтеп керү инвалидларга түгел, тап-таза кешеләргә дә бик авыр. Бер генә түрә дә сине кочагын җәеп каршы алмый, моң-зарыңны тыңларга, ярдәм итәргә атлыгып тормый. Бу фани дөньяда яшим дисәң, үзеңә тырышырга туры килә. Кеше хәлен кеше белми – үз башына төшмәсә, дип, мөгаен, юкка гына әйтмәгәннәрдер шул.

Кайбер депутатлар сукырларны, чукрак-телсезләрне тулысынча дәүләт карамагына алу зарурлыгын да искәрттеләр. Бәлки, андый вакыт та килеп җиткәндер. Алар да бит Конституция нигезендә җәмгыятьнең тулы хокуклы ватандаш-мәрдәннәре.

Әлбәттә, бу өстәмә чыгымнар таләп итәчәк. Ныклап уйланганда, һәр нәрсәне үлчәү тәлинкәсенә салып караганда кирәкле акчаны табарга да булыр. Әйтик, чорыбызның катлаулылыгын искә алып төрле бәйрәмнәрне, конкурсларны, зур акчалар тотып үткәрелә торган тамашаларны, ярышларны кимәтә төшәргә дә мөмкин. Чибәрләр конкурсында катнашучыларга да җиңел машиналар урынына хушбуйлар, затлы көзгеләр бирелсә, халык һич тә каршы килмәс, җитәкчеләрен саранлыкта гаепләмәс. Әгәр дә теге яки бу чиновник ярышларда җиңүчеләргә зуррак бүләк тапшырырга тели икән, үзенең хәләл шәхси акчасын сарыф итә ала. Бу инде чын мәгънәсендә Президент, хөкүмәт яки хакимият башлыгы, завод директоры призы булачак. Ә шәхси мөмкинлеге булмаган түрә ярышлар үткәреп көчәнмәячәк.

Үз предприятиеләрендәге хәл турында җитди сөйләшү барганда Дәүләт Советының утырышлар залында "Электроконтакт" берләшмәсеннән килгән берничә вәкил дә утырды. Аларның күңелләре боек күренде. Хәер, шатланырлык сәбәп тә юк иде шул. Беренчедән, ул инвалидларны гариплек, җан сызлануы газапласа, икенчедән, мөгаен, кайткач нәрсә ашармын, гаиләмне ничек туендырырмын, дип баш ваткандыр алар. Ул гарипләрне язмыш кочагына ташламыйсы иде. Язмыш тарафыннан болай да кимсетелгән гражданнарын яклар га сәләтле җәмгыять кенә гуманлы була. Дәүләт күләмендә шундый программаны булдырып, тизрәк аны гамәлгә ашыра башлауга керешәсе иде.

Каенсар урманнарында булган кеше бу якларның хозур табигатен хәтереннән һич тә җуймас, онытмас. Шагыйрь Нәҗип Мәдияров әнә шул гүзәл якларда – Әтнә районының Кызыл Утар авылында туып үскән. Колхозда эшләп, көтүче малай булып йөргәннәрен ничектер эчке бер горурлык белән сөйләргә ярата ул. Хәер, күңеленә җыйган шигъри гөлләр бәйләмен шагыйрь, бәлкем, нәкъ шул болыннардан-кырлардан да җыйгандыр.

Казан дәүләт университетында уку, журналистлык хезмәте аны каләмгә тагын да җитдирәк төстә үрелдерә. 1960 елда "Чык бөртекләре"исемле беренче шигырьләр җыентыгыннан соң Н.Мәдияровның ике дистәдән артык китабы басылып чыга. Җитмеш яшен шагыйрь әнә шундый мул җимешләр белән каршылый. Без дә аны шушы олуг бәйрәме белән тәбриклибез, төрле елларда язылган шигырьләреннән бер бәйләмне укучыларыбызга тәкъдим итәбез.



Йолдызлар

Планетадыр, бәлки, кометадыр,
Күпләр өчен алар йолдызлар.
Төнге күкне бирелеп караганда,
Минем җанда калмый кайгы-зар.

Миллиардлаган чакрымнардан алар
Балкыйлар бит – яхшы аңлыйбыз.
Ә без кайчак янәшәдә йөргән
Кешегә дә күрәнә алмыйбыз.

1986.

Рәхмәт, тормыш

Рәхмәт сиңа, рәхмәт,
гүзәл тормыш,
Бүгенгемә кадәр китердең.
Бу дөньяның миңа ачысын да,
Төчесен дә авыз иттердең.

Нәҗип МӘДИЯРОВ

Салкын гына озатып булмый икән
Туган җирнең салкын бозын да...

Бозлар акканда

Инеш буе халык белән тулы,
Ташкын суга күзләр текәлгән.
Яз тудырган шаулы тамашаны
Көткән идек инде күптәннән...

Каерылып купты әнә анда
Бәкеле боз – күпер алдында.
Бу яклардан китәр минутлары
Килеп җитте менә аның да.

Кузгалды ул инде соңгы юлга,
Һөҗүменә язның түзмәде.
Карап калдык аннан
Яшь киленнәр
Су китереп йөргән эзләрне.

Карап калдык...
Күздән югалды ул
Борылмалар аша узды да.
Салкын гына озатып булмый икән
Туган җирнең салкын бозын да.

1958.

Чишмә булсаң иде

Җырлап аккан чишмә
Авыр көрсенә күк:
– Инеш булсаң иде!
Суларыңны зур-зур елгаларга
Илтеп куйсаң иде!

Ярсып ага инеш,
Сөйли ул да гүя:
– Елга булсаң иде!
Суларыңны шаулы диңгезләргә
Илтеп койсаң иде!

Җәелеп ага елга,
Үз язмышын тиргәп:
– Диңгез булсаң иде!
Иксез-чиксез, данлы океанга
Кушылып торсаң иде!

Шаулый диңгез, йөгерек
Дулкыннары шыңшый:
– Чишмә булсаң иде!
Дөнья буйлап, матурлыкны күзләп,
Агып узсаң иде!

1966.

Гомер иткән нигез

Күчерделәр картны яңа йортка.
Чирәм баскан иске өй эзен
Шулай да ул бик еш карап китә
Үзе гомер иткән нигезен.

Нәрсә тарта икән аны монда?
Сөенечме, әллә кайгымы?
Сугышларга киткән вакытымы?
Әллә аннан кайткан чагымы?

Килгәндер ул әллә хыялланып
Очратырга егет чакларын:
Кыңгыраулы атта бар авылны
Шаулатып кыз алып кайтканын.

Уйларында, бәлки, дөнья куйган
Шул җанашын сагыну көчледер.
Әрнү тулы, сулган күңеленә
Монда дәва табылыр төследер.

И замана! Эзе генә калган
Челтәрле, зур, сары капканың.
Карап тора абзый сүзсез генә
Үзе салган нигез ташларын.

Ул бит шушы йортны гөрләтергә,
Ялыкмыйча, көн-төн эшләгән.
...Күчергәннәр картны яңа йортка,
Ә йөрәгә аның күчмәгән.

1968.

Ромашкалар иләндә

Ромашкалар утравына килдем,
Тирә-ягым сафлык диңгезе.
Әйтерсең лә, хуш ислардән тора,
Гел аклыктан тора җир йөзе.

Ни тарта соң мине бу тугайга?
Саф һавамы, кошлар җырымы?
Шушы җирдә, шушы тирәләрдә
Яшьнәп калган яшьлек чорымы?

Йөрәкләрне җилкендереп үткән
Ул чакларны фәкать күзаллыйм.
Әмма шушы ак дәрьямны тагын
Күрүемә мең кат ризамын.

Акрын гына бии ромашкалар,
Гомеремә ямь алам алардан.
Бәлки, шулар өйрәткәндер мине
Аерырга акны карадан.

1976.

Чакма чагып...

Ут эчендә калды чал Аурупа,
Янды шәһәр, янды авыллар.
Ул елларда безнең йөрәкләрне
Өтеп үтте утлы давыллар.

Шул чакларда туган утлы уйлар
Әле дә чыгып бетми башлардан.
Ут эчендә тордык, үзебез утны
Чакма чагып алдык ташлардан.

1978.

Балачак

Болыннарга алып чыгып йөрдем,
Инешләрдә аны коендырдым.
Гөл-чәчәкле гүзәл аланнарда
Хуш исләргә, ямьгә туендырдым.

Ашкынганда биеклеккә, аны
Алып мендем агач башларына.
Чишмәләргә кушылып җырласын дип,
Алып төштем һәм тау асларына.

Сеңеп калды басу үрләрендә
Иген исе аңа мәңгелеккә.
Арыш, бодай үскән кырлар аша
Юлны ачтым аңа гаделлеккә.

Балачагым!
Гомерем юлы буйлап
Ерак киткәч ныграк аңладым:
Кадерләдем сине аңышмыйча,
Ә кадереңне белә алмадым.

1981.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, сөер тормыш,
Мин һаман да синең куйныңда.
Эссеңә дә, суыкларыңа да
Кинәндердең тормыш юлымда.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, шаулы тормыш,
Һаман алга алып барасың.
Рәхәтлекнең кадерен белдерим дип,
Михнәтне дә миңа табасың.

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, кырыс тормыш,
Җиңел түгел сине кичәргә.
Бер елмайтып, бер моңайтып мине,
Өйрәтәсең һаман яшәргә.

1989.

Бусага

Урыны ишек төбендә,
Язмыш кушкач – ни чара?!
Безне гел түргә үткәрә
Үзе аша бусага.

Киң дөньяга чыкканда да
Аның аша узасың.
Читләрдә: "...Их, үз бусагам
Булсачы!" – дип куясың.

Әйтәләр: "...Ул явыз җан бит –
Бусагамнан узмасын.
Аннан үтеп, йортыбызның
Гүзәллеген бозмасын".

Һәм әйтәләр: "...Якын дус бит,
Шулай да килгәне юк.
Бусагамнан хет бер тапкыр
Атлап та кергәне юк".

Гомер буе әнә шулай
Хөрмәтле ул бусага.
Дәрәҗәсе өстә аның,
Үзе түбән булса да.

1990.

Өйрәттеләр безне

Өйрәттеләр безне күндәмлеккә,
Сүрәнлеккә,
Өйрәтәбез, диеп, бердәмлеккә, –
Ә без эчтән генә ачу җыйдык.

Өйрәттеләр безне тел тыярга,
Кул куярга,
Өйрәтәбез, диеп, аң җыярга, –
Ә без эчтән генә ачу җыйдык.

Өйрәттеләр безне кансызлыкка,
Сансызлыкка,
Өйрәтәбез, диеп, чын дуслыкка, –
Ә без эчтән генә ачу җыйдык.

Ул ачулар вулкан кебек ташый,
Халык һаман илне каргап ярсый,
Кайберәүләр берсен-берсе "ашый".
"Рәхәт" яшәп "гүзәл" СССРда,
Өйрәндек без фәкать әнә шуңа.

1997.

Рәис ШАҺИ сурәте.

шигырь нечкәлек билгесе белән языла

Гаяз ИСХАКЫЙның Милли кыйблабызны

Шушы елның февралендә Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулды. Әмма, ни сәбәптәндер, узган ел без аның иҗат эшчәнлеге башлануга 100 ел тулу вакыйгасын онытып җибәрдек. Мәгълүм ки, әдипнең чагыштырмача җитлеккән беренче хикәясе – "Тәгаллемдә сәгадәт" 1897 елда иҗат ителә. Яңадан бер елдан "Көләпүшче кыз" әсәре языла.

Халкыбыз "Соң булса да, уң булсын!" ди. Шуңа күрә 1998 елны Г.Исхакыйның тууына 120 ел дип кенә түгел, ә иҗат эшчәнлеге башлануга 100 ел дип бәйрәм итү дә хата булмастыр.

Бөек әдипкә үз гомеренең түгәрәк даталарын илдә юньләп уздыру мөмкинчелеге насыйп булмый. 30 яшен ул патша төрмәсендә каршылый. 40 яше ыгы-зыгылы инкыйлап елларына туры килә. Аннан инде мөһаҗирлек чоры башлана. Әмма илдә мөмкинлек булмаса да, читтә яшәгән милләттәшләребез Гаяз Исхакыйны онытмыйлар. Чөнки ул бу игътибарны, милләт мәнфәгатьләре өчен фидакарьләрчә көрәшеп, үзе яулап ала.

1937 елның башларында, аеруча әдипнең туган ае февральдә Гаяз Исхакыйның әдәби иҗат эше башлануга 40 ел тулу илдән читтә яшәгән татарлар тарафыннан киң күләмдә билгеләп үтелә. Япониядә, Кытайда, Кореядә, Германиядә, Эстониядә, Финляндиядә һәм башка илләрдә төрле кичәләр, тантаналар уздырыла. Матбугатта Г.Исхакый хакында төрле язмалар дөнья күрә. Мәсәлән, күренекле шагыйрә, педагог Сания Гыйффәт "Халыкның сулый торган һавасы" исемле мәкаләсендә (ул, безнең тарафтан әзерләнеп, "Сөембикә" журналында хәзерге чор укучыларына да ирешкән иде. Карагыз: 1992 ел, 11 нче сан, 19-20 б.) әдипнең 40 еллык әдәби иҗатына бер караш ташлый, аңа хас аерым үзенчәлекләрне күрсәтә. Юбилей тантаналарының иң зурысы 1937 елның 5 мартында Варшаудагы Шәрекъ институтының зур залында үткәрелә. Анда Польшаның дәүләт эшлеклеләре, галим-әдипләре, шулай ук төрле илләрдән килгән кунаклар, күренекле милләттәшләребез катнаша.

1928-1939 елларда Берлинда чыгып килгән "Яңа милли юл" журналында (әүвәл ул "Милли юл" исеме белән йөртелә) Г.Исхакыйның бу бәйрәменә мөнәсәбәтле шактый гына материаллар дөнья күрә. Аларда бу затның бөеклегенә, гаять нәтиҗәле һәм күпкырлы эшчәнлегенә, милли-азатлык хәрәкәтенең дөньякүләм танылган лидер булуына басым ясала.

Журналның 1937 елгы 3 нче (108) санында Финляндиянең Тампере каласында Г.Исхакый хөрмәтенә уздырылган кичә хакында мәкалә урнаштырылган. Анда бөек әдип үзе дә катнаша. Шул ук санда язучының иҗат эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу уңае белән алынган тәбрикнамәләрнең бер өлеше урнаштырылган. Алар, нигездә, Ерак Шәрекътә яшәүче милләттәшләребезнең котлаулары. Бу аңлашыла да. Чөнки Г.Исхакый моңа кадәр генә Япуния, Корея, Кытай якларында йөреп кайта, андагы милләттәшләребезне туплауга, милли рухта тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә, "Милли Байрак" гәзитен оештырып җибәрә. Бу хакта Рокыя Дәүләткилде 1988 елның 19 августында Минһаҗ ага Исмәгыйлигә язган хатында ("Мирас". 1996, N 5-6, 263 б.) менә болай ди: "Мин яшүсмер чагымда аның (ягъни Г.Исхакыйның – Х.М.) әсәрләрен бик яратып укый идем. 1933 елның җәендә ул Япуниягә, Тукиога килде. Мин андагы татар мәктәбендә урыс һәм инглиз телләре укыта идем. Бу шәһәрдә безнең халык шактый бар иде. Сәүдә итәләр иде. Гаяз абзый, килүе белән, халыкны берләштерү эшенә кереште. 1935 елның февраль 4еннән 11енә кадәре Япуния, Корея һәм Кытайда яшәүче безнең халыкның корылтаен уздырырга муаффәкъ (мөмкин – Х.М.) булды. Шунда бер атналык гәзит тә чыгарырга карар кабул ителде. Мәркәз (үзәк – Х.М.) идарә төзелде. Бу эшләр барысы да халыктан җыелган акчага вөҗүдкә килде (башкарылды – Х.М.). Ибраһим Дәүләткилде (бу һәм Рокыя ханым – атаклы милләттәшебез Надир Дәүләтнең әти-әнисе – Х.М.) белән мине шунда эшләргә сайладылар. Гаяз абзый 1936 елның март аена кадәр Мукден шәһәрендә безнең янда булып, безне гәзит чыгару эшенә өйрәтте һәм Варшауга кайтып китте..."

Укучыларга тәкъдим ителүче бу тәбрикнамәләр Г.Исхакыйның шәхесен һәм эшчәнлеген тулырак һәм тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Язучыны "бөек җитәкчебез", "юлбашчыбыз", "иң зур әдибебез", "кыйбла күрсәтүче" дип атау да күп нәрсә хакында сөйли. "Яңа милли юл" журналының 1932 елгы 2 нче санында титул биттә мондый юллар бар: "Бер милләтне юк иткән нәрсә – ул милләтнең үз-үзенә булган ышанычының югалуыдыр". Г.Исхакый, нинди генә кыен шартларга эләксә дә, оптимистик зат булып кала, шушы рухны халыкка, укучыларга да сеңдереп килә. Шунысы мөһим: тәбрикнамәләр дә татар халкының якты киләчәгенә, бәйсезлеккә ирешәчәгенә тирән ышаныч рухы белән сугарылган. Бу язмалар чит мөмләкәтләрдә яшәгән милләттәшләребезнең тарихын, мәдәни тормышын күзаллау ягыннан да игътибарга лаек.

"Яңа милли юл" – гарәп хәрефләре белән басылган татарча журнал. Биредә без мөмкин кадәр андагы язылыш үзенчәлекләрен сакларга тырыштык. Аңлатмалар һәм искәрмәләр җәяләр эчендә бирелде.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

YAÑA MILLI YUL

Chefredakteur und Herausgeber: A. Ishaki

Jahrg. 9	März 1937	Nr. 3 (108)

REDAKTION „YAÑA MILLI YUL"
Berlin-Charlottenburg 1
Postfach Nr. 8

● "Яңа милли юл" журналының тышлыгы.



● Гаяз Исхакый.

Гаяз әфәндened 40 еллык хезмәте мөнәсәбәте илә тәбрикнамәләр

Гаяз әфәндедән туган көненә тугры 10 февральдән бирле бер туктамаенча тәбрик телеграмлары вә мәктүбләре килеп торадыр. Хакыйкатәндә (чынлыкта – Х.М.) 40 еллык бер дәвер аз бер заман түгел икән; мөһаҗирлекнең авырлыгына карамастан, Гаяз әфәндедәнең бу хатирә көненә бөтен илдәшләр мәхәббәт вә сөенеч берлә кушылалар. "Милли Байрак" 26 февральдә чыга торган санын боңа багышлаячак, бөтен Ерак Шәрекъ мәхәлләләрендә Гаяз әфәндедәнең туган көненә мәрасимләр (тантаналар – Х.М.) уздырылачак, мөмкин кадәр үз әсәрләрендән берсе уйналачак, дип хәбәр бирәләр. Ерак Шәрекъ мәркәзе Гаяз әфәндедәнең кыска тәрҗемәи хален, әсәрләренең исемләре, язылу һәм басылу еллары берлә бергә, пөхтә бер брүшәр (брошюра – Х.М.) халендә кульязма басмасы тараткан; шулай ук төрле дәверләрдә алдырган биш рәсемен дә басдырган. Гаяз әфәнде үзе Корбан бәйрәмен һәм бу көнне Финляндиянең Тампере шәһәрендә уздырырга чакырылган булганга, Тампереда 25 февральдә аның 40 еллык әдәби хезмәте башлануы мөнәсәбәте берлә бер кичә ясалачак, – дип хәбәр бирделәр.

Идарәмез аркылы вә Гаяз әфәндедәнең үзенә килгән бик күп тәбрикләрнең бөтенесен, мәгаттәссеф (үкенечкә күрә – Х.М.), мәҗмугамызда йирләшдерә алмыйбыз. Боның өчен күндерүче (җибәрүче – Х.М.) оешма, Милли идарә, түгәрәкләр вә бик күп хосусый кешеләрнең барысының да гафуларын үтенеб, тәбрикләре өчен Гаяз әфәнде исемендән бик күп рәхмәтләр укыймыз. Идарәмезгә табшырылган тәбрик хатлары шулар: Ерак Шәрекъ мәркәзендән; Ерак Шәрекъ мәркәзе мәгариф шөгъбәсендән (бүлегеннән – Х.М.); "Милли Байрак" идарәсендән; Харбин Милли идарәсендән; Харбин яшьләр түгәрәгендән; Мукден төрк-татар мәдәнияте җәмгыятенең яшьләр түгәрәгендән; Мукден хатын-кызлар оешмасындан; Кумамуту (Ерак Шәрекътәге шәһәр – Х.М.) Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте исемендән; Коби (Япуниядәге шәһәр – Х.М.) милләтчеләре исемендән; Тукио Идел-Урал мәдәнияте җәмгыятендән; Мукдендан Рокыя туташ Мөхәммәдишдән; Мукдендан Ибраһим Дәүләткилдедән (Болар "Милли Байрак" гәзитен чыгаручылар. (Х.М.); Йукаһамадан (Япуниядәге шәһәр – Х.М.) Габделнафигъ гаиләсендән; Нагоя Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыятендән; Варшаудан, шәркыятче (Шәрекъне өйрәнүче – Х.М.) ләһ гәнҗләре (поляк яшьләре – Х.М.) дәрнәге (оешмасы – Х.М.) Идел-Урал шөгъбәсендән.

Телеграмлар: Фузан (Кореядәге Пусан шәһәре булса кирәк – Х.М.) милләтчеләрендән; Ерак Шәрекъ мәркәзендән; Мукденда корылтай ачылуга ике ел булу сәбәбле тубланган мәҗлесдә хазир булучылар (катнашучылар – Х.М.) исемендән; Гирин төрк-татарлары исемендән; Шанхай мәхәлләсендән.

Түбәндә бу тәбрик хатларының берничәсен басамыз:

Ерак Шәрекътә яшәүче Идел-Урал төрк-татар мөселманларының дини-милли мәркәзе башкармасы рәисемез Гаяз Исхакый җәнабларына!

Мөхтәрәм Гаяз әфәнде! Милләтемезнең яшь буынын милли рухда тәрбияләү вә милләтемезнең картрак гонсырлары (өлешләре, төркемнәре – Х.М.) арасында милләтемезнең тәрәкъкыйсе юлына киртә булып торган мөтәгассыйблыкларны (киртәләрне, артталыкны – Х.М) алып ыргыту вә милләтемезнең истикъбалын (киләчәген – Х.М.) яктырту гаясын (теләген – Х.М;) үзегезнең милли вазыйфагыз диб белдегез вә шул максадыгызга ирешүгә дөньяның иң көчле коралы булган каләм, әдәбият аркылы арыгап, талгап, йөдәгән милләтемезгә әдиблек хедмәтегезгә бу ел кырык ел тулу мөнәсәбәте берлә мәркәз башкарма сезнең милләтемез өчен эшләгән бу әдәби хезмәтегезнең кырык еллык юбиләсен (юбилеен – Х.М.) җандан тәбрик итә. Шуның берлә бергә бу юбиләнең туган көнегезгә тугры килүе уңае берлә сезнең туган көнегезне дә тәбрик итеб, сезгә сәламәтлек вә максадымызга ирешүдә армый-талмый эшләргә бөек Тәңредән куәт тели. Киләсе алтын юбиләгезне мөстәкыйль илемез Идел-Уралда уздырырга мөяссәр булуымызны (ирешүебезне – Х.М.) олуг Тәңредән ялварып сорый.

Мукден. 8 февраль, 1937 ел.

Бөек хөрмәт вә ихтирам илә рәис өчен:

Әхмәдшаһ ГЫЙЗӘТУЛЛА.

Кятиб (секретарь – Х.М.): Ибраһим ДӘҮЛӘТКИЛДЕ.

Бөек әдимебез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларына

Хөрмәтле Гаяз әфәнде!

Рус истилясы (басып алуы – Х.М.) нәтиҗәсендә милли мәдәнияте юлында үсүдән туктаб калган милләтемезне озын йокысыңдан уяту эшенең зур адымлар белән алга китүенә сәбәпче булган әдәби хедмәтегезнең кырык еллык юбиләсе берлә тәбрик итү без мәгариф эшчеләре өчен сөенечле бер вазыйфадыр.

Бөтен әдәби әсәрләрегез аша милләтемезне үсдерергә, барачак милли кыйбласын билгеләргә тырышуыгыз берлә сез илемезнең мәшһүр әдибләре арасында үзегезгә генә хас вә бик шәрәфле урын тотасыз. Үзегезнең кыйммәтле әсәрләрегез берлә милләтен сөйгәнләрнең күңелендә, әдәби ләззәтдән башка, милләт сөүгесе (сөюе – Х.М.) сызыкларын сызасыз. Сезнең әдәби әсәрләрегез садә теле, килешле җөмләләре, телемезнең матурлыгын, байлыгын күзгедә күрсәткәндәй тасвир иткәнгә, чит илдә яшьлегебезне әдәбиятымыз берлә таныштырганда, сезнең әдәби әсәрләрегез төмәл (нигез – Х.М.) ташы урынын тота-

Күрсәтүче әдип

дыр вә яшьлегебезнең (яшьләребезнең – Х.М.) күңелен илемезгә вә аның тормышына баглыйдыр.

Милли кыйблабызны күрсәтү, дошман аягы астында табталган мөкаддәс милли байрагыбызны күтәрүдән башка, яшьлегебез өчен рухани азык хазерләвегез, сезнең милләтебезгә иткән бөек хедмәтләрегезне тагы да йүксәлтәдер (күтәрәдер – Х.М.) вә милләтебезнең сәгадәте намена (исемена, шәһрәтенә – Х.М.) иткән чиксез хезмәтләрегезгә бу кырык еллык әдәби хедмәтегезнең дә кушылуы яшь гонсырыбызның (буыныбызның – Х.М.) күңел күзендә сезнең хөрмәтегезне тагы да бөекләтәдер, сезне вә сезнең хедмәтләрегезне аларның рухани барлыкларының җанлы бер кисәге ясыйдыр.

Сез күрсәткән милли кыйблабызга яшь буынны җитәкләүче без мәгариф эшчеләре сезнең бу сөенечле бәйрәмегезгә кальбән (чын йөрәктән – Х.М.) кушылып, милләтебезнең сезнең кеби бөек шәхесен сәламли алу шәрәфенә ирешә алуыбыз берлә үзебезне бәхетле саныйбыз вә сезне 40 еллык юбилегез вә туган көн бәйрәмегез берлә тәбрик итеб, киләсе 50 еллык юбилегезне һәм күб туган көнләрегезне истикъылалын (бәйсезлеген – Х.М.) кайтарыб алган үз илебездә каршы алуызны телибез.

Мукден, 8 февраль, 1937.

Бөек хөрмәт илә: Мәркәз мәгариф шөгъбәсенең рәис урынбасары: Рокыя Мөхәммәдиш.

Кятиб: Разия Дәүләткилде.

* * *

"Милли Байрак" гәзитәсе, Мукден.

"Милли Байрак" гәзитәсенең мәхсиссе (коручысы – Х.М.) мөхтәрәм Гаяз әфәнде Исхакый җәнаблары!

Хөрмәтле Гаяз әфәнде!

Милли үзлегебезне саклау юлында армый-талмый хедмәт итүегез нәтиҗәсендә мәйданга килеп, Ерак Шәрекъкә сибелгән мөһаҗирәтебезнең рухани азыгы дәрәҗәсенә ирешкән "Милли Байрак" гәзитәсенең идарәсе сезне әдәби хедмәтегезнең кырык еллык бәйрәме берлә тәбрик итәдер вә шул юбилә көненә туры килә торган туган көнегез берлә котлыйдыр.

Каләм хедмәтенең орлыкларын вә истигъдадның (сәләтнең – Х.М.) кыйммәтен аңлаганга, сезнең бу сахәдәге (мәйдандагы – Х.М.) кырык еллык хедмәтегезне вә шул юлда күргән бөтен зәхмәт вә мәшәкатьләрне чын күңелдән тәкъдир итәдер. Сезгә вә сезнең хедмәтегезгә булган хөрмәтене күрсәтү йөзендән "Милли Байрак" бер санына сезнең кырык еллык юбилегезгә багышлаб чыгаруны карар итәдер. Бу озын дәвер эчендә милли матбугатымыз дөньясына чыккан әсәрләрегезнең бик азын гына кулда итә алганлыктан, сезнең бу аландагы хедмәтегезнең зурлыгын вә бу хедмәтнең биргән сәмәрәсен (җимешен, нәтиҗәсен – Х.М.)тулы көенчә күрсәтә алмаячагына тәәссеф итәдер (үкенәдер – Х.М.) вә сездән бу кимчелеге өчен гафу итүегезне үтенәдер.

Илемездән еракда бөек әдибе хөрмәтенә ясала торган зурлауның күңел теләгән кадәре зур вә бай булмавына сыкраб, сезнең әдәби хедмәтегезнең илле еллыгын вә милли истикълалыбыз елында көрәшүегезнең тагы да бөегрәк юбилесен мөстәкыйль илебез Идел-Урал да каршы алуны сораб олуг Тәңрегә ялварадыр.

Бөек ихтирам вә кардәшлек сәламе берлә: "Милли Байрак" идарәсе.

Мөхәррире: Ибраһим Дәүләткилде.

Кятиб: Рокыя Мөхәммәдиш.

* * *

Харбин, февраль, 1937 ел.

Бик мөхтәрәм вә кадерле Гаяз абзый!

Без төрк-татар яшьләре хазерге көнне үзебезнең түгәрәкләребез, милли сәхнә вә милли көтебханәләребез тирәсендә оешыб, шулар аркылы халкыбызга мәхәббәт бәйләб, кулыбыздан килгәнчә эш күрсәтү вә милләтемез намена зуррак эшләр дә эшләргә талпынуыбыз берлә үзебезнең милли әдиб вә шагыйрьләремезгә бурычлы булсак, шулар җөмләсендән сезгә аерым рәвешдә зур бурычлыбыз. Чөнки сез, кадерле Гаяз абзый, безнең иң зур әдибемез. Без сезнең исем вә хедмәтегезне ата-аналарыбыз, ага вә апаларыбыз авызындан ишетеб үскәнебез халдә, сезнең бөек хедмәтегезне хазер үзебез дә күреб, аңлаб, белеб торамыз.

Безнең барыбыз да диярлек сезнең бу якларга килеб чыккан вакытыгызда якындан күрү вә кыйммәтле сүзләрегезне ишетү бәхетенә дә ирешде. Шунлыкдан сезнең әдәби хедмәтләрегезгә 40 ел тулу бәйрәмендә сезнең тирәдә яшәүче миллэтдәшләребез, сезнең берлә бергә яңабе утырыб, шадланыкан вакытда, без дә җөгърафый араның ераклыгына карамасдан, сезне үз каршыбызда, гүя сез безнең янда булган кеби итеб күрәбез.

Киләчәкдә халкыбызга хедмәт итү уйлары берлә рухан (рухани яктан – Х.М.) канатланган бу яшьләр, әлбәттә, сезнең кеби җитәкчеләргә бик мохтаҗбыз. Безгә юл күрсәтеб, юл сызыб, дөрест вә тугры юлга димләб, шуңа өндәүче булмаса, без бер кыйблага таба бара алмас идек, яңлышыр идек, таралыр идек... Ходага шөкер, без бу якдан бәхетлеләрбез: бер Харбин яшьләренә генә түгел, мөһаҗирәтдәге барлык яшьләребезгә исем вә хедмәтегез берлә рух биреб торучыны без сезнең кыйммәтле шәхесегездә күреб торабыз. Котлы булсын олуг бәйрәмегез!

Бу көндә сезгә нинди генә мәдхияләр укылса да, аздыр. Сез, кадерле Гаяз абзый, үзегезнең зур эшләрегез берлә миллэтнең вә аның балаларының самими ихтирамын, мәхәббәтен, бик хаклы рәвешдә казандыгыз. Яшәгез! Яшәсен Идел-Урал төрк-татар халкының милли әдәбияты!

Олуг ихтирам берлә Харбин төрк-татар яшьләре түгәрәге намена мувәккать (вакытлы – Х.М.) рәис: Галимҗан Таһир.

Кятиб: Халидә Әхмәди.

* * *

Бөек әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларына

Хөрмәтле Гаяз әфәнде!

Без, Мукден Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте янындагы "Хатын-кызлар оешмасы", әдәби хедмәтегезнең кырык еллык юбилесе вә шул ук көнгә туры килә торган туган көнегез берлә чын күңелемездән сөенеб вә бөтен йөрәгебездән сезне хөрмәт итеб тәбрик итәбез.

Без хатын-кызлар өчен төрк-татар хатын-кызына хөрмәтле вә шәрәфле урын биргән әдибнең язучылыгының тарихи бәйрәме безнең зур шадлыклы бәйрәмебездер.

Сез "Кәләпүшче кыз", "Теләнче кызы" берлә төрк-татар хатынкызының табталган намусын пычракдан тазарттыгыз, аның йөрәгенең сафлыгын, үзенең эшлеклелеген, булдыклылыгын күрсәттегез. "Мөгаллимә"гез, "Остазбикә" вә "Зөләйха"ларыгыз берлә төрк-татар хатынкызының каһарманлыгын, фидакарьлеген җанландырып, аның хөрмәтен күрсәтдегез. Бөтен әсәрләрегездә төрк-татар хатынкызын олуглау пәрдәсе аркылы күрсәтеб, төрк-татар хатынкызының йөрәгендә үзегезгә тирән ихтирам уятдыгыз.

Дошман аягы астында табталган байрагыбызны күтәрүдә без хатын-кызларда да тигез хокук биреб, безне дә дини, милли үзлегебезне саклау көрәшебезнең җанлы әгъзалары итүегез берлә, хатынкызларның йөрәгендә тирән тәшәккер (рәхмәт – Х.М.) тудырдыгыз.

Бөтен хедмәтләрегез эчендә хатын-кызларга хөрмәтле урын бирүегез вә рухани азык бүләк итүегез өчен бу олуг бәйрәмегез көнендә хатын-кызлар исемендән самими тәшәккерләремезне гарыз итәмез (белдерәбез – Х.М.) вә киләчәк илле еллык юбиләгез вә күп туган көнләрегезне хөр илебездә каршы алуыгызны телибез.

9 февраль, Мукден.

Олуг хөрмәт илә:"Мукден хатын-кызлар оешмасы".

Рәис: Рокыя Мөхәммәдиш

Кятиб: Сара Нияз.

Идарә әгъзалары: Мәрьям Мәдә(рр)ис, Рәкыйбә Явыш, Заһидә Гыйззәтулла, Разия Дәүләткилде.

* * *

Финляндиядән телеграм: "25 февральдә Гаяз әфәнденӗң әдәби эшләренә кырык ел тулу мөнәсәбәте илә Тампере төрк-татарлары тарафыннан банкет бирелде. Сәгать 8дә башланган бу банкет зур бер милли бәйрәм төсендә икегә кадәр дәвам итте. Мортаза".

Текстларны басмага профессор Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ әзерләде.

● Татарстан Берләштерелгән дәүләт музеенда Г.Исхакыйга багышлап ачылган күргәзмәгә куелган экспонатларның кайберләре.

Тамаша залары чакыра

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

27 февраль – "Җүләрләр йорты" (З.Хәким)
28 февраль – Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулуга багышланган кичә.
1 март (көндез) – "Кылый Кирам балдагы" (Аманулла)
1 март (кич) – "Хушыгыз" (Т.Миңнуллин)
2 март – Фәнис Яруллинның 60 яшьлегенә багышланган кичә.
3 март – "Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясенең 70 еллыгына багышланган кичә.
4, 5, 6 март – "Каравыл, талыйлар!" (Г.Камал)
Кече зал
5 март – "Карак песи" (С.Латыйпов)

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

27 февраль – "Син бит минем бергенәм" (И.Мәхмутова).
28 февраль – "Гайфи бабай, өйлән давай" (Г.Зәйнашева).
1 март (көндез) – "Ак төүбә, кара төүбә" (Т.Миңнуллин)
1 март (кич) – "Бәхетле килен" (Х.Ибраһим)
4 март – "Сакла сөюне, ташлама беркү" (Х.Тәхвәт)
5 март – "Сынган беләзек" (Р.Сәгъди)
6 март – "Җаным җил түгел сиңа" (Г.Зәйнашева)

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

27, 28 февраль – "Кармен" – сюита (Р.Щедрин)

Зур концерт залы

28 февраль – Татарстанның, Русиянең, Казакъстанның халык артисты, профессор Ф.Мансуровның юбилей кичәсе.
4 март – Орган музыкасы концерты. А.Фисейский башкара. Программада Д.Циполи, И.Бах әсәрләре.
6 март – Татарстанның халык уен коралары оркестры концерты. Т.Хренников әсәрләре башкарыла (автор үзе катнаша). Солистлар П.Болдин, М.Рыба, Р.Галимова. Дирижер – А.Шутиков.

Татар яшьләр театры

27 февраль – "Кәрпе малае дуслар эзли" (Р.Корбан), А.Гайдар исемендәге мәдәният йорты.
28 февраль – "Без барабыз, барабыз, барабыз" (Н.Коляда), премьера, "Казан" санаторие.
3 март – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), Юдино бистәсендәге 13 нче балалар бакчасы.
4 март – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), Г.Ибраһимов исемендәге гимназия.
5 март – "Кадерне белмәүче бурсык". Юдино бистәсенең мәдәният йорты.
6 март – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 155 нче мәктәп, кичен дискотека.

Курчак театры

27 февраль – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).
28 февраль – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).
1 март – "Дюймовочка" (Х.Андерсен)
5 март – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).
6 март – Паппет шоу.

Цирк

27 февраль – 6 март – Мәскәү циркы йолдызлары тамашасы.

(Дәвамы. Башы 8 нче санда).

Үзенең мәктәбендә татар сыйныфлары бөтенләй беткәч, Казан шәһәрендә ярым-йорты гына хәлдә калган берденбер мәктәпкә укытырга урнашырга дип уйлап та карамады Нурания Габбасовна: урын да юк, үзен гадәттән тыш туарылган, таркауланган кеше итеп тә хис итте. Шулай да барыбер берәр эш табып урнашмый хәле юк, яшәргә кирәк. Менә шундый хәл инде, бу илдә хатын-кыз акча табу мәсьәләсендә дә ире белән кара-каршы җигелеп, дөресрәге, рәттән җигелеп тартырга тиеш. Әбисенең әнисе, оныгы – кыз баланың, шулай ярты гомерен, йөрәген бетереп, чит кешеләр арасында эшләп йөргәнен белсә, кызганудан кабердә борсаланып ятар иде.

Бик тырыша торгач, алай да китапханәгә урнаша алды Нурания Габбасовна. Рухланып эшли алмады ул анда, шулай да биш-алты ел гомере үтте. Якты истәлек булып бергә эшләгән иптәшләре һәм теле?

Ә инде мәктәптә бөтенләй дә татар теле укытучысы юк икән, җавап шулай ук әзер: килүче юк. Кире борып җибәрдек, дип әйтмәсләр бит инде...

Менә шулай, нигә яшьлекне искә төшермәскә әле, урыс мәктәбендә булса да яңадан татар телен укытып карарга, дип эшкә урнашканда ниндирәк шартларга килеп эләгәсен Нурания Габбасовна бик аз гына күз алдына китергән икән.

Янәдән мәктәпкә эшкә баргач, Нурания шул үзе белгән мәктәпне дә, элеккеге укучыларны да тапмады, юк иде алар. Мәктәпне җенпәриләр алыштырып куйганнармыни?! Тышкы ишектән үк як-ягыңа караштыргалап, сакланыбрак кермәсәң, ишек белән шапылдатып суктырырга яисә бөтенләй үк аяктан ук егарга мөмкиннәр икән. Мәктәптә бер укучы да элеккегечә, ерактан ук күреп, әнә укытучы килә дип, тынып калмый. Зурраклар кечкенәләрнең маңгайларына чирткәләргә, кайсыларын аяк чалып егарга, Нурания Габбасовна аңлап бетермәгән "йомышларын" үтәмәгән өчен яңаклап алырга, ө бәләкәйләр, үз чиратының юк – шул беренче дәресенә директор кереп утырды. Алгарак узып әйтеп китәргә була: директор Казан мәктәпләрендә сакланып калган ике-өч кенә татар директорларының берсе иде. Илле яшьләрендә генә булса да, җете ап-ак чәчле, мөлаем аксыл-ал йөзле бу кешене Нурания Габбасовна соңыннанрак та Казан урамнарында еш күргәләде, һаман да директорлык итте бугай. Директорның идарә итү принциплары күзгә шактый бәрелеп тора иде. Беркайчан да үзе вактөяк һәм уртача низагларда казыйлык итмәс, бурзайлар кебек өч хатын – укыту бүлеге мөдирләре бар иде, шуларны гына өскә җибәрә. Татар мәктәбен отыры бетерүче Хрущев унъеллыгыннан чыгып, инде байтактан Брежнев бабайның "торгынлык елларында" яшәгән дәвер иде бу. Нурания Габбасовна менә хәзер директорны искә алып уйлый: артык куркыныч яклары бар иде, диясе килми, ул үз заманының кешесе булгандыр инде, бары шул гына.

Тегә, директор кереп утырган дәрескә әйләнеп кайтсак, Нурания Габбасовна утка пешкәндәй булса лы тарихы, үзе зур хәзинә булган туган тел дөньясы бар икән бит! Туган әдәбият бар икән. Бала башка иптәшләреннән аермалы булган бер тормышы, дөньясы барлыгын тоеп, эчке шатлык белән, эчтән балкып йөри башлый.

Бөтен мәктәбендә ата-аналар белән иң күп эшләүче дә Нурания Габбасовна булгандыр әле, мөгаен. Ата-аналар, ниһаять, сизенделәр, аңладылар бугай катнаш мәктәпнең нәрсә икәнлеген. Катнаш мәктәп, аннан бер адымда... катнаш никах дигән куркыныч нәрсә дә көтеп тора бит әле. Сизәрсең, куркырсың, үзеңнең балаң укыган мәктәпкә керергә дә куркып торырсың. Тик эш узган иде шул инде. Бөтенесен хәзер ничек кайтарып аласы? Шул урысча укытыла торган, катнаш дигән исем белән аталучы мәктәптә булса да милләт үсентеләрен ничек тергезергә? Чү, шулай да боз кузгала башлады түгелме соң?

Әле яңа гына узган укытучылар киңәшмәсендә директор: "Укучыны ничек итеп дәрескә йөртергә, укытырга татар теле укытучысыннан өйрәнегез", – диме? Бөтенләй дә

Бикә РӘХИМОВА

"Коткару килер, көтегез!"

(Хикәя)

китап-журналлардан укыган кайбер әдәби әсәрләр хәтерендә калды. Ә якын дустына әверелгән Нәфисә ханым белән хәзер дә барышып-килешеп йөриләр. Бөтен яктан килгән кешеләр була дөньяда. Нурания Габбасовна Нәфисә ханымны шундыйлар рәтенә куеп була дип хисаплый.

Китапханәдә эшләгән чорда әле тагын бер нәрсәгә күңеле белән дә, күзе белән дә аң булды Нурания Габбасовна. Чәчен таратып матурлаганда, көзгегә карап бераз гына бизәнеп-ясанып алганда, ул үзендә нindидер үзгәрешләр барлыгын шәйләп алды. Хикмәт! Кош канаты кебек, өскә таба очарга талпынган кашлары чигә ягыннан түбән таба карый башлаган түгелме соң?! Әннекәч кенәм, менә сиңа кирәк булса! Ирен читләре ияк ягына таба сызык җибәреп яталар! Йөзе дә түгәрәкләнә түгелме соң?.. Камыш буйлы гәүдәсе дә бөтенләй тулыланып китүгә күп сорамас... Их, мәктәптә йөгереп эшләп йөрүләрне кире кайтарсаң икән...

Хәер, бераздан йөгереп йөрергә җай да чыгып куйды. Адәм баласының түбәсе өстеннән җылырак, мәрхәмәтлерәк җилләр исә башладымы, әллә инде халык, җәмәгатьчелек татар телен сорап кага-кага түрәләрнең түбәләре тишелә башладымы – бер елны урыс мәктәбендә укучы татар балаларына татар теле дәресләре кертеләчәге мәгълүм булды. Нурания Габбасовна, билгеле, бу турыда беренчеләрдән булып ишетте, ләкин беренче елларны ук мәктәпкә урнаша алмады. Мәктәп директорына барасың, татар теле укытучысы кирәк икән сезгә, эшкә керер идем, дисең. "Юк, кирәкми, безнең татар теле укытучыбыз бар", – ди, күзен дә йоммый. Югыйсә, район мәгариф бүлегендә нәкъ менә шул мәктәпкә укытучы кирәк, дип җибәргәннәр иде бит. Барасың икенчесенә, сөйләштек, килештек, килә безгә укытучы, чак кына соңга калдыгыз, диләр. Шулай озак вакытлар йөреп, ахырда ире ярдәмендә укытырга урнашкач, андый хәлләрнең дә мәгънәсен аңлады. Директорлар бөтенләй башкалар, безнең халыктан түгел, аларга татар теле буенча белгечкә карагандa, аз-маз белеме булган – укытучымы ул, агрономмы, хисапчымы, кулинармы – татар теле дәресләрен сылтау гына итеп, күбрәк башка төрле эшләрдә ярдәмче ролендә йөрүче кирәк икән. Штат бирелә, нигә файдаланмаска? Ишәкнең туйга су ташырга чакырылганын белмиләрме әллә?.. Мәктәпнең очы-кырые күренмәгән вак-төяк эшләре дә бар ич аның. Эч пошырып йөрмәсеннәр әле татар телләре белән, кая барырга ярый ул татар да, бер-берләрен типкәләргә, озын тәнәфес булса, әллә нинди куркыныч төркемнәр үзләренең "җыелышлар"ын да үткәрергә өлгерәләр икән. Дәрескә кыңгырау чылтырагач кына, мәктәп бераз тынып калгандай була да, икенче тәнәфестә тагын шул ук хәл. Коридорга мәктәп директоры чыгып йөрү түгел, ник шунда Англия королевасы килеп тәртипкә чакырмасын, шашкан ташкынны беркем туктата алмас иде.

Менә ничек икән хәзер мәктәптә хәлләр. Болар турында алданрак та бераз ишеткән булса да, шул дәрәҗәдә түбән тәгәрәгәннәр икән дип уйлый да алмас иде Нурания Габбасовна.

Татар теле дәресенә килгәндә исә, ул расписаниедә бөтенләй дә юк иде. Факультатив – ирекле рәвештә үткәрелә икән балаларның ана теле! Татар әдәбияты турында сүз дә була алмый. Район мәгариф бүлегенә гариза илтә баргач, мөдир, керфекләреннән тәкәбберлек чаткылары чәчрәтеп, кәгазь бите буйлап күзләрен йөртеп алды да: "Учительница татарского языка, причем тут татарская литература?" – дип, Нурания Габбасовна гаризасындагы "и литературы" дигәнне чытырдатып сызды. Менә шулай, татар хатыны, бел үз урыныңны!

Факультатив дәресләрне үткәрү тәртибе болайрак булып чыкты. Көндез, иртәгә дәрес буласы дигән сыйныфтагы һәрбер укучыны аерым туктатып, татарлыгын искә төшереп, аның белән хисле генә сөйләшү үткәреп аласың, дәрескә килергә үгетлисең... Иртәгесе көнгә ничә дәрес үткәрәсе, шул балаларның һәрберсен күздән кичерәсе. Соңгы баланы ташкын эченнән эләктереп алып, "тәрбия биш минутлыгын" тәмамлаганда телең әлсерәгән маэмайныккыннан бер дә ким булмый, тының беткән, талчыккан бер кыяфәттә, иртәгә нәрсә булыр дип, йөрәгең убылып, өеңә кайтып егыласың икән. Нурания Габбасовнаның беренче дәресе иртәнге гомуми беренче дәрес башланганчы үткәрелергә тиеш булып чыкты, ягъни мәсәлән, "нулевой". Татар баласы башкалардан бер сәгать иртәрәк торып килергә тиеш... Икенче дәрес – түбән сыйныфларда дүртенче дәрестән соң, уртанчы сыйныфларда – бишенче дәрестән соң, тагын да өлкәнрәк сыйныфларда алтынчы, җиденче дәрестән соң... Шулай җыя башласаң, төштән соң укучыларны да кушсаң, көненә хәйран гына сәгатьләр – биш-алты дәрес килеп чыга икән. Әйе, җыя башласаң, җыя алсаң. Һай, аларны җыюлары...

Һич тә онытасы юк Нурания Габбасовнаның, шундый шартларда башлап җибәргән беренче дәресенә өч бала килгән иде – алтынчы "В" сыйныфы укучылары. Һич тә онытада, үзен кулга алып, теманы башлады. Тик иң элек балаларның туган телне белү дәрәҗәләрен барлап карады. Берни дә белмиләр иде. Берничә көннән шул да мәгълүм булды: түбән сыйныфлардан алып, иң югарыларына кадәр һәммәсенең белем дәрәҗәсе, дөресрәге, белмәү дәрәҗәсе бертөрле булып чыкты, әлифбаны да белмиләр, уку турында, сөйләү турында сүз дә була алмый. Менә "рәхәт"! Кер дә хәреф өйрәт, кер дә әлифба укыт. Укымыйлар шул, кайсы булдыра алмый – теле әйләнми, кайсы бөтенләй дә ояла, иң куркынычы – хурлана... Шундый аңлашылмаган, кызыксыз тел буламыни... Бер сүз белән әйткәндә, каля-баля. Әйе-әйе, нәкъ менә татар балалары үзләре үз телләре турында әйтәләр! Нурания Габбасовна башын тотып күзен йома, җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр иде: "И туган тел! Нишләргә инде? Без синең белән шулай икәүдән-икәү генә калдыкмыни? Ничекләр генә итеп синең саф чишмәдәй челтерәүле авазыңны шул балалар күңеленә салыйм икән?.." Ул елларда шундый шартларда мәктәпкә татар теле укытырга килгән укытучыларның кайберләре, авторитетымны төшереп йөрмим әле монда дип, артларына да карамыйча, тәкеренә-тәкеренә китеп бардылар. Туган телең шундый авыр хәлдә булганда, син мәктәптән йөз чакрымда качып йөрсәң дә, каян килсен ди инде ни үзеңә, ни халкыңа авторитет. Укытучы булмыйча, хет әллә кем булып эшләп йөр шунда. Авыз ачып ул сүзне әйтүдән ни мәгънә? Нурания Габбасовна болай бирешергә уйламады да. Чикмән янса янсын, казан кайнасын, дип, эшләвендә булды. Чикмән, әлеге дә баягы, кемнәрдер саклыйбыз, дигән авторитет иде.

Күргәнебезчә, баланы дәрескә китерү, аннан соң гына укыту иде факультатив дәресләрдә. Ә баланы исә үзеңә тиң итеп, уртак бер эшне эшлибез, дип мәсьәләне куя белсәң, эшең пешә дигән сүз. Әй, бала табигате – ул иң кызыклы фильмнан да кызыклырак, маҗаралырак бит! Эш шуңа хәтле барып җитте ки, дәрескә килгән һәрбер укучы үзен дә маҗаралы бер роман каһарманы дип хис итә ахры, дип уйлый башлыйсың. Югыйсә, беренче айларда аяк басарга курыккан укучылар караңгы булганчы сыйныф бүлмәсеннән чыкмыйча: "Нурания Габбасовна, әйдәгез, концерт куйыйк, спектакль өйрәник", – дип, дилбегәне үз кулларына алырга тырышуларын могҗиза димичә, ни дисең?! Грек-юнан тарихы, урыс патшаларының тарихы гына түгел, дөньяда башка тарихлар, борынгы бабаларының кызыккабинеты булмаган килеш эшен башлап җибәргән иде Нурания Габбасовна, хәзер менә үзенең кабинеты бар, район буенча кабинетлар ярышында беренче урынны алды.

Шулай матавыклана торгач, мәктәптә татар теле укыту шундый бер суверен, бәйсез эшкә әверелде ки, эшлә мөстәкыйль рәвештә... урыс мәктәбе кысаларында. Көч-хәл белән булса да тырышып, үзенең ана телен өйрәнергә азапланган баланың интонациясе, авазлар әйтелеше әле һаман урысчага тартым. Укучының һәр сүзен төзәтергә, озак итеп тамак-тел күнегүләре ясатырга туры килә, укучы алҗый, укытучының тамагы карлыгып бетә. Арый, бик арый Нурания Габбасовна, шулай да моны үзе генә белә, әнә бит җыелышып көтеп торалар, түгәрәккә дип килеп җиткәннәр, мәктәптә кунарга әзерләре бар араларында. Кайсы – татар халык әкиятләре эчтәлегенә туры китереп рәсемнәр ясый, кайсы – дүртьюллык кына шигырен күтәреп килә, кайсы – үзе кечкенә генә әкият язган.

...Ата-аналарга чакыру кәгазен дә шунда ук – түгәрәктә язалар. Матур төсле карандашлар белән, һәрбер әтине, әнине аерым атап. Менә бәйрәм көне җитә. Билгеле инде, бу – Г.Тукай туган көн. "Артистлар" сәхнәнең биек шкафлар белән генә бүлеп куелган кумырыгында сулыш алырга да куркып торалар. Килерме ата-аналар? Җыелалар. Шаулап киләләр! Менә ничек зарыктырган икән туган тел! Нурания Габбасовна да, ишек төбендә кизү калдырып, залга ашыкты. Шунда таба барганда ишетеп алды: баскычта, кара-каршы басып сөйләшүче ике мөдирнең берсе: "Там татары собираются!" – диде. Татар теле укытучысын күргәч, шым булдылар. Әйе, ничә елга сузылган "тәнәфес"тән соң, ата-аналары, татар баласы ата-анасы булып, беренче мәртәбә мәктәпкә җыела иде. Җыр артыннан – җыр, шигырь артыннан тагын шигырь, бер бию артыннан тагын да матуррак бию... ата-аналарның күзләрендә яшь, алкышлар... урыннан торып рәхмәт әйтүләр. Бу хәлләргә, Аллага шөкер, диими, ни дисең инде?! Концертны ата-аналар белән бергә барысы да аягүрә басып, "Туган тел"не җырлап тәмамладылар. Нәкъ менә шушы елларда, татар җәмәгатьчелеге нинди генә җыелышка җыелса да, "Туган тел"не бергәләп җырлау гадәте туды бугай... Ышансаң – ышан, ышанмасаң да ышан, дигәндәй, бер вакыт Нурания Габбасовна Г.Тукайны хәтта төшендә күрде.

(Ахыры 15 нче биттә).

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГӘЗИТЕНЕҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ N2 (54)

Тел фәне ачышларын – тизрәк гамәлгә!

Хәзерге мәктәпнең вазифасы безнең киләчәк буыныбызны аңлы, укымышлы бер татар ясап чыгарудыр... Шуның өчен андагы укыту теле, андагы тәрбия, андагы җырлар, көйләр – һәммәсе шуңа хезмәт итәргә тиешләр...

Гаяз ИСХАКЫЙ.

Гамәле юк галимнән кысыр тавык яхшырак

Файдалы нәрсә язсаң, укырлык булсын. Файдалы нәрсә ятласаң, язарлык булсын

Сәхифәбездә:

- Туган телне – гамәлгә! Чаллыдан үрнәк алыйк.
- Галимнәр хисап тота. Тел фәненең яңа үрләре.
- Югары уку йортында татарча укыту өчен термин җитәрлек.
- Ана көндәлегеннән. Баланың теле ничек ачыла.
- Сүз һәм моң бердәйлеге җимеш бирә.
- Кич утырганда. Сездән дә тәкъдимнәр көтәбез.

Үрнәк алырлык шәһәр

"И туган тел..."нең гыйнвар санында без Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы "Татарстан халыклары телләре турында"гы Законны тормышка ашыру комитетының узган елгы чираттагы утырышында шул Законны гамәлгә ашыруның барышы хакында Чаллы шәһәр хакимиятенең хисабы тыңлануын хәбәр иткән идек. Комитет утырышында чаллыларның бу юнәлештәге эшчәнлегенә уңай бәя бирелде һәм бу тәҗрибәне башка хакимиятләргә дә җиткерергә тәкъдим ителде. Шуны истә тотып, без бүген бу хисаптан киңрәк мәгълүмат китерәбез.

Иң башта шуны басым ясап әйтик: шәһәр хакимиятендә Телләр турындагы Законның үтәлеше өчен җаваплы конкрет орган бар – мэриядә 1992 елдан бирле милли мәсьәләләр бүлеге эшләп килә. 1997 елның апреленнән ул җәмәгатьчелек белән элемтә, милләтара мәсьәләләр һәм дин эшләре идарәсе итеп үзгәртелде. Инструкциядә каралганча, Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыруда өлкән идарә начальнигының урынбасары һәм баш белгеч җаваплы.

Шәһәр хакимиятенең барлык идарә һәм бүлекләре катнашында "Чаллыда яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятен саклау,өйрәнү һәм үстерү Программасы" эшләнгән иде. Шунысы игътибарга лаек: Программаның үтәлеше ел саен халык депутатларының шәһәр Советы сессиясендә тикшерелеп, яңа елга кабат кабул ителә. Шул программаның үтәлешен тәэмин итәргә тиешле яңа чараларны мэриянең һәр идарәсе һәм бүлеге эшли.

Шул вакытта Законны гамәлгә ашыру өчен оештырылган, даими эшләүче шәһәр комиссиясенең дә хисабы тыңлана, аның составы яңартыла, яңа елга эш планы карала.

Игътибар итик: кайбер район, шәһәрләрдә дә программалар төзелгән булса да,аларның күпчелеге үтәлми, чөнки башка күп кенә сәбәпләр рәтендә, программада куелган чараларны үтәү өчен матди-финанси җирлек булдырылмый. Чаллы шәһәр бюджетында телләр һәм мәдәният үсеше фонды булдырылган. Телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру өчен махсус сумма бүленә. Узган ел, мәсәлән, ул 1 миллиард сумга (шул вакыттагы акча исәбе белән) җиткән. Күп түгел, әлбәттә, шулай да хакимият бу максатка башка чыганаклардан да акча табу юлларын эзли.

Хакимиятнең Комитет утырышына әзерләгән хисабында әлеге Программаның үтәлеше елдан-елга тәфсилләп күрсәтелгән: шәһәр Советы сессияләрендә каралган чаралар, мэрия буенча һәм аның аерым идарә, бүлекләре үтәгән чаралар аерым-аерым күрсәтелгән. Бер язмада гына барысын да санап чыгу мөмкин түгел, шәһәркүләм чараларның кайберләрен генә күрсәтеп китик.

Һәр елны "Сабантуй", "Нардуган", "Нәүрүз" бәйрәмнәре үткәрү; ел саен Габдулла Тукайның туган көнендә бөтеншәһәр шигырь бәйрәме; татар балалары һәм яшүсмерләре өчен "Тургай" җыр бәйгесе; балалар иҗаты конкурсы һәм фестивале; барлык мәктәпләрдә "Туган телем – байлыгым" конкурсы; иң яхшы әдәби иншага шәһәркүләм ярыш; укучы яшьләрнең "Изге Болгар" еллык республика форумы һ.б.

Даими үткәрелә торган чаралардан янә менә боларны күрсәтергә була:

Шәһәрнең оешма, учреждение, эшханәләрендә татар телен өйрәнү курслары эшли. Мәсәлән, халыкка сервис хезмәте эшханәләрендә оештырылган курсларда 1995 елда – 145, 1996 – 105, 1997 елда 93 кеше укыган. Курслар сәламәтлек саклау, сәүдә, транспорт һәм элемтә системаларында да даими эшли. Теләүчеләр татар телен Чаллы өзлексез белем бирү институтында һәм "Заман" яшьләр үзәгендә оештырылган даими эшләүче курсларда өйрәнә ала.

Хакимият хисабыннан күренгәнчә, мэрия аппаратында да, аның барлык идарә һәм бүлекләрендә гражданнарны кабул итү, аларның гариза, шикаятьләрен карау һәм җавап бирү ике телнең берсендә – гражданнар кайсы телдә мөрәҗәгать итсә, шул телдә алып барыла. Мэриядә ике телне дә яхшы белүче тәрҗемәче эшли. Кәнсә эшләре һәм эш кәгазьләре ике телдә дә башкарыла.

Вокзалларда, транспортта пассажирларга хезмәт күрсәтү асылда ике телдә бара. Пассажирларга мөрәҗәгать итүнең үрнәк тексты булдырылган. Татар телен эштә аралашу дәрәҗәсендә белүгә кондукторлар һәм транспорт йөртүчеләр аттестация үтә.

Хәзер шәһәрнең географик атамалары, элмә язулары, юл күрсәткечләре һ.б. нигездә Телләр турындагы Законга туры китереп үзгәртелә. Эш бланклары, афиша, лозунг, плакатлар, этикеткалар да ике телдә дә языла.

Телләр турындагы Законны үтәү максатыннан шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында кайбер үзгәрешләр булды. Мәсәлән, шәһәр халкы татар телендә, "Татарстан" теле-радиокомпаниясе тапшыруларыннан тыш, "Чаллы-ТВ" шәһәр телевидениесе тапшыруларын да карый ала. Анда тәүлегенә ике сәгатьлек үз тапшырулары күрсәтелә. "Эфир ТВК-9 каналы"нда да берникадәр үз хәбәр-мәгълүматлары бирелә.

Радиода татарча тапшырулар, "Татарстан"нан тыш, "Күңел" станциясеннән тәүлегенә 15 сәгать ишетелә. Шәһәрнең чыбыклы радиосы да тәүлегенә ярты сәгать татарча һәм урысча үз хәбәрләрен тапшыра.

Көндәлек матбугатка килгәндә, Чаллы басмаларының (биредә хәзер "Шәһри Чаллы", "Кама таңнары", "Нур", "Көмеш кыңгырау" гәзитләре чыга) тиражы арта бара. Кулдан сатыла торган гәзитләр арасында "Хәерле иртә", "Киңәш", "Тәрбия" гәзитләре – татарча.

Шәһәрнең мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләре турында без узган санда кайбер мәгълүмат биргән идек инде, җентекләрәк мәгълүматны алдагы саннарда да тәкъдим итәрбез.

Айдан-айга

Казан дәүләт технология университетында татар теленә укыту, югары уку йортлары өчен дәреслекләр, кулланма, программалар әзерләү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче үзәк уңышлы эшләп килә. Үзәкнең узган елгы казанышларыннан берсе дип университетның деканнары һәм башка фәнни хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курсының уңышлы эшләп китүен санарга кирәк.

19 февральдә Татарстан Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы булып узды. Академиянең 1997 елдагы эшчәнлегенең йомгаклары һәм аның үсеш перспективалары турында докладны ТФА президенты академик Мансур Хәсәнов сөйләде. Докладта "Татарстан халыкларының телләре турында"гы Законның һәм Программаның үтәлеше турында да җитди сүз барды, уңышлы һәм кимчелекле яклар анализланды.

Җыелышта шулай ук Татарстан Фәннәр академиясенә яңа әгъзалар сайланды, академиянең уставына өстәмәләр кертелде.

Татар теле һәм әдәбияты буенча бәйге—олимпиадалар республикабыз шәһәр, районнарыннан тыш, бүтән өлкә, республикаларда да булып узды. Безгә килеп ирешкән хәбәрләрдән күренгәнчә, мәсәлән, Төмән өлкәсе буенча олимпиадада 8 районның 24 мәктәбеннән җиңүчеләр көч сынашкан. Ульян өлкәсендә, Башкортстанда да олимпиада яхшы оештырылып үткәрелгән.

Республика олимпиадасын хәзер Бөтенрусия олимпиадасы дип атарга булыр иде. Ул 24–26 февральдә булып узды. Анда Татарстаннан тыш төбәкләрдән килгән җиңүчеләр дә катнашты. Олимпиада нәтиҗәләрен алдагы санда хәбәр итәрбез.

Удмуртиядә "Язмышлар авазы" дигән җыентык басылып чыкты. Анда биредә яшәп татарча иҗат итүче 19 авторның шигырьләре һәм җырлары тупланган. Авторлар арасында Риза Шәфи кебек танылган шагыйрьләр янәшәсендә күп кенә яшь шагыйрьләрнең үсеп килүе – күңелле күренеш.

Яңалык! Яңалык!

Ульян өлкә радиосында атнага (җомга көнне) ике сәгать татарча тапшырулар була башлады. Аны өлкә телевидениесендә татарча "Чишмә" тапшыруын оештырып алып баручы Рамис Сафин оештырды. Беренче тапшыруны тыңлаучыларга хуш килде. Бу тапшыру өлкә татар җәмәгатьчелегенең ун ел буе алып барган көрәшенең уңай нәтиҗәсе дип кабул ителде.

Февраль башында Татарстан телевидениесенең "Дөнья һәм без" тапшыруларының берсе тулысы белән Телләр турындагы Законның үтәлешенә багышланган иде. Халык депутатлары, тел белгечләре, мәгариф, матбугат, киң җәмәгатьчелек вәкилләре Закон үтәлешенең акрын баруына борчылу белдерделәр, моның сәбәпләрен ачыкларга тырыштылар.

Бәрәкалла!

- *Яңа елга керер алдыннан Татарстан радиосы республиканың иң зур җитәкчеләре белән әңгәмә оештырып, алардан үткән елда ирешкән иң истә калырлык эш казанышлары турында сорашкан иде. Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшинның, мәсәлән, узган елда татар телен өйрәнүгә шактый күп вакыт биреп, берникадәр алга китүен казаныш дип санавына, мөгаен, күпләр игътибар иткәндер. Быел җитәкчеләребездән кемнәр шундый казанышка ирешер икән?*
- *АКШның Биография институты ел саен бирә торган "Ел кешесе" дигән халыкара мөхтәрәм исемгә "1997 ел кешесе" дигәненә Татарстаннан берничә зат лаек булды. Шулар арасында татар теле белгече, академик Рузәл Юсуповның да булуы, ана телебез өчен кайгыртучыларга зур шатлык һәм горурлык бирде.*
- *Узган ел шактый урыс баласы күп кенә татар сүзе өйрәнде. "Кайда булды мондый сирәк хәл?" дисезме... Белмәсәгез, белегез: Казанның 15 нче бакчасында. Бу эш анда быел да ярыйсы барыр, бүтән бакчалар да аннан үрнәк алырлар дип өметләник.*

Фәнни кыйблалар

Алны уйлап, үткәнгә бер

Иске ел азагында, яңа ел башында фән дөньясы үзенә бер казан булып кайнап куя – гыйльми оешма, учреждениеләрдә, югары уку йортларында еллык йомгакларга багышланган конференция, җыелышлар булып ала. Уңай гадәт дәвам ителеп, андый чаралар быел да җанлы, күтәренкелек белән үтте.

Татарстан галимнәренең фәнни һәм фәнни-гамәли эшчәнлек өлкәләрен, эзләнү темаларын санап чыгар өчен генә дә калын бер журнал кирәк булыр иде. Без инде үз укучыларыбыз даирәсе кызыксынган тармакны – татар телен өйрәнү, аны камилләштерү һәм дәүләт теле буларак гамәлгә ашыру мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешма, галимнәребезнең еллык эшчәнлеге турында гына берникадәр сүз йөртеп алырбыз. Киләчәктә дөнья казанышы саналырлык, киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәрлек фәнни хезмәтләргә шушы рубрикабыз астында алга таба да язмалар биреп барырбыз.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында лингвистика секциясенең (җитәкчеләре академиклар М.Зәкиев, Ф.Ганиев) еллык конференциясе ике көн барды. Кырыкка якын доклад тыңланды.

Доклад, чыгышлардан институт галимнәренең татар телен өйрәнү кыйбла, юнәлешләрен чамалау әлләни кыен түгел иде; телебезнең тарихи мөмкинлекләре, аларны бүген куллану юллары (филология фәннәре докторы Ф.Гарипова, Х.Курбатов), телебезнең стиль һәм куллану байлыгы, сүзлек хәзинәсенең үзенчәлекләре (фән кандидатлары И.Бәширова, М.Хәйруллин, Ф.Гәрәев һ.б.), татар теленең диалектологик хәзинәсе (Д.Рамазанова, Ф.Баязитова, Т.Хәйретдинова, З.Садыйкова һ.б.) бүгенге терминология проблемалары (Р.Рәхимова, Ф.Фәттахов, Ф.Гаффарова, Л.Хәлиуллина, Г.Сабирова, А.Рәхимова һ.б.), икетеллелек мәсьәләләре (З.Исхакова, Ф.Сәгъдиева һ.б.), яңа сүзлекләрне төзү һәм камилләштерү бурычлары (Ф.Ганиев, И.Сабитова, Г.Вәлиуллина һ.б.), грамматикада яңалыклар (Р.Сәгъдиева, Г.Нуриев, Г.Сабирова, Р.Закирова, Ф.Таһирова, Г.Сәмирханова, С.Гарифуллин, В.Костенко һ.б.) һәм дә башка кайбер юнәлеш, темалар.

Казан дәүләт университетының берничә факультетында татар теле максатчан өйрәнелә. Фәнни юнәлеш буларак расланган кайбер темаларны гына санап китик. "Татар теленең үсеше һәм гамәли кулланылышы" дигән секция (җитәкчесе профессор В.Хаков) темаларны төрләндерү, аларның заманча актуальлеген көчәйтү өстендә даими эшли. Быел күтәрелгән мәсьәләләр арасында татар әдәби теленең бүгенге үсеше (В.Хаков), авазларның тарихи үзгәреше (Ф.Хисамова), төрки телле иске чыганакларның байлыгы (Ф.Нуриева) һәм башка темалар тыңлаучыларның игътибарын җәлеп итте. Л.Гыймадиева, Г.Зиннәтуллина, А.Исламова, Х.Кузьмина кебек яшь галимнәр дә тел тарихына караган кызыклы гына мәгълүмат бәян иттеләр.

Соңгы вакытта "Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә ашыруның нәзари һәм гамәли мәсьәләләре" дигән секция (җитәкчесе профессор Ф.Сафиуллина) эшен активлаштырды. Секция җитәкчесе "Татар телен чит телле аудиториядә нәтиҗәле өйрәтү проблемасы" дигән темага доклад сөйләде. Галимнәрдән Л.Таҗиева, А.Йосыпова, Л.Ризванова, Р.Шәмсетдинова һәм башкалар татар телен төрле даирәгә нәтиҗәле укыту мәсьәләләрен күтәргәндә телебезнең тулы мөмкинлекләрен барлап куллану юлларын ачарга омтылдылар. Бу секция дә яшьләр белән эшләүгә, аларны дәртләндерүгә нык игътибар бирә.

Татар телен татар мәктәпләрендә дә, урыс телле уку йортларында да укыту проблемасы актуаль булып кала бирә. Университетның "Татар әдәбиятын һәм телен мәктәптә һәм югары уку йортында укытуның төп методик һәм методологик нигезләре" дигән секция (җитәкчесе академик Т.Галиуллин) конференциягә әзерләгән чыгышларда (аерым алганда, С.Ибраһимов, М.Шәкүрова, З.Шәйхрәзиева һ.б.) татар телен укыту өчен әзерләнгән дәреслекләр һәм программалар мәсьәләләре дә күтәрелгән иде.

"Төрки-татар ономастикасы" секциясе дә (җитәкчесе профессор Г.Саттаров ел йомгакларына телебезнең бу өлкәсенә караган кызыклы гына яңалыклар турында мәгълүматлар әзерләгән иде. Өлкән һәм яшь галимнәребезнең (Г.Саттаров, Л.Таҗиева, Г.Сөнгатов, М.Әнварова, М.Акбашева, Д.Сайкина, Г.Закирова һәм башкаларның) чыгышлары тыңлаучыларда кызыксыну тудырды.

"Татар журналистикасы" секциясендә дә тел үсеше, кулланышы мәсьәләләренә караган кызыклы чыгышлар булды. Ф.Әгъзамов, И.Низамов, М.Мәрдиева, Н.Нуруллина, А.Айнетдинов чыгышларында вакытлы матбугатның тел сәясәтен гамәлгә ашыру юлындагы бурычлары һәм тәҗрибәсе дә ачыкланды.

Шунысы игътибарга лаек: гомуми тел белемен, урыс телен һәм башка юнәлешләрне өйрәнүче галимнәр дә татар теле мәсьәләләреннән читтә кала алмый. Берничә секцияне үз эченә алган "Милли телләр һәм әдәбиятларның үсү һәм гамәлгә ашырылу закончалыклары" дигән юнәлештә дә татар теленең башка телләр белән, шул нисбәттә урыс теле белән мөнәсәбәттә үсеше һәм камилләшүе мәсьәләләре каралган иде (мәсәлән, Г.Гыйлаҗетдинова, Т.Киселева, Т.Ибраһимов, Р.Колшәрипов, Г.Хәйретдинова һ.б.).

Бу юнәлешнең "Гамәли һәм кампитр лингвистикасы" дигән секциясе татар теле мәсьәләләренә аеруча якын килә башлады. Быелгы чыгышлардан К.Галиуллин, А.Закиров һ.б.ларныкы аерым игътибарга лаек дип табылды.

Гомумән дә телләрне чагыштырып өйрәнү, аларны куллану тәҗрибәсен тарату мәсьәләләре көн үзәгенә чыга бара. Ана телен башка телләрне нәтиҗәле өйрәнү өчен файдалану хәзер актуаль юнәлешләрнең берсе санала. Бу җөмләдән "Шәрык телләренең татар теле һәм башка төрки телләр белән багланышы" дигән секциянең (җитәкчесе доцент Җ.Зәйнулин) актив эшләве, бу конференциядә дә кызыклы күзәтү, игътибарга лаеклы анализ, нәтиҗәләр белән катнашуы искә алынды.

Университетның теоретик кибернетика кафедрасына караган "Интеллектуаль гамәлләрне автоматлаштыруның математик нигезләре һәм аның программа тәэминаты" дигән фәнни юнәлешнең "Тел. Санак (кампитр). Фәһем" секциясендә Татарстан Фәннәр академиясе һәм Казан дәүләт университетының "Шәкли Фәһем" уртак фәнни-тикшеренү лабораториясендә (җитәкчесе доцент Җ.Сөләйманов) башкарылган эшләр хакында докладлар тыңланды. Аларга тәфсиллерәк тукталыйк әле.

Мәгълүм ки, бу лаборатория соңгы биш елда "Татарстан халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү" Дәүләт программасын үтәү йөзеннән санакларда татар телен куллану, бу телдә мәгълүмат туплау, эшкәртү, санак ярдәмендә татарча аралашу, телне өйрәнү юнәлешләрендә нәтиҗәле эшләр башкарып килә.

Конференциядә ясалган чыгышларда да сүз нигездә шулар хакында барды.

Ничек итеп санакны татар телендә сөйләргә өйрәтергә, аның Г.Тукайның "Туган тел"ен бүген татарларның үзләреннән дә йомшаграк итеп укып бирә алуы һәм башка практик сәләтләре турында өлкән фәнни хезмәткәрләр Т.Ибраһимов, Ф.Сәлимов, аспирантлар Р.Хөсәенов, Г.Дәүләтшина чыгышларыннан күренде.

Ф.Харисов, Ч.Харисоваларның актив катнашында төзелгән һәм санакларның бүгенге көндәге иң югары мөмкинлекләрен кулланып эшләнелгән "Минем беренче сүзлегем" бүген күпләргә татар телен башлап өйрәнергә ярдәм итә. Мультимедиа куллану укучыга 50дән артык теманы карап, сүзләрнең әйтелешен тыңлап чыгу гына түгел, шул ук сүзләрне диктор артыннан кабатлап әйтеп һәм тыңлап карарга мөмкинлек бирә. М.Хәлиуллин, А.Михайлусов, Р.Вәлиев чыгышында бу программаның компакт-диск чыгарылышы татар дөньясында

Терминнар дөньясында

Бөеклегебезне

Яңа XXI гасыр якынлаша... Аны, дөньякүләм мәшһүр галимнәр олугъ китап вә зур матбугат битләрендә "төрки халыклар гасыры" дип исемләп тә өлгерделәр инде. Галимнәр юкны сөйләмәс! Безгә, ошбу гасырны каршылап һәм аның дәверенә алдан эз салып, барча милләтләрне тәрәккыяткә вә дуслыкка җитәкләү өчен, иң әүвәл белемле кеше булу лазем. Белем дип аталган зур хәзинә өлешләрдән гыйбарәт; шуларның берсен сызма геометрия дип атыйлар. Хәзер шул атамада ана телебездә нәшер ителгән дәреслек хакында кыскача мәгълүмат-хасиллама бирербез.

Ана телебез

Бер телле, бер мәдәниятле бердәнбер коммунистик милләт төзү сәясәте хөкем сөргәндә, Татарстанның югары уку йортларында төрле фәннәрне татарча укыту һәм гыйльми эшләрне татарча язу турында уйларга да мөмкин түгел иде. Ике-өч югары уку йортында булган татар филологиясе бүлекләрендә ана теле һәм әдәбияты гына татарча дәвам итте. Башка барлык фәннәр урысча алып барыла, гыйльми эшләр дә урысча гына языла иде. Бу татар теленең функциональ үсешен, терминологиясенең баюын, димәк, татар милләтенең камилләшүен дә тоткарлауга китерде. Бу сәясәт ил күләмендә рухи һәм матди хәерчеләнүне тудырды, чөнки милләтләрнең үзенчәлекле менталитетларыннан файдалану тукталды. Бу хәл татар халкының рухи кимсетелүенә, пассивлашуына китерде. Йөз меңнәрчә миллионнарча татарларның интеллектуаль потенциалы ачылмый калды.

Тормышның барлык өлкәләрендә дә үзгәртеп кору башланып, милләтләрне тергезү, саклау һәм үстерү сәясәте өстенлек алгач, моны тормышка ашыру эшенә республика вузларында татар галимнәре дә актив кушылып киттеләр, әдәбият һәм телне генә түгел, хәтта табигать фәннәрен һәм техник фәннәрне дә татар студентларына ана телендә укыту күренгәли башлады. Хәзер инде алар өчен татарча дәреслекләр язу зарур, димәк, гыйльми эш тә татарча алып барылырга тиеш.

Татар галиме буларак, бу эшкә **"Гамәли һәндәсә һәм инженерлык сызымы"** белгечлеге буенча үз өлешебезне кертергә уйладык. Шул ният белән **"Сызма геометрия"** исемле дәреслек төзергә булдык. Бу зур вә мөһим эшкә керешкәнче үк безнең тарафтан эшкәртелгән сызма геометриядән атамалар сүзлеге, соңра шул фәннән мәсьәләләр җыентыгы да ана телендә нәшер ителде.

Ошбу дәреслек-сызма геометрия фәне буенча татар телендә язылган беренче китап. Шуңа күрә аны язганда безгә махсус фәнни терминология мәсьәләсе белән дә шөгыльләнергә туры килде. Безне, әлбәттә, урта мәктәп дәреслекләрендә кулланылган терминология сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да канәгатьләндерми иде. Шунлыктан күп кенә төшенчәләрнең махсус терминнарын үзебезгә эзләп табарга туры килде. Аларны төзегәндә филология фәннәре докторы Рифкат әфәнде Әхмәтҗанов гаять зур сәләтен һәм фидакарь хезмәтен күрсәтте.

Китапка халкыбызда киң таралган, фәнни текстларга сыгылмалылык биреп торган, **вә, илә, даир** кебек сүзләр белән беррәттән, яңа **табигълык, рәкымьдәшлек, түңгеллек, кимәл, җәйрәү, битләү** кебек күп кенә сүзләр тәүге мәртәбә кертелде. Алар дәреслектә аерым сүзлек итеп теркәлгән һәм урысча мәгънәләре бирелгән.

Максатлар, мәсьәләләр вә ысуллар

Һәр нәрсәне диярлек сүзләр белән тасвирлап була. Ләкин техникада кабул ителгән төп алым – җисемнең формасын аның сурәте тасвирлау, сызма геометриянең беренче төп максаты булып геометрик рәвешләрне һәм җисемнәрне яссуда төгәл сурәтләү тора. Сызма геометриянең икенче зур максаты булып яссуда сурәтләү ярдәмендә график юл белән фәзада бирелгән мәсьәләләрне чишү санала. Фәза объектларын аларның сурәтләре белән чагыштырып, тиңләштереп бару нәтиҗәсендә сызма геометрия укучыда фәзаны күзаллауны, аны тирәнтен төшенүне һәм дөрес фараз итүне, ягъни логик фикер йөртүне үстерә. Сызма геометриянең өченче мөһим максаты шуннан гыйбарәт. Геометрик рәвешләр илә фәзада дөрес фикер йөртә белү, теләсә нинди аерым белгечлектә, бигрәк тә **уйгырлыкта, кәшефчелектә** хезмәт итүче һәр инженерга күләмле объектларны һәм формаларны яссуга проекцияләү ысуллары:

– реаль тормышка багланышлы төрле геометрик мәсьәләләрне график ысуллар белән чишү;

– модельдә объектларның геометрик үзлекләрен тикшерү һәм аларның проекцияләрен үзгәрт[ү] ысуллары;

– проектланган объектның визуаль чынбарлыгын һәм күрсәтмәлелеген, күзәфәлелеген арттыру алымнары.

Фәнни яңалыклар

Дәреслеккә фәнни күзлектән караганда һәм аны исемдәш китаплар белән чагыштырганда, аның гаять зур аермасы бар.

1. Югары мәктәптә өйрәнелә торган теләсә нинди математика фәне булачак инженерлар кулына инженерлык мәсьәләләрен чишә торган ысуллар тәкъдим итәргә тиеш. Шул җәһәттән, биредә фәза механизмнарын оптималь синтезлау өчен "ярдәмче модельләр ысуллы" кертелде. Ысул кулланышында чишелгән мәсьәләләрнең бер өлешенең, автомобиль җитеш–терү буенча иң алдынгы һәм дөньякүләм танылган атаклы фирмаларның игътибарын җәлеп итүе – тәкъдим ителгән яңа ысулның һәм шул рәттән сызма геометриянең, классик фән буларак, фәзалы механизмнар теориясенә зур өлеш кертүен өстәмә раслый. Бу хезмәтләр "Руль шүргече" исемле монографиядә 1989 елда дөнья күргән иде инде.

Бу – шушы гыйльми эшләрне үзенә туплаган татар телендәге **"Сызма геометрия"** дәреслегенең бүтән төрдәш китаплардан беренче аермасы. Нәтиҗәдә, сызма геометрия фәнендә киң таралган "ярдәмче проекцияләр ысулы" тәкъ-

беренче карлыгач булуын, беренче "алтын диск"ның да лабораториядә уңышлы эшләнүе ассызыклап әйтеп үтелде. Ә бу – лабораториядә техник-технологик мөмкинлекләрнең дә, белгечләрнең профессиональ дәрәҗәсенең дә югары булуына саллы дәлил.

Информатикага, санак технологияләренә караган терминнар ясау мәсьәләсенә багышланган чыгышларында доцентлар Ә.Галимҗанов һәм И.Кыпчак төрки республикаларда, Төркиядә, шулай ук, Татарстанда тупланып килгән тәҗрибә белән таныштылар. Теория мәсьәләсе белән беррәттән тәкъдим ителгән конкрет терминнар тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты: "меню – сайлак", "принтер – басак", "тонер – буйау", "клавиатура – төймәсар", "катридж – буяк (буяу савыты)". Бу терминнар татарча-урысча-инглизчә терминнар сүзлегенә тәкъдим ителә.

Татар теленең морфологиясен анализлаучы санак программасын татар сүзләрен

караш

морфемаларга таркату һәм җыю эшендә бүген студентлар хәтта аспирантлар белән дә ярыша ала, дип белдерде аспирант Р.Гыйльмуллин һәм доцент И.Кыпчак үз чыгышларында. Шул программа нигезендә Төркиянең Белкент университеты белгечләре белән берлектә татар текстларын төрекчәгә, төрек текстларын татарчага күчерүче программа эшләнеп килә.

Аспирант А.Гатиатуллин һәм доцент Ә.Әлмирнең чыгышлары татар морфемаларының шәкли моделен төзүгә, аны тутыруга һәм практикада куллануга багышланган иде. Аффиксларның нинди мәгънәләр бирүе, аларны модельдә ничек итеп күрсәтү мөмкинлекләрен табу һәм куллану аеруча мөһим мәсьәлә итеп күрсәтелде.

Фәнни хезмәткәрләр М.Әюпов, Җ.Сәләев, Р.Һадилар чыгышында сүз уку-укыту программалары, укучы-укытучының автоматлаштырылган эш урыннары турында барды. Доцент Р.Мөбәрәкҗанов лабораториядә КДУның "Чит телле аудиториядә татар теле укыту" кафедрасы һәм Мәскәү галимнәре белән берлектә төзелеп килгән татарча-урысча-инглизчә электрон сүзлекнең хәлен аңлатты.

Шунысы куанычлы, узган елда башкарылган эшләрнең дә күбесе инде Чехия, Италия, Франция, Төркия, Украина илләрендә, Мәскәү, Казан шәһәрләрендә Халыкара конференцияләрдә бәян ителде, фәнни мәкаләләр булып бастырылды, кайберләре (мәсәлән, компакт-дискка яздырылган татар теле дәресләре) инде мәктәпләрдә кулланыла.

И.МАЗИН.

Гаиләдә

Утызынчы елларда балалар сөйләмен өйрәнгән галим М.Фазлулла болай язган:

"Сөйләшергә өйрәнгәнче бала өч девер үткәрә: бетелдәү, тәкълид итү (иярү) һәм аңлау дәверләрен. Балалар үзләренең фикер вә хиссиятләрен ике төрле юл белән тәкъбир итәләр: берсе ишарә вә хәрәкәтләр белән, икенчесе – авазлар белән. Әгәр инде бала әйткән аваз вә сүзләр үз урынында вә үз мәгънәсендә булып, аның эчке хиссиятен тәгъбир итә торган булсалар, ул вакытта чын мәгънәсе белән бала сөйләшә башлаган, теле ачылып җиткән итеп хисаплана. Уау-уау сүзен белсә дә, этне күргәч аны атамаса, ул әле сөйләшә белә дип булмый..."

Сүзне бишек җырыннан башлыйм әле. Халкыбызда бишек җырлары моннан берничә гасыр элек үк барлыкка килгән. Аларның эчтәлеге еллар үткән саен камилләшә барган.

АДЫМ арты АДЫМ

(Ана көндәлегеннән)

Аларда нәрсә турында җырлана соң? Гадәттә, ананың иң изге теләкләре чагылдырыла. Бишек җыры – ананың үзенчәлекле догасы ул. Боларны бигрәк тә әбиләр җырлый. Чөнки алар дәверендә бишек җырлары киң урын алып торган. Бу уңайдан, Г.Тукай иҗат иткән "Бишек җыры"н искә төшереп үтик:

"Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып китәр бу..."

Бишек җырлары, барыннан да бигрәк, баланы тынычландыру, юату, тирбәтеп йоклату өчен хезмәт итәләр.

Бишек җырлары, баланы тирбәтеп тынычландырудан тыш, белем һәм тәрбия бирү көченә ия. Шуны да онытмаска кирәк: бала әнисе, әбисенең җырын тыңлап, аңа кушылып җырларга, үсә төшкәч, җыр сүзләрен кабатларга тиеш. Шулай итеп, бишек җырлары аша, сабый ана телендә сөйләшергә, сүзләр әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә, үзе дә сүзләрне әйтергә омтыла.

Баланың теле ачылу, сөйләшергә өйрәнү процессы кызык. Мин ике ел буе кызым Илсөярнең, дөньяга карашы үсүе, ничек теле ачылуы турында көндәлек алып бардым.

Яше тулганчы ул "әттә", "әннә" "мәммәм" сүзләрен әйтә иде. Бик аңлап бетермичә, туры китереп кенә. Яше тулгач, шуларны аңлап әйтә башлады. Бер-бер артлы бәбәй, әби, куян төшенчәләрен аңлап әйтә башлады. Яшь тә ике айда китап, бабай, чәй төшенчәләре өстәлде. Яшь тә өч айда кулы белән ишарәләп "сау бул" дия иде. Яшь тә дүрт айда "Исәнме", – дигәч, кул бирә. Аю, шар, эт уенчыкларын да танып алып килә. Этне "ау-ау" ди, "аю" сүзен тулы әйтә. Яшь тә биш айда "бәб-бә", "әб-бә" "мяу" (песи), эч" (чәй), "чә" (чәчәк) "ам-ма" (алма) сүзләрен әйтте; күзен, авызын таныды, тагын бер айдан "чәй", "су", "кил", "ки", апа, "би" (бир), әби сүзләрен әйтә иде.

Әбисе амин тотарга өйрәтте. Авызын сыпырып "әппә" (әппәр) ди. Бахбай кайда, дигәч, "на-на" ди, маэмай килә дисәләр "ау-ау" килә, ди. Кызым, әниең кайда, дисәләр, "әни җюк, мәммә киә" (әни юк, мәммәм алып килә), дип җавап бирә. Күп сүзләрне кеше артыннан кабатлый: җимеш – "тимеч", урман – "ума".

Бер яшь тә җиденче айда Илсөяр инде дөрес җөмләләр белән "эш итә" башлады: "Баба, өйдә, мәми би (бир)!" "Әби тәтәй" (әби әйбәт) һ.б.

Телевизор, көзгене сорагач, аңлап күрсәтә; күзен, колагын, кулын, аягын, башын, чәчен, борынын, телен, тешен күрсәтә белә. Аягын – "пәпи", чәчен – "чәч", ди. Мунча керүне – "чәт-чәт" (чабыну), машинаны – "түтүт", ди.

Чәй эчкәч "Әх!", сикерсә "оппа!", мичтә утын янса "үф", пш", (пешә, яна). "Пш" дип үзе дә ашарга пешереп уйный, барыбызга да ашата. Майны – "ма", абыйны – "аби", ди. "Аби түтүт китә" (абый машина белән китте), дип, кулы белән ишарәләп күрсәтә. Иелгәнне күрсә, аркага менеп утыра да: "на, на", ди башлый, "әийә, китте" (әйдә, киттек). Яңа кием кидерсәң, көзгегә таба тарта. Көзге алдына басып, үзенә сокланып карап тора, көзгедәге "бәбәй"не үбә башлый.

Гаиләдә бала тәрбиясендә әби, бабайларның урыны аеруча зур. Алар баланың сөйләмен үстереп, шомартып, баетып кына калмый, ә аңарга тулаем халык педагогикасы нигезендә йогынты ясый. Менә кайбер ырымнарны гына искә төшерик. Нинди тәрбия чарасы бит алар!

"Тупсага утырма – көрлә булып калырсың", "Майны күп ашасаң, күзең күрмәс", "Иләк аша карама – хатының шадра булыр", "Әшәке сөйләшсәң – телең корыр", "Кич идән себерсәң, бәхетең ким булыр", "Төнлә көзгегә карасаң, гомерең кыскарыр" һ.б. Болар барысы да балада әдәплелек, этика, культура күнекмәләре тәрбияләргә мөмкинлек бирә. Телне әшәке, вульгар сүз аламалары белән пычрату аеруча яман санала. Ризык-нигъмәтнең кадерен белү, аны исрафламау кирәклеген дә бала күңеленә кече яшьтән үк сеңдерә бару мөһим. "Бәхет ярмасын калдырма!" диләр әби белән бабай. Әби-бабай тәрбиясендәге баланың акыл һәм физик үсеше тизрәк бара. Сөйләме дә баерак, җайлырак була. Эш шунда ки, олыларның көндәлек сүз байлыгы яшьләрнекеннән күпкә мул.

Бер үк вакытта бу күренешкә ике яклап карарга кирәк: "әбиләрчә" әйткәндә, баланың сөйләме тизрәк шомара, табигыйрәк була. Шул ук вакытта бу сүзләрнең әдәби телдә әйтелешен дә балага кисәтә килергә, күнектерергә кирәк, мәктәпкә баргач югалып калырлык, сөйләмен тоткарларлык булмасын.

Гүзәлия ШӘЙГӘРДАНОВА.
Мөслим районы.

дим ителгән ысулның аерым очрагы гына булып калды.

2. Фән һәм техниканың хәзерге халәте теләсә нинди катлаулы сызымнарны башкару өчен сурәтләү ысулларын үзләштерергә һәм кулыңа сызым кораллары алып, төрле сызым төзү процессларын башкарырга куша. Шул максатка ирешү өчен сызма геометриянең һәр ысу-

кайтару

лы һәм һәр бүлеге алгоритмнар белән тәэмин ителде. Алгоритмнарны ансат аңлау, кампитрларда эшләрне камилләштерү нияте белән күп кенә мисалларда сызым алгоритмы алдыннан гомумиләштерелгән фәза алгоритмы бирелде. Фәза алгоритмы мәсьәләләрне чишү барышын глобаль итеп күрсәтте, ә аның сызым алгоритмы һәр геометрик рәвешнең (ГР) модельдә тәгәл урынын билгели һәм мәсьәләне чишелешкә, нәтиҗәсенә илтә.

Өстәп шуны да искәртик. Метрик, позицион вә конструктив мәсьәләләр чишелешендә китерелгән бу алгоритмнар өч үлчәмле җисемнәрне яссуда сурәтләү һәм фәзаны тирәнтен күзаллауны үстерү өчен генә түгел, "икенче белемне" (программалаштыру һәм кампитрлаштыру), "Машина графикасы" "Геометрик мәсьәләләрне машинада чишү алгоритмнары" курсларында куллану өчен гаять зур адым булып тора. Бу – ана телебездә нәшер ителгән сызма геометрия дәреслегенең чит телләрдә чыккан шундый ук китаплардан икенче аермасы.

3. Сызма геометрия нибары өч ГР: нокта, сызык һәм өслек (яссу – өслекнең аерым очрагы) белән үзенең гамәли эшләрен башкара. Аның катлаулы мәсьәләләрне ГРнең үзара мөнәсәбәтләреннән, төгәлрәк әйткәндә үзара табигълыкларыннан гыйбарәт. Биредә ошбу мөгаммә (проблема) өслекләрне өйрәнгәндә үк башлана (Ү бүлек):

– каркас билгеләмәсенә таянып, структура формулалары кертелде:
– рәвешләрнең үзара табигълыклары каралды;
– ГРнең кисешүчәнлекләре

төп позицион мәсьәләләргә бүлеп бирелде, һәм аларның һәркайсы өчәр очракта калды.

ҮII бүлектә исә кисешүче ГР гомумторышлы өслекләр ярдәмендә башкарылуы каралды һәм белешмә җәдвәле бирелде. Алар игътибарга лаек мәсьәләләр дип санала.

Методик өстәмәләр

Безгә югары мәктәпләрдә эшләү дәверендә күп фәнни курсларны укытырга туры килде. Мондый шарт-ларда аудитория алдына чыкканчы төрле чыганаклардан өстәмә мәгълүматлар җыеп, белемеңне күтәрергә кирәклеге һәр педагогка мәгълүм.

"Сызма геометрия" дәреслеге техник вузлар мөдәррисләре һәм студентлары өчен төзелү сәбәпле, без укучыларның төрле кимәлдәге белемнәрен истә тотып, әүвәл белемнәрен фәннең нәзари нигезен алгы сафка чыгарып, проектив фәза күзлегеннән исбатлап, мөгаллимнәр өчен аерым бер бүлек тупладык, ә студентлар игътибарына "Ортогональ проекцияләрдә ГРне модельләү һәм мәсьәләләр чишү" исемле беренче кисәкне тәкъдим иттек. Дәреслекнең бу өлеше ун бүлектән гыйбарәт, чөнки ортогональ сызымнар – һәр һөнәрлекнең – инженер-конструктор, инженер-механик, инженер-технолог һәм башка техник һөнәрлекнең график нигезе ул.

Ошбу дәреслек – урыстан яисә башка чит телләрдә туры тәрҗемә ителгән сызма геометрия түгел. Әлбәттә, монда күп кенә материал исемдәш китаплардан кертелде. Дәреслекләр өчен – бу табигый хәл. Иң мөһиме, без, күләм ягыннан бу зур хезмәтнең нәтиҗәләрен гамәли кулланышта уңай һәм ансат файдалану максатыннан, һәр бүлек азагына, анда исбатланган тәгълиматларны садәләштердек, теоремалар, кагыйдәләр, кануннар яисә тәкъдимнәр рәвешендә теге яки бу конкрет мәсьәләгә җайлап, гадиләштереп бирдек (шундый бирелешләрнең саны 314). Мондый методик алым дәреслектән файдалануны җиңелләштерә.

Дәреслектәге тагын бер методик үзенчәлеккә игътибар итми булмый: мондый өслекләр вә яссулар грек шрифтының баш хәрефләре илә тамгаланган. Максат:

– символларны милли телгә – сүзнең әйтелешенә аваздаш итеп сайлау һәм тамгалау. Әйтик, грекларның Θ (тэта) хәрефе безнең телдә "өстәмә" сүзенең баш хәрефенә охшаш. Димәк, милләт укучысына ошбу хәреф илә тамгаланган яссу яисә өслекне – "өстәмә яссу" яисә "өстәмә өслек" булган ГР икәнлеге тиз аңлашыла.

Әйтик, О (омикрон) хәрефе безнең телдә "орынма" сүзенең баш хәрефенә охшый, аның "орынма яссуны" яисә "орынма өслек", ә юл хәрефе – "орынма сызыкны" тамгаларга мөмкинлек бирә. Шундый мисаллар дәреслектә күп урында очрый;

– югарыда тасвирланган ысулга охшаш, әмма аермалы тагын бер мисал. Биредә П (пи) хәрефе белән проекция яссулары тамгаланган. Мәгълүм ки, физика, математика, нәзари механика, механизмнар вә машиналар теориясе кебек төгәл фәннәрдә шул шрифтның юл хәрефе П (пи) – иррациональлек вә трансцендентлык саны булган 3,14 рәкымьле тәкъбирләрдә, тигезләмәләрдә очрый. Аларның тамгаланулары урта вә югары мәктәп программаларына бербөтен итеп карауга һәм гамәлгә ашыру юлы табылуга ишарә ясый.

XXI гасыр тирән вә төпле белемле шәхесләрне көтә. Җыеп әйткәндә, алар төрки халыкларның яшь буыннары булачак. Ошбу буыныбыз өлешенә өстәмә, катлаулы вә үзенчәлекле көшефләр, уйгырлыклар төшә. Бу шәхесләрдә алгоритмлаштырылган вә рәкымьләп тәгъбирләнгән белем булу лазем, ә нигездә гыйльми әсрар (теология, логика, фәлсәфә, тарих, икътисад, һ.б. гуманитар) һәм төгәл (проектив геометрия һәм математика, нәзари механика һәм механизмнар вә машиналар теориясе) фәннәр очрашкан очсыз-кырыйсыз фәзакәкрә ята. Шундый сукай вә ташлы-киртәле юлдан фәнне тартып бара алганнарны бөек шәхесләр язмышы әл-Хәризмиләр, Мимар Синарлар көтә. Якты белем нуры юлдаш булсын изге юлыбызда.

Галимнәр сүзе бушка түгелдер, ә яңа XXI гасырны тәрәккыяткә илтүчеләр – галәмгә ямь вә ләззәт бирүче яшьләр алар!

Садрислам МИНУЛЛА,
КДАТА профессоры.

Белешмә-сүзлек
һәндәсә – геометрия
фәза – пространство
уйгырлык – ачыш
көшефчелек – уйлап табу, яңалык чыгару
рәкымьле – математик
ГР – геометрик рәвеш.

Сүз һәм моң

Могҗиза туганда

Җырчы булырга әзерләнүче студентларны укыту барышында сүзгә ни дәрәҗәдә әһәмият бирелә? Сүз беренчелме, музыкамы? Бу сорауларга җавап табу өчен без Казан дәүләт консерваториясе мөгаллимәсе, профессор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Светлана Нәҗип кызы ҖИҺАНШИНА белән әңгәмә үткәрдек.

– Светлана ханым, сез – гомерегезне музыкага багышлаган кеше, консерваториядә вокал укыту методикасы алып барасыз, үзегез вокал курсы укытасыз, опера кафедрасы мөдире вазифасын үтисез. Җырлауда тел һәм сөйләмнең зур әһәмияткә ия булуын беләбез, шуңа киңрәк тукталсагыз иде.

– Дөрес һәм матур сөйләмнән дөрес җырлау формалаша. Шунлыктан, сөйләм күнекмәләре бирелә зур урын тота. Балаларын әдәби тел нормаларын җирлегендә тәрбияләүнең әһәмияте шуннан ачык аңлашылса кирәк. Бала татар әдәби телен дә, урыс әдәби телен дә, хәтта чит телләрне дә ишетеп, аларның матурлыгын, аһәңен тоемлап үсә икән, бу бик әйбәт.

Тыңлагыз сез күренекле осталар җырлавын: анда һәр аваз, иҗек үз урынында.

– Җырлау серләренә өйрәтеп буладыр, ә менә дөрес артикуляциягә өйрәтеп буламы?

– Аларны аерып карарга ярамый. Җырчы-студент бөтен уку дәверендә шуны гына диярлек өйрәнә дә инде. Барлык вокаль күнегүләр сузык һәм тартык авазларга нигезләнә бит. Әгәр авыз эчендә ботка пешерсәң – җырыңның бәясе бер тиен. Шул сәбәпле, сүз тыңлаучы аңына җитсен дисәң, дикция – ачык һәм нәзакәтле әйтелеш өстендә эшләргә кирәк. Җырчы бит борынгы классиканы да, XYIII һәм XIX гасырда язылганнарны да, бүгенге көн әсәрләрен дә башкара. Шуның өчен сөйләм аппаратының мондый үзгәреш-күчешләргә әзер һәм көйләнгән булуы мөһим. Урыс вокаль музыкасында, мәсәлән, Глинка чорында, сүзне үзенчәлекле итеп әйтү очраклары яшәп килгән. "Расцвел" дигән сүзне, "е" авазы булмаганга күрә, "расцвел" дип әйткәннәр (һәм җырлаганнар). Профессиональ дәрәҗәдә башкару өчен мондый "ваклыклар"дан хәбәрдар булу кирәк.

– Кайсы җырчыны студентларга мисал итеп китерергә яратасыз?

– Иң әүвәл, әлбәттә, Шаляпинны. Бу бөек артистның образга, грим, костюмга карашы белән беррәттән, сүзгә мөнәсәбәте дә сокландыргыч. "Маска и душа" китабыннан хәтерлисездер, ул теге яки бу образны иҗат иткәндә аның сөйләмен тудыруга озак әзерләнгән, хәтта драма актерларыннан дәресләр дә алган. Шаляпин "тартык авазларны җырлый белүче" (К.Станиславский сүзләре) буларак та мәгълүм. Тартыклар аңа комачауламаган. Тагын опера җырчыларыннан Пирогов, Лемешев, Архипова, Атлантов, татар җырчыларыннан Мәрьям Рахманкулова, Галия Кайбицкая, Усман Әлмиевләрне атап үтәр идем. Болар да үз иҗатларына гаять таләпчән музыкантлар.

– Кайбер композиторлар аерым бер шагыйрь иҗатына гына йөз тота. Мондый иҗади дуслыкка күпләп мисал китерә алыр идек...

– Әйе, композиторларга талымсыз булырга ярамый. Бөек композиторлар теләсә кем шигыренә язмаган бит. Мәсәлән, Чайковский шагыйрьләрдән Плещеевка, Романов, Жуковскийга күбрәк мөрәҗәгать иткән. Пушкин шигъриятенә билгеле бер нәфислек, матурлык хас, шунлыктан аеруча аңа ихтирам белән якын килергә кирәк. Көй һәм сүз бәйләнеше өлкәсендә һәр гасырның үз эстетикасы, шуңа күрә дә Прокофьевның Ахматова шигырьләренә тукталуы гаҗәп түгел. Олы композиторлар иҗатында сүз юкка чыкмаган, һәрчак үз максатына юнәлдерелгән, эстетик вазифасын төгәл үтәгән.

– Светлана ханым, ә татар музыкасына килсәк?

– "Тәфтиләү" Тукай сүзләренә җырлана. Аның әйтеп бетергесез гүзәл сүзләрендә тирән фикер ята. Бу җырны Фәхри Насретдинов башкаруында яратып тыңлый идем. Әтием – Нәҗип Җиһанов башлыча Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким сүзләренә язды. Җырларны күп иҗат итсә дә, ул операда көчлерәк иде. Җәлил аңа бу өлкәдә таяныч, юлдаш, иҗатташ булды. Икенче бер либреттисты – Әхмәт Фәйзи. (Әти гомумән либреттисттан башка опера язмады). Талантлы либреттист, әйткәнемчә, аның таянычы да иде. Әхмәт Фәйзи үлгәч, ул опера язудан бөтенләй туктады. Аның Габдулла Тукай турында опера язасы килгән иде, ләкин ул вакытта либретто язардай шагыйрь булмагач, бу нияте тормышка ашмады.

Сүзгә таләпчәнлеге белән Рөстәм Яхин да аерылып торды. Ул беркайчан да купшы, ялтыравык сүзләргә ябышмады. Берара Шекспирның урысчага тәрҗемәләренә (Лившиц тәрҗемәләре) романслар иҗат итте. Ә романслар, гомумән, камера музыкасы, гаҗәеп дәрәҗәдә осталык сорый торган өлкә ул. Монда операдагы кебек декорация дә, костюмнар да, драматик уен да юк, музыкант һәм җырчы гына бар. Синең төп коралың – тавыш һәм сүз. Менә кайда кирәк ул сүз белән эш итү осталыгы, чөнки син образ тудырырга, кечкенә спектакль башкарырга тиеш буласың.

– Шулай да сүз белән музыканы нәрсә берләштерә соң?

– Башкару техникасы! Әйтик, бар шундый вокализлар (билгеле бер аваз яисә ноталар әйтеп җырлана торган вокаль күнегү) аларда тавыш инструментка тиңләштерелә.

Башкару осталыгы җәһәтеннән Илһам Шакировны атап үтәр идем. Ул гаять ачык дикция белән җырлый, татарча сүзләрен аңламаган кешегә дә ни турында сүз баруын төшенү кыен түгел, чөнки әсәрне бөтен җаны белән бирелеп башкара. Аның көче – монда!

Кайбер җырчылар әсәрне өйрәнүне музыкадан башлый. Сүздән кирәк. Эчтәлек бит сүзләргә салынган. Йә булмаса җырчыларның бер ишеләре сүзләрне алмаштыра. Бусы инде бөтенләй дөрес түгел, аеруча классик әсәрләрдә.

Эстрада турында да әйтми булмый. Чын мәгънәсендә эстрада – зур сәнгать ул. Ләкин вульгар сөйләмнән, вульгар шигырьдән вульгар җыр туа. Эстрада – ул шулай ук мәдәният мәйданы, анда да югары максатлар куелырга тиеш. Халыкка иярергә түгел, ияртеп югарыга, яктыга тартырга кирәк.

– Консерватория югары белемле музыкантлар һәм җырчылар әзерли. Укуны тәмамлаучылар операга гына китеп бетми, эстрадага менүчеләр дә була. Сез әйткән таләпләргә туры килерлек, сүзне, телне аңлап аның тәмен тоярдай белгечләр әзерләү юнәлешендә нинди эшләр башкарыла?

– Опера классында без студентларның теге яки бу операны уйнаганда ачык, аңлаешлы сөйләвенә ирешергә тырышабыз. Режиссер, дирижер һәм педагоглар аларга интонация байлыгын үзләштерергә, астекстны (подтекст) аңларга өйрәтә. Татар студентлары Рафаэль Сәхәбиев җитәкчелегендә Җәүдәт Фәйзинең "Башмагым" музыкаль комедиясеннән өзекләр куярга теләк белдерде. Актер осталыгы дәресләрендә исә төрле пьесалардан татарча өзекләр уйнала.

Вокалист – ул музыкант һәм актер. Шуны истә тотып, аларга сәхнә хәрәкәте, бию, грим, актер осталыгы белән беррәттән, сөйләм культурасы да кертелә. Бездә бу предметны озак еллар буе СССРның халык артисты Николай Якушенко, соңрак Элла Ригорина һәм Якушенконың кызы Виктория Николаевна алып барды. Бу дәресләрдә студентлар сөйләм аппаратын төгәл, аның, дөрес итеп эшкә җигәргә өйрәнә, "Сүз, Әдәбият" дигән олы могҗизаның серләрен үзләштерә.

Әңгәмәне ***Илдар КЫЯМОВ***
үткәрде.

И туган тел...
1998 ел
27 февраль
№ 2 (54)

Ызгышырга нигез юк

(Өзекләр)

Тургай сайрый үз телендә,
Сандугач – үз телендә.
Өстен телләр, мескен телләр
Юк табигать илендә.
Саескан да, каргалар да,
Тартар яки бүдәнә -
Һәркайсысы үз телендә
Рәхәтләнеп сөйләшә.
Бер урманга бар да сыя,
Беркем тоймый көйсезлек.
Тавышларның күплегеннән
Арта гына хозурлык.
Уйласаң, уйларга чумып
Хәйран булып торырлык.

Фәнис ЯРУЛЛИН.

Болыт чыга да
яңгыр яумый
җирне алдый;
Галим чыга да
гыйлемен чәчми
илне алдый.

Наданның
сукырдан
аермасы юк.

Этимологик табышлар

Кәз

Чуашча **касы "квартал"** сүзе борынгы **кәзе** сүзенә кайтып кала һәм бу сүз борынгы татар телендә дә булган булса кирәк. Шуннан чыгып, татар әдәби теленә шул **кәзе (кәзиг)** сүзен кайтарырга мөмкин (ә бәлки, шундый сүз татар сөйләшләрендә әле һаман очрый торгандыр).

Кәзиг нигезе борынгы **кәз** тамырына сыйфат ясагыч -иг кушымчасы кушылып ясалган. "Тигез өлешләрнең берсе" төшенчәсе мәйданга да, вакытка да, авырлыкка да карый ала. Шунлыктан борынгы **кәз** тамырыннан ясалган сүзләр бик күп була ала. Ихтимал, татарча **кәз, кәс "буразна, тигез өлешләргә киселгән чирәм, кирпеч"** сүзе шул тамырның бер чагылышыдыр.

Тарихи фонетика мәгълүматлары буенча **кәз** яңгырашы борынгы **кәр** яңгырашыннан килә. Ихтимал, кирпеч (борынгыча **кәрпич**) сүзе дә шуннандыр. Чуашча **кар** (борынгы **кәрдән**) **"тигез, төзек бүленеш"** сүзе дә фаразыбызга туры килә.

Гомумән, төрки һәм монгол телләрендә борынгы инәкә (прототөрки) **кәр/кәз** тамырыннан ясалган күпсанлы сүзләрне барлап чыгу – үзе бер диссертациялек эш. Берәр яшь кеше шул эшне башкарып чыкса, кызык булыр иде.

Келиндер һәм калач

Татар әдәби телендә (мәсәлән, Сибгат Хәким шигырьләрендә **келиндер,** татар сөйләшләрендә **керәндил** сүзе урысча **крендель** сүзеннән, ә урыс сүзе исә нимесчә **кренгель "келиндер,** уртасы тишекле күмәч" сүзеннән килә.

Шунысы кызыклы ки, уртасы тишекле икмәк, күмәч төрки халыкларда күптәннән билгеле булып, ул **калач, кәләч** дип аталып килгән. Кайбер тикшеренүләр бу сүзнең таралуын нәүрүз бәйрәме йолалары илә баглыйлар: кайбер якларда нәүрүзче малайлар урам буйлап нәүрүз бәетләрен такмаклап йөргәндә һәр өйнең ишегенә, үзләре кермичә генә, нәүрүз таягы тыгалар һәм хуҗабикәләр шул таякка уртасы тишекле күмәч элеп куялар.

Икенче бер версия буенча **калач** – бауга тезеп йөртү өчен юлчыларга пешерелгән ашамлык.

Калач сүзе урыс телендә дә бар. Әмма ул төп төрки сүз булса кирәк. Алтай-Саян төркиләрендә **калач** дип бер яклы **барабанчык-тәңгерне** атыйлар.

Урыс этимологиясендә **калач** "түгәрәк ак ипи" борынгы **коло** "түгәрәк, тәгәрмәч" сүзе белән чагыштырыла. Ләкин сүзнең ясалыш моделе ачыкланмыйча кала. Төрки телләрдә әлеге татар исеменнән тыш **калач** дигән кабилә атамасы да билгеле.

Киңәш

Татар телендә **киңәш** дигән исем һәм **киңәш-ү** дигән фигыль бар. Алар (һәм гомумән шундый төрдәге омонимнар) бер-берсенә турыдан-туры баглы түгел. Ләкин аларның ясагыч нигезе бер – борынгы **кәңә** – (уйгурча **кәңә-**) "киңәш сорау, киңәш бирү" фигыле. Киңәш "акыл бирү", ә киңәш-ү "бер-беренә акыл бирү, акыллашу" – **кәңә** – фигыленең уртаклык юнәлеше.

Кәңә– фигыле, үз чиратында **кәң, кәйң** "ханның юраучысы һәм акыл бирүчесе" сүзеннән ясалган ("Идегәй" дастанындагы **Киң Җанбай** – Туктамыш ханның киңәшчесе – **"киң"** булмаган, ә юраучы-акылчы булган). **Кәң** тамырын корей телендәге **кәйңкәй** "киңәш" сүзе белән чагыштыралар. Башта **кәйңкәй, кәйңкә** сүзе "юрау кыңгыравын (шуның тавышына карап киләчәк юралган)" белдергән дигән фикер бар.

Рифкат ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре
докторы, профессор.

Кич утырганда

Сөйләм чарлар чаралар

Ак аксым акрын ага.
Аталган атаклы атны ата.
Байгыш баегач байый.
Башка башак башы.
Бизмичә бизәклә.
Йомран йомшак йомгакта.
Каекчы кайракчыга кайрак кайтарды.

Сөйләм чарлатучы
Равил ҺАДИ.

КИЛӘСЕ САННАРДА:

- ***Туган телне – гамәлгә! Район, шәһәрләрдә Тел программалары ничек үтәлә.***
- ***Гаяз Исхакый мирасыннан.***
- ***Тел олимпиадасыннан соң уйлану. Яңалыклар һәм кабатлаулар.***
- ***Укучыларыбыз иҗаты.***
- ***Кич утырганда.***
- ***Агач авыз – балта тел.***

Кушымтаның
мөхәррире
Илдар НИЗАМОВ.

Адресыбыз:
Бауман урамы, 19.

Бикә РӘХИМОВА

"Коткару килер, көтегез!"

(Хикәя)

(Ахыры. Дәвамы 10 нчы биттә).

Нурания Габбасовна аңа берәр сүз әйтергә өлгергәнче, Г.Тукай: "Коткару килер, көтегез!" – диде һәм шунда ук юкка да чыкты. Гаҗәп, искиткеч төш. Кайсы афәтләрдән татарның котылачагына ишарә ясады икән сөекле шагыйребез рухы? Татар мәктәпләре кире кайтырмы икән? Татар тормышы аякка басар микән? Әллә соң, бөтенләй дә татар дәүләте торгызылырмы икән? Тукай кадәр Тукай кечкенә нәрсәгә генә өметләндермәстер... Шундый фантастик төшләр-уйлар белән йөргәндә, чынлап та әллә нинди көтелмәгән үзгәрешләр башланып китте бит, әй! Чынлап торып татар мәктәпләре, гимназияләре ачыла башлады. Билгеле инде, бу илдәге гадәт буенча, аларны ачтырмаска тырышу да көчле аскы агым булып акты, безелдәүче чебен-черки булып та изалады. Ни генә булмасын, ачылулары хак. Күңелле хәлләрдән шатлык эченә сыймый йөргән көннәрдә Нурания Габбасовна өчен тагын бер көтелмәгәнрәк хәл килеп чыкты, дөресрәге, бу хәл аның үз эчендә, үз табигатендә иде. Күрәсең, теге елларда ул үзе дә сизмәгән киеренкелектә эшләгән булган, шул хәлен ирек, татар мәктәпләре, татар телен укыту өчен шактый уңайлыклар килгәч кенә тоеп, үзен иркенгә җибәреп, йомшап төште: аның мәктәптә эшләрлек хәле калмаган икән. Ял, ял кирәк. Булды. Аның намусы авыр елларда пычранмады. Чалгы күтәрә алмаган урак тота торсын, дигән сүз бар. Менә шул уракчылар – яңа, яшь укытучылар, шөкер, чалгы тотарлык булып җитештеләр. Бервакыт Нурания Габбасовна "Дөнья тирәли" дигән журналдан бер галимнең, укытучы сигез ел мәктәптә эшләгәннән соң "туза", дип исбатлаган мәкаләсен укыган иде. Булса да булыр, тузасыңдыр, сигез генә түгел, күбрәк еллар укытсаң, бигрәк тә урыс мәктәбендә татар телен факультатив укытсаң... Хәер, нигә әле зарланырга? Аның укучыларыннан татар халкына хезмәт итүче мәдәният хезмәткәрләре чыкмадылармыни? Чыктылар. Әле хәзер дә гөлт итеп, асыл таштай ялтырап, яктылык чәчеп эшләп йөриләр. Күбесе мәктәпне тәмамлап чыккач, Казаннан авылга дисеңме, яисә солдаттан әти-әнисенәме татарча хатлар язганнарын үзләре, әтисе, әнисе килеп тә әйтәләр иде.

Тик хәзер тагын да эшли алмас, арыды, туарылды...

...Нурания Габбасовна гаиләсе белән шәһәрнең икенче бер яңа бүлгесенә, яңа фатирга күчкән иде, шунда, алар өенә каршы гына татар гимназиясе ачылды. Беренче сентябрь көнне мәктәп ишегалды чәчкәле матур болынны хәтерләтә, бөтен тирә-юньгә музыка яңгырый, сөекле туган телебез авазлары колакка ирешә... Нурания Габбасовнаның шул сәгатьләрдә йөрәге ләззәтле сулкылдый, ул тәрәзәләрне ачып куя, аннары бөтенләй дә урамга чыга, мәктәпкә йөгереп барып кереп дәрес башлардай булып дулкынлана, тик урыныннан кузгалмый, ә инде мәктәп ишегалдын тутырган укучылар беренче дәрескә кереп киткәч, эскәмиягә килеп утыра. "Сөбханалла, игелекле Тукай бабабыз рухы әйткән сүзләр – "Коткару килер, көтегез!"

– шушы буладыр инде! Әллә соң бөегебез безгә тагын да зуррак шатлыклар ишарәлидеме икән?.. – дип үзалдына уйланып утыра иде, бәләкәй кызын гимназиягә озаткан күршесе Сания кайтып килә икән:

– Исәнмесез, Нурания апа! – диде ул һәм ялт итеп кенә ишектән кереп югалды.

Нурания Габбасовна үзалдына елмаеп куйды: үзенә карата әйтелгән "апа" сүзен ул бирегә күчеп килгәч ишетә башлады. Югыйсә, гомере буе диярлек Нурания Габбасовна булып йөргән иде... Үзебезчә эндәшкәндә нинди күңелле икән. Нурания апа – матур яңгырый. Рәхмәт әтисенә, әнисенә, матур исем кушканнар. Их, үзләре дә исән булса!.. Шунда төшке әбәткә кайтасы үз кызы белән ире исенә төшеп, кузгаласы итте дә тәмле ашлар пешермәк булып фатирына кереп китте...

ЙОЛДЫЗНАМӘ (2 - 8 март)

КУЧКАР (21.03-20.04). Март сезнең өчен уңышлы ай. Ә аның беренче атнасына килгәндә, сезгә мул табыш керә. Тормышта рухи, гамәли үсеш кичерәсез. Яңа очрашулар, шактый нигезле уйланган сәфәр көтә. Тик аның нәтиҗәсе бүген-иртәгә булыр дип ашыкмагыз. Эшегезнең нәтиҗәсе зурдан булыр, ай дәвамында керем килер. 5се көнне иң мөһим проектка алыныгыз, ул сезнең көн.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). Яз сезнең өчен бәхетле мизгелләрдән, бәхетсөенечләрдән башланса да, 2се көнне бәхәскә кермәскә тырышыгыз. Сезгә илаһи серле көчләр ярдәмгә килер, аннан баш тартырга, читләшергә ашыкмагыз. 3, 4е көнне үзегезнең яшәү рәвешенә бәя биреп, яман нәрсәләрдән арыну, чистарыну ягын карагыз. Изге эшләргә алыныгыз. 6сы көнне бәхетсезлекләрдән, 7се көнне акча, матди югалтулар кичерүдән сакланыгыз.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05-21.06). 6сы көнне иң зур эшләргә нигез салыгыз, ул мөһим мәсьәләләрне хәл итү көне. 4, 5е көнне финанс эшендә дөрес юл сайлый белүегез таләп ителә. Аз гына ялгышлык җибәрү дә сезнең матди хәлегезгә зыян китерәчәк. 7, 8е көннәрендә ызгыш-талашларга кермәскә тырышыгыз, чөнки бик күңелсез хәлләргә төшүегез, язмышыгызның бөтенләй башка юлдан китү ихтималы бар.

КЫСЛА (22.06-22.07). 2, 4, 5, 8е сезнең өчен уңышлы көннәр. Сезнең өчен көтелмәгән, әмма күңелле, сөенечле вакыйгаларның шаһите булырсыз, эшегездә үсеш кичерерсез, күңел төпкелләрендә генә йөрткән изге ниятегезгә ирешерсез, эшлекле мөнәсәбәтләрегез гаять зур нәтиҗәләр бирер һәм илаһи серле көчләр карамагында булырсыз. Галәм киңлекләре серләре килеп ирешер. Иң мөһиме – сәламәтлегегезне кайгыртыгыз, күбрәк табигать кочагына чыгыгыз.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). Изге ният белән чыккан сәфәрегез уңар һәм шуның нәтиҗәсе буларак, табыш керер. Серле көчләр сезнең күңел төпкелләрегезгә килеп кагылыр, аларны аңларга тырышыгыз. Рухи ихтыяҗыгыз гыйбадәтханәгә чакырса, барыгыз, дога кылыгыз, әрвахларны искә алыгыз һәм аларның җаннарына тынычлык, хәерле урнашу килсен өчен ятимнәргә сәдака бирегез. 6сы көнне юл фаҗигаләреннән, 7, 8е бәхәсләрдән сакланыгыз.

КЫЗ (24.08-23.09). Атна эшлекле мөнәсәбәттән, зур проектларга керешүдән башланып китә. Ләкин көтелмәгән хәлләр сезнең төшенкелеккә бирелүгә сәбәпче булырга тора. Ихтыяр көчегезне туплап, үз-үзегезне кулга алыгыз да, яшәештә килеп чыккан вак-төякләрдән өстен булып калыгыз. 5се көнне эштә, юл йөргәндә, транспортта кагыйдәләрне төгәл үтәгез, бәхетсезлектән сакланыгыз. 7се – бәйрәм алдыннан, акча мәсьәләсендә тыйнаклык, сабырлык күрсәтегез, юкка әрәм-шәрәм итмәгез.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). 3, 4, 5, 7, 8е сезнең өчен гаҗәп уңайлы көннәр. Тормышыгыз, гаилә мөнәсәбәтләрегез, эшләрегез, матди хәлегез гел үсеш юлында. Сез бәхетле, сез яшәештән канәгать.

ЧАЯН (24.10-22.11). Мартның ике көне сезгә күңелсез хәбәрләр, вакыйгалар ирештерсә дә, атнаның калган көннәре сезгә шәфкатьле. Сез эзләнүдә, сәяхәттә, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда, чөнки илаһи көчләр сезгә юлдаш, уңышларга сәбәпче.

УКЧЫ (23.11-21.12). 5, 7, 8е сезнең өчен уңышлы көннәр. Сез ихтыяр көчегезне туплап төрле кирәкмәс сүзләрдән, бәхәсләрдән читтә калырга тырышыгыз. Бу атна сездән сабырлык таләп итәчәк. Иң беренчел булып сәламәтлек алгы планга чыга, һәм сез шушы өлкәдә армыйталмый шөгыльләнергә тиешсез. Финанс мәсьәләсе дә игътибар сорый. Атна башында акчагызга сакчыллык күрсәтегез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). Март сезне тагын да баетудан башланып китә. Сез эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырасыз, шуның нигезендә зур матди табыш аласыз. Ул сезне кабат хезмәттәшлеккә әнди һәм сәфәр чыгара. Ләкин артык матдиләшү сезнең дусларыгызны, хәтта иң якыннарыгызны да читләштерә. Фани дөньяда җан азыгы барлыгын да онытмагыз.

СУКОЯР (21.01-19.02). Яз ае сезгә рәхимле карый. Сез үсештә. Күптәнге ниятегезнең гамәлгә ашуын күрерсез. Сез илаһи серле көчләр карамагында. Үзегезне ача белегез, җан таләбенә игътибарлы булыгыз. 4, 8е көнне барлык вак-төяк эшләрне үз өстегезгә алыгыз, гаиләгезне сөендерегез. 6сы көнне фаҗигаләрдән сакланыгыз, юл йөргәндә кагыйдәләрне төгәл үтәгез.

БАЛЫК (20.02-20.03). Бу, чын мәгънәсендә, сезнең өчен элемтәләр урнаштыру атнасы. Бу элемтәләр эшлекле дә, дустанә дә, мәхәббәт өлкәсендә дә булыр. 5се көнне финанс, бизнес мәсьәләсендә сакчыллык таләп ителә. Ә 6сы көнне зур эшләргә алынмагыз, гадәти эшләр белән шөгыльләнегез.

Йолдызнамә. Балыклар, сезнең өчен! (20.02-20.03)

Балыклар 20 февральдән алып 20 мартка кадәр идарә ителәр. Ул сулы, үзгәрешле, каршылыклы билге. Аның билгесе дә капма-каршы якка йөзүче ике балыкны күрсәтә. Бу – билгенең холкын да ачып сала.

Балыклар шактый тирәндә, икенчел дөньяда яшиләр. Алар вакытларын медитациядә, спиритизмда, күрәзәчелек итеп үткәрәләр. Алар үз дөньяларында еш кына уйдырмалар, иллюзияләр белән яшиләр. Бу дөнья аларга буйсына. Чөнки аларның тәэсир итү көче эпифизга, ягъни өченче күз өлкәсенә туры килә.

Балыклар Кояш хәрәкәтенең еллык тәгалләнүен билгелиләр. Йолдызнамәдә алар Уникенче йортка урнашканнар. Бу йорт хакында төрле фикерләр дә бар. Аны "Яшерен дошманнар йорты", "Үз-үзеңне һәлак итү" дип тә йөртәләр. Ул шәхси ирек, үз-үзеңне корбан итү, тормыштан читләшү дәрәҗәсен тикшерә.

Балыклар кеше организмындагы барлык җепселләр бергә тупланган урын – аяк табаны белән идарә итәләр. Алар табаннан тыш ашказанына, бөер өлкәсенә һәм сыеклык тупланган урыннарга тәэсир итәләр.

Балыкларда авырулар еш кына иммунитет йомшаклыгыннан була, шлакларны чыгаруда баланс сакланмау сәбәпле, шешенүләр, диабет, симерү, кызышу, тиредә гөмбә авырулары килеп чыга.

Балыкларның эмоциональ халәте еш үзгәрү сәбәпле, аларда күңел күтәренкелеге вә төшенкелеге күзәтелә, хәтта дару белән дәвалап булмаслык хәлгә җитешеп, депрессиягә бирелә ләр.

Балыкларны дәвалауга килгәндә, медикаментларны еш алмаштыру кирәк, чөнки алар даруга тиз күнегәләр һәм дәвалау сәләте кими. Шунысын да онытмаска кирәк, Балыкларның даруны тәннән чыгару көче начар.

Зодиак билгесендәгеләрдән Балыклар – иң көчсез иммун эшчәнлекле һәм калдыкларны иң начар чыгаручылардан. Шуңа күрә алар тартуга, наркоманиягә, эчүчелеккә тиз бирешәләр. Балыкларның бу йомшаклыкларына гадәти булмаган ысуллар белән тәэсир итү, туктату, чикләү мөмкин түгел. Кодлаштырып вакытыгызны әрәм итмәгез, нәтиҗәсе булмас.

Әлеге билгенең күзәнәк тозы – тимер фосфаты. Ул кузаклыларда, бавырда, яңа өзелгән кыярда, салатта, йөземдә күп. Балыклар йод азлыгын тиз тоемлыйлар. Аны теләсә нинди су асты байлыклары яки йод белән баетылган азык тозы белән тулыландырырга мөмкин. Йод җитешмәүне хатын-кызлар авыр кичерә. Бу аеруча гормональ үзгәрешләр кичергән чорга – күрем башлануга һәм күрем бетү вакытына туры килә.

Бу билгегә туры килә торган үләннәр: акчәчәк, кычыткан, календула, юкә чәчәге. Атнага бер мәртәбә шушы үләннәр төнәтмәсеннән (1 литр суга 1 чәй кашыгы) тәнгә ванна ясарга кирәк.

Балыкларның аяк табаны белән идарә итүен искә алсак, борынгыларның табан аша ничек итеп тулаем организмга тәэсир итүен хәтергә төшерү мөһим. Мәсәлән, борынгы грек философы Сократ "фикер йөрешен тирәнәйтү максатыннан" даими рәвештә яланаяк йөргән һәм башкалардан да шуны таләп иткән. Сенека да шулай яланаяк йөргән.

Җәй көне җирдә, кыш көне карда яланаяк йөрү Балыклар организмын ныгытуда мөһим чара. Әмма ул Балыклардан ихтыяр көче таләп итә. Бу массаж гына түгел, ә актив терморегулярлау чарасы.

Шәхси, гаилә, сексуаль мөнәсәбәтләрдә Балыклар башлап йөрүче түгел. Шуңа күрә алар үз дөньялары белән чикләнеп яшәсәләр дә, чынбарлыкка каршы баруга сәләтсезләр. Алар өчен гармонияле партнерлар, әлбәттә, Балыклар, яшь вакытта Кысла һәм Чаян, өлкән яшьтә – интеллектуаль Сукоярлар һәм Кыз.

* * *

Балыкларның хисләреннән файдаланыгыз. Тирән тоемлауга ия, игътибарлы Балыклар кызганучан җаннар. Аз гына төнкыйть тә аларның күңелен җәрәхәтли. Алар алданырга теләмиләр һәм үзләренең ихласлыгына шикләнеп карауны авыр кичерәләр. Балыкларның күңеленә тия торган бер генә сүз дә әйтмәгез.

* * *

Балыклар Балыклар белән мәхәббәттә уртак тел табар. Кәҗәмөгез белән аның сөю вә сөелүдә эше пешәр. Кучкар һәм Чаян белән ул бәхәскә керсә дә, хис-тойгылары сакланыр. Балыкларның Игезәкләр, Үлчәү, Укчы белән мөнәсәбәтләрендә ызгыш-талаш, бәхәс булыр. Балыкларның Кыз белән яңа мөнәсәбәтләр урнаштыруы ихтимал. Балыклар Сукоярга боздай салкын караш та тора.

* * *

Балыкларның асылташы – Ай ташы. Ай ташы мәхәббәт мәсьәләләрен хәл итүдә көчле йогынты ясый. Ул уңышка, тынычлыкка, бәхеткә илтә. Тулы ай вакытында туган кешеләргә әлеге ташны талисман итеп йөртү кирәк. Ул куркуны, стрессларны бетерә. Көмешләнгән таш нерв эшчәнлеген җайга сала. Ай ташы эпилепсияне, чахотка, бөер авыруларын, гормональ үзгәрешләрне, депрессияләрне, сары авыруын дәвалый һәм ашказаны, ашказаны асты бизе, үт эшчәнлеген яхшырта.

Җавап-савап

Безгә мирас тияме?

Минем кооператив фатирымда, теркәлү үтеп, әти-әнием һәм энем яши. Фатир минем исемгә хосусыйлаштырылган. Үзем хатын фатирында яшим. Авылда әти-әнинең үз йортлары бар. Минем аларны шәһәрдәге фатирдан чыгарырга хокукым бармы?

С.Вагыйзов.

Әгәр туганнарыгыз фатирыгыздан үз ихтыярлары белән чыгарга теләмәсә, судка мөрәҗәгать итә аласыз. Татарстанда гражданнарны тору урынында теркәү буенча вакытлы кагыйдәләрнең 10 нчы пунктына нигезләнеп, гражданнарны пропискадан төшерү түбәндәге очракларда эшләнә: яшәү урынын алмаштыру – гражданның яңа урындагы теркәлү бүлегенә язган гаризасы нигезендә; хәрби хезмәткә чакыру – хәрби комиссариат хәбәре буенча; суд хөкеме буенча; хәбәрсез юкка чыккан дип танылган очракта – монысы да суд карары белән; үлгән дип танылуы (үлеме турындагы таныклык) закон тәртибендә рәсмиләштерелгәч; торак мәйданнан чыгарылу яки торак мәйданына булган хокукын югалту (суд карары белән); теркәлүне нигезләүче документларның чынбарлыкка туры килмәве ачыклану; теркәлү үткәндә дәүләт хезмәткәренең хокукка сыймаган эшләре ачылса (суд карары белән).

Без өч туган ике бүлмәле фатирыбызны хосусыйлаштырдык. Олы апабызга 87 яшь. Варислары юк. Вафатыннан соң аның фатирдагы өлеше безгә турыдан-туры мирас булып күчәме, әллә васыять язуы кирәкме?

А.Садретдинова.

Русия Федерациясе гражданлык кодексының 532 нче маддәсе нигезендә, закон буенча тигез өлешкә хокуклы варислар итеп, беренче чиратта, балалары (улыкка алынганнары да), ире һәм әти-әнисе (уллыкка алган кешеләр) санала. Икенче чираттагы варислар: вафат булган кешенең, ир һәм кыз туганнары, әбисе һәм бабасы (ике яктан да). Икенче чираттагы варислар закон буенча беренче чират варислар булмаган яки алар мирасны алырга теләмәгән (баш тарткан) очракта һәм, шулай ук, вафат булган кешедән васыятьтә өлеш язылмаган яки өлеш бирүдән баш тарткан очракта гына мираска ия булалар. Закон буенча мирас тиешле кешеләр исәбенә вафат булган кеше кулында яшәгән (иждевенец) һәм аның вафатына кадәр бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә бергә яшәгән кешеләр керә. Башка варислар булган очракта да аларга тигез күләмдә мирас тиеш. Оныкларга да, әгәр аның әтисе, йә әнисе мирас иясеннән алда вафат булса, мирастан өлеш тия. Уллыкка алынганнар һәм аларның дәвамчыларының (балалары, оныклары) да мираска хокуклары бар. Ә менә уллыкка алынган кешенең әти-әнисе, канкардәшләре, аларның оныклары мирас ала алмый. Шулай итеп, Закон буенча сезнең мирас алырга хокукыгыз юк. Олы апагыз мирасны сезгә калдыруы турында гариза-васыять язганда гына мираска хокукыгыз була.

Җавап-савап

Фәнис ЯРУЛЛИН:

Кап-кара күзләрем белән Ап-ак дөньяны күрәм

Фәнис янына килеп күрешүгә, алтмыш өченче елларда, "Яшь ленинчы"да эшләгән чакта, редакциябез белән аның янына баруыбыз исемә төште. Мин ул чакта Фәнис янында үземне шундый яхшы, рәхәт хис иттем, бу хакта аның яныннан кайткач, редакциядәге иптәшләремә дә сөйләгән идем.

Бүген дә Фәнис белән күрешкәч шул мизгелләр искә төште. Бүген дә аның белән күрешүгә үк нишләптер күңелем күтәрелеп китте.

Аның:
Дөньяны каргаганым юк,
Кайгым булса да тирән.
Кап-кара күзләрем белән
Ап-ак дөньяны күрәм, -
дип язуы юкка түгелдер.

Шуны Фәниснең үзенә дә әйттем. Кайбер кешеләр энергияне суыра, ул вампир, дип әйтәләр, мин әйтәм, ә син үзең бүтәннәргә якты энергия өләшәсең ахры.

– Бәлки шулайдыр, – дип, Фәнис елмаеп кына куйды. – И, мин сезнең ул "Яшь ленинчы"дан килгәнегезне бик яхшы хәтерлим. 1963 ел иде ул. Миңа бер бүлмәле фатир биргәннәр иде. Әнкәй пенсия алмый. Бернәрсәбез юк. Язучылар берлегеннән 100 сум акча бирделәр. Шуңа бер карават, бер өстәл, ике урындык сатып алдык. Ә сез бик матур кыңгырау чәчкәсе төшкән, үзе дә кыңгырау чәчкәсе формалы чынаяк алып килдегез.

– И, менә шул чынаякны төшереп ваттым бит мин... – диде үкенүле тавыш белән сүзгә кушылган Нурсөя. – И ачуланды Фәнис! Шунда гына белдем мин аның яшь ленинчылар бүләге икәнен. Фәнис бик тәфсилләп сөйләде ул турыда.

– Ул чакларны искә төшереп әйбәт иттегез, – диде Фәнис. – Үзем дә шул вакытларны искә төшереп ята идем әле. Ул чакта кеше күңелендә мәрхәмәт күбрәк иде. Хастаханәләрдә бик күп яттым бит инде. Олы-олы язучылар килә иде хәлемне белергә. Абдулла абый Гомәр бар иде бит әле, "Совет әдәбияты" журналы мөхәррире. Язучылардан автографлар алып, китаплар җыеп китергән иде. Сибгат абый Хәким дә бик якын итте, башкалар да. Мин бит әле авылдан гына килгән малай, яза да башламаган. Аларның ышанычы көч биргәндер инде.

– Ә ничек яза башладың, Фәнис?

– Шигырьләр яза башлавым 1958-59 елларга туры килә. Бүлнистә ятканда. Соңгы вариантына хәтле күңелдән уйлап бетерәсең. Аннары берәр татарча яза белүчегә әйтеп яздырасың. (Үземнең кул-бармак эшләми бит әле.) Алай бик уңайсыз. Язу бит ул яшерен эш, аның тәмам формасы килмичә кешегә күрсәтергә дә теләмисең... Ә редакциягә җибәргәндә аларын уйламыйсың инде, аларны күрмисең бит. Ичмасам, йә басыла, йә юк, дип хат яза торганнар иде элек. Ә хәзер телефоннан гына булса да әйтмиләр. Кешене сөендерәселәре килмиме. Үзебезнең буын шушындыйга әйләнде, яшьләрне әйткән дә юк. Бер-береңә игътибар юк, югыйсә, язучыга кешенең игътибары университетка караганда да кирәгрәк. Горькийлар, Ибраһимовлар университетларда укымаган, ә ниләр генә эшләмәгәннәр...

Шул елларга кире кайтыйм әле. 1963-64 елларда минем шигырьләр дә күп чыкты, кызлар да күп килде яныма.Минем бәхеткә булгандыр инде... 1964 елда "Комсомольская правда"да конкурс оештырылган иде. Шунда минем шигырьләр икенче урынны алды. Конкурста катнашкан шигырьләрдән "Золотой олень" дигән җыентык та бастырып чыгардылар. Аннары бер инглиз атналык басмасында шигырьләрем басылган иде. 50 яшем тулганда күргәзмә оештырдылар да, кызганыч, ул атналык гәзит шунда югалды...

– Нурсөя белән ничек танышканыңны сөйлә әле, Фәнис?

– Үзеннән-үзе генә, сәбәпсез генә дөньяда бер нәрсә дә эшләнми. Әгәр минем укуга омтылышым зур булып, мин шул урын өстендә яткан килеш мәктәптә укып ятмасам, яныма укытучылар, укучы, эшче кызлар килеп йөрмәс иде. Урыс теле укытучысы Виктория Зайцева белән бергә килде яныма Нурсөя. Хәлемне белергә дип инде... Укырга омтылу шулай итеп Нурсөя белән танышуга сәбәп булды.

– Ничегрәк яшисез, гомерегез ничек уза?

● *Ф.Яруллин – 18 нче эшче-яшьләр мәктәбе укучысы. Аның янына физика укытучысы Наилә Гатауллина килгән. 1963 ел.*
Ә.ШАКИРҖАНОВ фотосы.

– Бергә яшәвебезгә инде утыз елдан артты, бер-беребезнең холкын беләбез, дигәндәй. Ул бит төнлә торып кына да мине биш-алты тапкыр әйләндерә. Юындыра да, туалетына да, һава суларга да алып чыга.

Барлык әсәрләремне, пьесаларымны ике-өч тапкыр машинкада гына баса. Илтә, алып кайта. Үземне җәй буе машинада йөртә. Без хастаханәгә дә бергә керәбез. Имгәнгәч, ун ай буена госпитальдә ятып, минем бит гәүдәмдә бер карыш исән тире калмады, бөтен җир череде. (Армиядә солдатка мөнәсәбәт бик начар иде бит. Кеше итеп карамыйлар, кешенең күңеле юк кебек. Приказ гына бар!) Хәзер шул яралар әледән-әле ачылып тора. Нурсөя шәфкать туташы эшен дә үзе башкара. Кешене карый торган робот юк шул. Нурсөянең күп вакытын физик эш ала, ә күңел өчен вакыт аз кала.

Нигә шагыйрь:
Күргән саен дөнья гыйбрәтләрен,
Рәхмәтләрем сиңа арта бара.
Көн дә чагылып торган кешелегең
Күңелемне үзеңә тарта бара.
***
Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Нәрсә әйтер миңа сөйгән ярым:
Ул бит мине егерме ел буе
Кулларында йөртә, түкми зарын, -
дип язмасын әле!!!

– Төрле (һәм тегенди һәм мондый) изелүләрдән исән калгач, Ходай миңа көчне биргән инде, Аллага шөкер!

Мин бер тамчы, тозлы тамчы,
Булды минем язмыш ачы
Авыр, озын юллар үттем
Зур диңгезгә кушылганчы.

Әйе, гомеренең һәр сәгатен, һәр минутын көрәштә үткәргән шагыйрьгә бүген – 60 яшь!

– Нурсөя белән үпкәләшкән чакларыгыз да буламы?

– Була инде, тормыш булгач күңел төшенке чаклар да, үпкәләшкән чаклар да була. Әмма нахак сүзләр, кичерелми торган сүзләр әйтелмәгәндер... Кайчак бик аздан да бәхәс куба торган була бит. Ләкин ул тирәнгә керми, бер-беребезнең йөрәген җәрәхәтләрлек сүзләр әйтешкән юк, Аллага шөкер!

Шуңадыр шул, 1980 елда Фәнис:
Бер тамчыдан диңгез булмый, диләр,
Ә син менә
Кайнар тамчы булып тамдың да,
Шаулап торган диңгез хасил иттең
Мәңгелеккә минем җанымда, –
дип язгандыр.

Әйе, әйе, диңгез ул Нурсөя, шаулап торган диңгез! Аларга кыска гына вакытка барып кайткан арада да, ул үзе редакциябез бүлмәсенә кереп чыккан арада да шаугөр килеп үзләрендә булган хәлләрне-яңалыкларны, дөнья хәлләрен сөйләп ала, үзе сораштыра, теге яки бу вакыйга хакында фикере белән уртаклаша.

– Бәхет мәсьәләсендә ничегрәк фикер йөртәсең, Фәнис?

– Бәхетсез булдым, дип тә әйтә алмыйм. Сәламәт кеше эшләгәнне эшләдем...

Алай гынамы соң? Һәр сәламәт язучы Тукай, Җәлил бүләге иясеме!

Укучым да күп булды, хакимият тарафыннан да типкедә йөрмәдем. Танылылар.

Әмма:
Сагышларны миңа язмыш бирде,
Ә моңнарым булган тумыштан.
Бәхет белән шатлыкларны гына
Гел көрәшеп алам тормыштан.
Әйе, шатлык-бәхетнең һәр бөртеген! Көрәшеп! 40 ел буена! Урын өстендә ул 40 ел ята!

Кешенең личное обаяниесе дә булырга тиеш бит әле! – дип дәвам итте Фәнис сүзен. – Мин күп кеше белән очрашам. Дусларым күп. Шунысы кызык, минем янга бер килгән кеше икенче тапкыр килми калмый.

Бер-ике шигырен генә укыйм әле дип, аның китабын кулыңа алсаң, башыннан ахырына кадәр барып чыкмыйча китапны кулыңнан куям димә: "личное обаяниесе" эченә, аның күңел җылысы эченә кереп чумасың...

Фәнис минем уку турындагы фикеремә кушылып киткәндәй булды:

–...Студент чакта күп укыдым. Программа буенча гына түгел. Периодик басмаларны – "Новый мир", "Дружба народов", "Юность", "Аврора" һәм башка журналларны. Вак хәрефле язмаларына хәтле берсен дә калдырмый идем. "Литературная газета"ны бер көндә укып чыга идем. Уку күп вакытны ала. Хәзер "Мәдәни җомга"ны да ике көн укыйм.

– Бүгенге әдәбиятыбызга, ниндирәк бәя бирер идең?

– Үз дәүләтчелегебез булса, безнең күп язучылар тәрҗемә ителер иде. Югыйсә, көчле әйберләр әрәм булып кала, башка тел аша тәрҗемә иткәндә күп байлык югала. Үз-үзебезне күрсәтергә куркабыз, оялабыз...

– Әнә ПЭН-үзәк күрсәтергә ниятли инде...

– Кешенең иҗатын вакытында күрсәң, поддержать итсәң, үсеп китү мөмкинлеге була. Мине дә бит Марс Шабаев табып алып, дигәндәй, әсәрләремне "Яшь ленинчы"да, "Татарстан яшьләре"ндә чыгарды.

– Әңгәмәң өчен рәхмәт, Фәнис. Нурсөя белән икегезгә игелекле гомер, җан тынычлыгы телибез.

Әңгәмәне Саимә **ИБРАҺИМОВА** үткәрде.

Әмирхан морза могҗизасы

(Дәвамы. Башы 8 нче санда).

Икенче көнне гарәп хәрефләре белән язылган, кечкенә китапны Әмирхан абыйга китереп бирәм. Сакланып кына полиэтилен капчыктан китапны ала да, сыпыргалап, зур саклык белән битләрен ача, укыштыргалап карый. Берничә битен ачып карагач китапны яба да:

– Син бу асыл китапны миңа калдыр инде, Зәки. Көн саен берәр, икешәр битләп кенә укып ләззәтләнерм мин, – ди.

Атна чамасы узгач, Әмирхан абый бүлмәсендә сыйланып, сөйләшеп утырабыз.

– Укып чыктым мин син китергән китапны. Би-ик күп мәгълүматлар алдым үзем өчен. Чыннан да мәдрәсәгез бик зур булган икән...

Китапны ике куллап тоткан, әмма миңа бирергә ашыкмый. Үзе китап турында сөйли, китапны кулларында йөреткәли. Шулай итеп байтак сөйләшкәч, мин көлемсерәп әйтәм:

– Әмирхан абый, Сез китапны миңа бирмәскә уйлыйсыз бугай. Бу китап бит минем иң зур байлыгым.

– Шулайдыр, Зәки. Байлыгыңдыр. Тик яхшы китап кулга килеп керсә, аны ычкындырасы килми бит әле...

Үзе, вак кына көмеш акчалар сипкән кебек, кет-кет көлә. Мин дә аңарга кушылып көләм, тынычландырам:

– Бу китап фотога төшерелгән инде. Бер нөсхәсен алып килеп бирермен Сезгә.

– Ярар алайса. Син анысын алып килгәнче, мин монысын тагын бер кат карап чыгыйм әле. Бу бит Шакир Тукаевның кулы аша узган китап. Бәлки, Дәрдмәнд кулы да тигәндер әле. Алар бит дус булганнар...

Әмирхан абыйдан чыккач, Динис азрак уфтану белән әйтеп ташлый:

– Был карт миллионер бит инде, ә, Зәки агай?!

– И-и! – дип сузам мин. – Аның кебек язсаң, аның яшенә җитсәң, син дә булырсың әле миллионер. Кайгырма, сабыр ит, Динис.

Башын арткарак салып чын күңеленнән көлде шунда Динис:

– Й-у-у-ук инде-е! Мин бит язып тапкандың барыһын ла тотоп, юк итеп, бөтереп барам. Ысын башкорт запас ясай белмәй бит ул. Ә мин ысын башкортмын!

Пугач патшаның уң кулы булган, иң соңгы сәгатьләренә кадәр аның янында калып сугышкан Кинҗә Арсланов авылыннан иде Динис Бүләков дигән чын башкорт егете. Һәм үзенең сөйләве буенча Кинҗә нәселеннән дә иде. Тик гомере генә озын булмады ул асыл егетнең. Берничә ел элегрәк вафат булды. Үлгән чагында Башкортстан Язучылар берлегенең рәисе иде...

Ялы тәмамланырга берничә генә көн калгач, Әмирхан абый миңа әйтә:

– Ике көннән без китәбез инде кайтып. Син азрак вакыт тапсаң, безне озата алмассыңмы икән диюем. Билетлар алынган. Тик менә Мөршидә апаң азрак әйберләр, күчтәнәчләр алган иде...

Хатыны Мөршидә апа кечкенә гәүдәле, үтә дә мөлаем татар әбисе. Сорыйм:

– Машина белән килимме, Әмирхан абый?

– Юк, кирәкми. Рәхмәт. Мин таксига заказ бирдем инде. Ул яктан тыныч бул.

Китәсе көнне таксига төялешеп, өчәүләшеп Ригага юл алабыз. Әйберләрен күтәреп, аларга ияреп поездга керәм. Кирәк купены табып Әмирхан абый хатыны белән эчкә үтә. Мин коридорда басып торам. Купе эче кеше белән тулы, керерлек урын юк. Озатучылар, ахрысы, дип уйлап куям. Аскы урында утырган бер әрмән Әмирхан абыйга эндәшә:

– Ты что, Амирхан! Разве не уехал?

Әмирхан абый кабаланмый гына урыннарны карап чыга да, әрмәнгә җаваплый:

– Китмәдем әле. Менә бит китеп барам. Аскы ике урын безнеке. Тор минем урыннан, әрмән!

Тегесе өстәлгә салып куйган билетын алып карый:

– Мин үз урынымда утырам. Синеке түгел бу урын. Кая, билетыңны күрсәт әле.

Мин тиз генә әйберләрне идәнгә куям да, Әмирхан абый кулыннан үрелеп билетларын алам. Билетта күрсәтелгән урыны шул – анысы дөрес. Тик билет кичәге көнгә бирелгән икән. Шул турыда татарчалап Әмирхан абыйга әйтәм. Йөзендә ник бер каушау билгесе чагылсын!

– Булмас ла! Кая, үзем карыйм әле.

Ала да, җайлап кына билетны карый. Азрак уйлангандай иттереп басып тора да, тавышын күтәрмичә, җайлап кына әйтә:

– Кассадагы хатын бик зәһәр иде. Шул бутаган инде моны...

Кабаланмый гына урыныннан кузгала:

– Әйдә, перронга чыгыйк әле. Шунда уйлашырбыз...

Мин чемоданнар күтәреп алдан атлыйм. Мөршидә апа ник шунда берәр төрле ризасызлык белдерсен. Салмак кына атлаган Әмирхан абыйга ул да кабаланмыйча гына ияреп перронга чыкты.

Көн матур, җылы. Поезд кузгалып китәргә ярты сәгать чамасы вакыт бар әле.

– Ярар! – ди Әмирхан абый перронга чыгып баскач. – Син, Зәки, нәрсә уйлыйсың бу хакта?

– Бу күңелсезлектән чыгу юлы өчәү, Әмирхан абый.

– Өчәүме? Байтак икән инде өчәү булгач. Әйт син аларны. Тыңлыйк.

– Беренчесе болай. Хәзер миңа кайтабыз. Кунак буласыз, кунасыз. Иртәгә шушы вакытта китәсез. Билетлар артыннан мин йөрермен. Шушы ук билетлар белән китәрсез, дип уйлыйм...

Минем бик тә кунакка аласым килә Әмирхан абый белән Мөршидә апаны.

– Ярар, хуш! Икенчесе ничегрәк икән инде?

– Бер сәгатьтән икенче поезд китә. "Латвия" дигәне. Шуның белән китә аласыз. Билетлар табарбыз.

– Өченчесе?

– Шушы поезд белән китәсез. Кузгалып киткәч, поезд бригадирыннан билет аласыз...

Шунда күрдем мин Әмирхан абыйдагы чын ирләрчә һәм морзаларча холыкны. Ул азрак уйланып торды да әйтте:

– Юлчының юлда булганы яхшы. Насыйп итсә, киләсе килүдә булырбыз кунак. Син бар алайса, тап бригадирны. Сөйләш. Без шунда көтик.

Вагоннар буйлап эзләп китәм. Бригадир әзәрбәйҗан кешесе булып чыкты. Минем аны элегрәк тә күргәләгәнем бар иде. Аңлатам хәлне, берочтан Әмирхан абыйның татарның атаклы язучысы икәнлеген дә әйтәм. Әзәрбәйҗан мин килгәнче сөйләшеп торган латыш кондукторга: "Пагайт, лудзу!" – дия дә, минем белән китә. Килеп җитүгә Әмирхан абый белән җылы итеп исәнләшә дә сүз ката:

– Шушы ук вагонга керегез! Кузгалгач та мин сезгә ике урын табармын. Бар буш урыннар. Шушы ук вагонда да булырлар әле...

Киттеләр кайтып Әмирхан абый белән Мөршидә апа. Мин Рига тимер юл вокзалының перронында басып калдым. Аларны кунак итә алмадым...

Мөршидә апаны башка күрергә насыйп булмады миңа...

Казанда

1984 елның август ае. Мин Казанга килеп чыктым. Бауман урамы буйлап нәшриятка бара идем, тротуардан килгән Әмирхан абыйга очрадым.

– И-и, Зәки-и, син бит бу! Исәнлек-саулыкмы? Ни эшләр бетереп йөрисең Казанда?

Минем эшләр шәптән түгел. Май аенда гына докторлык диссертациясен яклый алмадым. Бер тавыш җитмәде. Кәеф юк. Мәскәүдәге Дзержинский исемендәге ракета академиясендә киләсе елга яңадан яклау өчен документлар әзерләү бара. Әллә яклап була, әллә юк. Беркем дә белми аны. Әмирхан абыйга боларның берсенең дә кирәге юк. Шунлыктан ул турыда сөйләп тә тормыйм. Тик...

– Синең кәефләр нигәдер чамалы күренә. Әллә берәр төрле уңышсызлыклар бармы?

Менә сиңа! Җайлап кына караса да, күпне күрә торган морза булды бит әле бу абзый кеше! Ипләп кенә минем беләктән тота:

– Минем кайтып барыш. Әйдә, миңа барыйк әле. Анда мин коймак пешерергә кушып киткән идем. Мөршидә апаң гүр иясе булды бит – ишеткәнсеңдер инде.

– Әйе.

– Әйдә, утырыйк азрак сөйләшеп миндә.

Яшь кенә бер кыз безне коймаклар белән сыйлый. Әмирхан абыйга туган тиешле студентка икән. Ул чакта Әмирхан абый Шмидт урамында яши иде. Коймак ашыйбыз, чәй эчәбез. Гәпләшәбез. Тыныч, рәхәт, җан ял итә. Әдип кабаланмый гына сөйли:

– Сугыштан исән-сау кайта алгач, мин инде бөтенләй язмаска дип уйлап, карар кылып куйган идем. Хөкүмәткә кем генә килсә дә, бик җәберлиләр бит язучы халкын. Ул, теге утыз җиденче елны әйткән дә юк инде. Мин моннан чыгып китеп кенә тере кала алдым. Исәп берәр һөнәр алырга да, бик күренмичә, тыныч кына яшәргә иде. Мәсәлән, бухгалтер һөнәре. Тик булмый икән шул язмыйча. Сизми дә каласың яза башлаганыңны...

Мин форсаттан файдаланып сорап куям:

– Муса Җәлил ниндирәк кеше иде, Әмирхан абый? Сез бит аның белән күрешеп, аралашып яшәгәнсез.

Әдип өстәл өстендә кул бармаклары белән нәрсәдер әвәләгәндәй иттереп хәрәкәт ясап азрак утыра. Уйлана. Аннан соң җай гына сүзгә керешә:

– Кызларны бик ярата торган иде. Гәүдәгә алай зур түгел һәм тышкы кыяфәтенә карап герой дә булыр, дип әйтеп булмый кебек иде. Аның батырлыгы искитмәле. Менә бит, татарны бөтен Җир шарына танытты...

Шунда телефон шалтырый. Әмирхан абый шалтыратучы белән "Афзал абый" дип сөйләшә. Сөйләшеп бетергәч миңа аңлата:

– Язучы Афзал Шамов шалтырата. Үзе бик чыгып йөрерлек түгел инде. Кайбер йомышларын үтәштерәм аның...

1989 елның җәендә мин Казанга күченеп кайтам. Еш кына җыелышларда, театр-концертларда очрашабыз. Бу зур йомры гәүдәле абзый мине һәрвакыт үзенә тартып тора. Аның белән аз гына вакыт аралашып сөйләшсәм дә, минем энергиям арткан кебек була. Соңыннан мин һәр сөйләшкән сүзне искә алам, аңарга һәрчак яхшы мәгънә биреп анализлап хәтергә сала барам. Сизеп торам, минем милли хәрәкәттә кискен йөрүемне Әмирхан абый табигате белән тулысынча кабул итеп бетерә алмый. Шунлыктандыр инде, җайлап кына миңа тәрбияви киңәшләр бирә:

– Син күбрәк яз, Зәки! Яз! Урамда, митинг-пикетларда акырып йөрү, ачлыкта утыру, сәясәт белән шөгыльләнү язучы эше түгел ул! Каләмең бар – яз. Язасы әйберләрең, сөйләвеңә караганда, күп бит синең. Җиткер шуларны укучыга! Яз!

Еллар узды. Миңа вәгазь укыган Әмирхан абый... үзе дә сәяси мәкаләләр язарга тотынды. Хикәя-повестьларына зыян китереп. Мин сорамасам да, миңа шул сәяси мәкаләләрне яза башлавының сәбәбен аңлата:

– Йөрәк түзми икән, Зәки, тирә-яктагыны күреп, йөрәк...

Иделдә

1993 елның 10 августында бер төркем язучылар, галимнәр, "Мулланур Вахитов" теплоходы белән Казан-Әстерхан маршруты буйлап сәяхәткә чыгабыз. Теплоход шыгрым тулы татар зыялылары. Урыслар бөтенләй юк. Әйтерсең лә без, инде тулы мөстәкыйльлек алып, алардан бөтенләй котылганбыз.

Кузгалып киткәннең икенче көнендә классик язучыбыз Әмирхан Еники теплоход палубасында укучылар, ягъни безнең белән очрашу үткәрде. Ул чакта Әмирхан абый сәяси мәкаләләр язмый иде әле. Бик күп сорауларга җавап биргәннән соң Әмирхан абый үзенең ризасызлыгын белдерде.

– Менә безнең Татарстанда да бер төркем, лидер дип әйтикме инде аларны, милләтчеләр диикме, урамнарда, митингларда, пикетларда бертуктаусыз кычкырып йөрүчеләр бар. Кычкыралар инде, халыкны котырталар, милләтләр арасында низаг чыгарырга омтылалар. Аларның бит Карабахтагы, Спитактагы кебек, милләт белән милләтне капма-каршы бәрелештереп, кан коюга алып барып җиткерүләре мөмкин. Безнең Президентыбыз Шәймиев төпле акыл белән эш итә. Ә болар риза түгелләр аның алып барган тыныч, төпле сәясәте белән...

Миңа тыныч кына утыруы бик тә авыр. Чөнки 1991 елның маенда Казанның Ирек мәйданында ачлыкта утырганда ясаган чыгышлар өчен мине, татар экстремисты, милләтчесе, дип урыс һәм... татар гәзитләре бик каты тәнкыйть иттеләр. Әмирхан абыйдан да байтак кына "эләкте" миңа. Әмирхан абыйның сөйләгәне миңа ошап бетми, шунлыктан, очрашуда катнашучыларның берсе буларак, сорау бирүне кирәк табам:

– Әмирхан абый, мин дә мәйданнарда йөрүчеләрнең берсе бит. Сез миңа карата ниндирәк бәя бирер идегез?

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН.

(Ахыры бар).

Февральдә журналлар ни яза

"Казан утлары"
Ф.Яруллин. Якты ай янында. Шигырьләр.
М.Гали. Догалы еллар. Эссе.
Р.Гаташ. Бармы көчем – яшь моңны юатырлык... Шигырьләр.
Н.Хәсәнов. Иңрәү. Повесть.
Әй гомер агышлары
Дуслык илчесе, туганлык җырчысы.
Н.Нәҗми. Сиксән тулганда. Шигырьләр.
Гаяз Исхакый. Ике хикәя.
Ф.Ибраһимова. Әдипнең тормыш мизгелләре.
Публицистика
Ә.Галиев. Бер һәйкәлнең тарихы.
Әдәби мирас
М.Гайнетдин. Мулла шагыйрь.
М.Иманколый. Газәлләр.
Әдәби тәнкыйть
Х.Әшрәфҗанов. Тамырыбыз тарихта.
М.Шабаев. Түземнәр генә бәхеткә лаек.
Сәнгать
К.Тимбикова. Чәчәк аткан гөл.
К.Миңлебаев. Гүзәл мирас калдырган әдип.
И.Юзеев. Шигырьдә – рәссам, рәсемдә – шагыйрь.
Ш.Маннап. Иман нуры. Латин имлясында уку үрнәкләре.

"Сөембикә"
"Берәүгә базар, берәүгә мазар" рубрикасында **М.Авзалованың** "Бирә дөнья кирәкне" дигән язмасы.
Ш.Мостафин. Миһербанлы Мөгъфүрә.
Яшәр өчен гомер бар әле. **Нәҗар Нәҗминең** шигырьләр шәлкеме.
"Туфан мине бәйләде". Нәҗибә Ихсановага 60 яшь тулу уңаеннан **А.Юнысова** мәкаләсе.
Ак төн ае сөйләр әле! Рәссам Р.Гыйләҗевның иҗаты турында **Галина Кекушева** мәкаләсе.
Г.Исхакыйның тууына 120 ел тулу уңаеннан **"Исхакыйлар Сөембикәсе"** дигән әңгәмә.
"Меңъяшәр имән кеби". Галимә **Л.Гайнанова** белән **Г.Исхакый** хакында әңгәмә.
"Әнигә дә, бәбигә дә", "Яшь әниләр мәктәбе", "Минем кайнанай мировой" дигән һәм башка рубрикалар, "Айсылу" кушымтасы дәвам итә.

"Татарстан"
Заман һәм шәхес
Р.Ганиева. Татарның сөекле улы.
Г.Исхакый. Шагыйрь Габдулла Тукай.
Әдәбият тарихыннан
Ә.Шәрипова. Сирин фаҗигасе.
Сәясәт
Р.Хәким. Русия һәм Татарстан тарих юллары чатында.
Фикер
Г.Һидиятуллина. Иҗтиһат һәм Г.Курсави җәнаплары.
Галәм
Галактикалар сере.
К.Шакир. Резонанслар.
Табигать һәм без
Г.Гомәр. Безне нинди язмыш көтә?
Икътисад
Н.Гатиятуллин, И.Гәрәев. Бер куанычның мең борчуы.
Дөнья серле, дөнья киң
Г.Йосыпова. Нинди ил ул Кытай?
Сәнгать
И.Һилалова. Аңа зыялы ханым булу килешә.
Әдәби хәят
М.Юныс. Конгресс.
Маҗара һәм фантастика
Ж.Сименон. Мегрэ ханым танышы.
Шигърият
Р.Миңнуллин. Шигырьләр.
Укучы мөнбәре
Г.Әхмәт. Татар дигән исемне бетерә алмаслар.

"Идел"
Шигърият
Марат Закир.
Нәсер
Заһид Мәхмүди. Калканлы Идел. Тарихи-хыялый кыйсса.
Ша-ярыш
Туфан Миңнуллин. Минһаҗ маҗаралары.
Тур башы
Миргазиян Юныс. Эш аты.
Галәмәт
Нәбирә Гыйматдинова. Сыер һәм хуҗа.
Киңәш базары. Бер кат кис. Һәйбәт гайбәт һ.б.

"Салават күпере"
Журналның бу саны фольклорга багышланган китапчык булып чыга. Рәссам Фәрит Муллахмәт бизәгән.

Дин вә гавам

Киңәшле эш таркалмас

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Татарстан мөселманнарын берләштерү корылтае турында сүз башлаганда бер гәзит журналисты әйткәнчә, бик күпләрнең күңелендә туган уртак фикерне искә алмасак, хакыйкатькә хилафлык итү булыр иде. Җитмеш елдан артык дингә каршы көрәш барганнан соң, Татарстан мөселманнары тарихында беренче тапкыр югары мөнбәрдән Илбаш Минтимер Шәймиевнең тирән эчтәлекле, тәэсирле, киләчәк эшкә юнәлеш биргән чыгышы мәртәбәле җыенның бернинди тавыш-гаугасыз, тыныч, эшлекле узуына этәргеч бирде. Икенчедән, корылтайның үз максатына ирешүендә һәр мәсьәләне делегатлар белән киңәшеп, конкрет хәл итеп, кирәк чакта кырыс та булып яки мәзәк тә кыстырып, зирәк, гадел, җор тел белән чын татарча алып баручы Балтач районы мөхтәсибе Җәмил хәзрәт Фазлыевның да ярдәме тигәндер. Моңа хәтта Президент үзе дә сокланып, тәнәфестә аның кулын кыскан, ди. Җиде ел дәвамында дини идарәчеләрнең үзара тыныша алмавы нәтиҗәсендә татар-мөселман халкына, җөмһүриятебез йөзенә ямьсез тап төшерә башлаганга түзә алмыйча, берләштерү корылтае уздыруны үз өстенә алган хөкүмәт җитәкчеләрен битәрләп, бу турыда матбугат вәкилләренә хәбәр тарату "тагын тынычлана алмаслар, ахры", дигән шом салды. Менә шул хәл корылтайда ике мөфтиятнең дә вәкилләре кергән оештыру комитеты өч уставка нигезләп эшләгән яңа низамнамә проекты белән бергә тагын бер уставны тикшерергә тәкъдим итәргә маташуда да бик ачык күренде. Әмма ике низамнамәнең аермасы берничә маддәдә генә чагыла. Аны корылтай бик җиңел хәл итте.

Бер уставта, мөфти итеп югары дини белеме булган кеше сайланырга тиеш, дип әйтелә. Кандидатлар арасында, гомумән, Татарстанда андый кеше берәү генә, ул да булса – Габдулла хәзрәт. Шушы маддәне кабул иткән очракта, калган биш кеше дә мөфтилеккә кандидатлыктан төшеп калачак иде. Димәк, бердәнбер кандидат кына сайлауда катнашачак. Президентлыкка бер генә кандидат күрсәтелгәч, бишенче сыйныфта укучы бер баланың "Нинди сайлау булсын инде ул", – дигәне хәтердә калган. Тәлгат хәзрәт Таҗетдин да үз вакытында бер генә кандидат калдырып, үзен мәңгелек мөфти итеп сайлаткан иде. Ул чакта моның белән Габдулла хәзрәт үзе дә килешмәде кебек. Чөнки нәкъ сәвитчә сайлау бит. Ә хәзер заманалар башка. Шуңа күрә корылтай мөфти булып урта яки махсус дини белемле кешенең сайлана алуын хуплады. Уставлардагы икенче үзгәлек: берсендә мөфтине һәм хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүче башкарма комитет рәисен корылтай аерым-аерым сайлый, диелгән. Икенчесендә, әлеге башкарма оешма, ягъни вакыф идарәсе булмый, ул вазифаны мөфти урынбасары да үти ала, кыскасы, урынбасарны мөфти үзе күрсәтә, корылтай раслый, дип әйтелә. Габдулла хәзрәтнең шушы соңгы тәкъдимен корылтай гамәлгә кертте. Мәсьәлә бик тыныч хәл ителде. Ә менә дәүләтнең дини оешмаларга ярдәмен дин эшләренә тыкшыну дигән сылтау белән кире кагу делегатлар күңеленә һич тә хуш килмәде. Бу мәсьәләне Президент үзенең чыгышында бик ачык итеп аңлатты. Конституциядә, дин дәүләттән аерылган, дип язылса да, җәмгыятьтә ул аерым яши алмый. Дингә каршы көрәшне кире каккан, мәчетләр, мәдрәсәләр төзергә, дин тотарга мөмкинлек биргән дәүләтне хәзер халык үзе сайлап куйган Президент җитәкли. Димәк, ул корылтай куйган мәсьәләләргә, җәмгыятьтә диннең торышына битараф була алмый. Без әле һаман сәвитчә фикерләүдән арына алмыйбыз кебек. Диннең дәүләттән аерылган булуы да Сталин Конституциясеннән күчкән маддә генә түгелме? Динчеләргә зыян китермәсә, аны инде күптән сызып ташларга мөмкиндер.

Ютазы районы мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрдәншин болай диде:

– Биредәге кебек, без районда хакимият башлыгы белән бәхәскә керә алмыйбыз. Чөнки аз-маз кергән сәдака акчасына гына берни дә эшләп булмый. Мәчет, мәдрәсә биналарын төзергә, торгызырга хакимият, колхоз-совхозлар, предприятиеләр, башка оешмалар булыша. Мөфтиятнең андый ярдәмне күрсәткәне юк. Хәтта аның вәкилләре мәчет ачарга да килми. Күршебез Башкортстанда хәл бөтенләй башкача: мәчет, мәдрәсә ачуда мөфти үзе катнаша. Дини бәйрәмнәр уңаеннан хәтта безгә дә котлаулар, вәгазьләр үрнәген җибәрәләр. Ә безнең мөфтият искә дә алмый. Ни өчен шулай?

Туры әйткән туганына ярамаган, дисәләр дә, Әҗем мәчете имам-хатибы Габдрәүф хәзрәт Зиннәтуллин бик ачынып сөйләде: власть, мал бүлешәләр, акча туздырып, чит илләргә күп йөриләр. Шуңа авылга ярдәм аз. Шәкертләр укытабыз, дип мактаналар. Ә авылларда имамнар җитми. Булганнарының да белеме сай. Аларны укыту-өйрәтү мөфтият исәбенә оештырылмый. Шәкертләрне кышкы-җәйге каникул вакытында авылларга ярдәмгә җибәрергә мөмкин. Яңа әлифбага күчкән чакта һәр йортка кереп, хәреф өйрәтеп йөрделәр бит әле. Динне дә шулай халыкка җиткерергә бик мөмкин.

Дин эшләрен татарча алып бару, саф татарча, тәэсирле итеп вәгазь сөйләү мәсьәләсенә дә корылтайда зур игътибар бирелде. "Гади имамнан алып мөфтигә кадәр саф татарча белүчеләр аз", – диде Зәй районы мөхтәсибе Әнәс хәзрәт Салихов. Бу фикерне аның якташы язучы Рабит Батулла да куәтләде. Мәчеттә тәэсирле, үтемле, чын татарча вәгазь укылмаса, кеше аннан читләшә, диде ул. Чит илләргә укырга киткән балаларның телебезне, мәдәниятебезне, тарихыбызны өйрәнүенә игътибар бирелми. Бу мәсьәлә остаз-тәрбияче, мөгаллим ияртеп җибәргәндә уңай хәл ителәчәк. Без, дин телебезне саклап калды, дибез. Ә хәзер мәдрәсәләрдә байтак фәннәр урысча укытыла. Янәсе, татарча белмиләр. Икетеллелек тормышка ашырылганда хәтта җитәкче урыннарда эшләүче урыслар, башка милләт кешеләре дә татарча өйрәнәләр. Ә татарлар... урысча вәгазь сөйләрме? Шушы ук корылтай урысча чыгышларны кире какты. Габдулла хәзрәтнең кереш сүзен, оештыру комитетының, санау комиссиясенең кайбер документларын урысча укырга ниятләүләрен зал кабул итмәде. Рәсми документлар өш кына урысча языла. Урыс теле генә рәсми саналган чирдән һаман котыла алмыйбыз.

Түбән Кама шәһәре һәм районы мөхтәсибе Мәүлемҗан хәзрәт Сибгатуллин расланган укыту программасы белән тәэмин итмәгәне өчен мөфтияткә дәгъва белдерде. Дәреслекләр дә юк. Менә шул хәл төрле юрауларга, бәхәсләргә юл ача. Мәсәлән, Гарәбстаннан укып кайткан имамнар яки аннан килгән мөгаллимнәр ата-бабаларыбыздан мирас булып калган, мең еллар гамәлдә йөргән гореф-гадәтләрне, йолаларны бидгать дип кире кагалар. Менә шулар динчеләрне төркемнәргә аеруга китерә, үзара татулыкны боза, диде Югары координацион үзәк җитәкчесе Нәфигулла хәзрәт Әширов. "Ислам илләрендә булганда дин кардәшләребезнең элек Казанда басылган китаплардан гыйлем алуларын күреп сөенәбез. Хәзер бармы соң андый галимнәребез?" – диде Равил хәзрәт Гайнетдин.

Диндар бер мөслимә дин галимнәренең бер-ике китабын гарәп язуыннан урыс хәрефләренә күчергәне өчен, берәүне "безнең бүгенге Мәрҗаниебез" дип мактаган иде. Кайда соң андый галимнәрнең бүген кулланырлык хезмәтләре? Бу да корылтайда әйтелгән фикер.

Корылтайда Рамазан гаете бәйрәмен рәсми ял көне итеп билгеләү (Башкортстанда бу берничә ел элек хәл ителде), Русия кануны нигезендә яшь имамнарны тыныч вакытта хәрби хезмәткә алмау, мәчет-мәдрәсәләрне коммуналь хезмәтләр өчен түләүдән, җир салымыннан азат итү, Казанда Ислам университеты ачу һәм аны бина белән тәэмин итү, Татарстан Фәннәр академиясендә Ислам тәгълиматы, дини мирасыбызны тикшерү-өйрәнү үзәге булдыру турында мөрәҗәгатьләр кабул ителде. Әлегә яңа мөфтият Мәрҗани мәчетендә урнашты (К.Насыйри урамы, 17 нче йорт), ә Ислам университеты элекке Гали мәчете бинасында (Тукай урамы, 40 нчы йорт) эшли башлаячак. Президентыбыз мөфтият бинасын салуда ярдәм итәргә ышандырды. Бу корылтай дәүләтнең дин эшләренә йөз белән борылуын күрсәтте, болар, әлбәттә, рухи һәм рухани тормышыбызга уңай йогынты ясар.

– Киләчәктә дин эшләребез тагын да уңышлы, милләтебезгә иман һәм дин тойгыларын үтемле, бәрәкәтле итеп җиткерү өчен нигез бүген салына, – диде Тәлгат хәзрәт Таҗетдин.

Татарстан җөмһүриятенең үзәкләштерелгән иң югары дини оешмасы рәисе, мөфти Госман хәзрәт Исхакый һәм баш казый Габделхак хәзрәт Саматов, Президент чыгышында бәян ителгән, корылтай билгеләгән юнәлештә эшләп, Ислам диненә, татар-мөселман халкына турылыклы хезмәт итәргә, дин эшләрен гадел алып барырга чын күңелдән ышандырдылар. Бу сүзләрне әйткәндә һәр икесенең күзеннән яшь тәгәрәп төште. Аллаһы тәгалә аларның изге эшләренә хәер-фатиха бирсен. Амин.

Шәех ЗӘБИРОВ.

Утлы куздай бу "Гомер мизгелләре"нә мин кайчандыр үзем укыган Зур Сәрдек урта мәктәбенең (Кукмара районы) туган якны өйрәнү музеенда юлыктым. Аны миңа мәктәп директоры Закирҗан абый Сабитов бирде. Истәлекнең авторы Гаян ага Әхмәтшин гомере буе шушы мәктәптә хезмәт дәресен укытты, күпме егет-җиләнне балта-пычкы тотарга, дөнья күтәргә өйрәтте. Әгәр Зур Сәрдек төбәге тирә-якта үзенең балта осталары, һөнәрчеләре белән дан тота икән, монда алтын куллы остаз Гаян аганың да гаять саллы өлеше бар, билгеле.

Моннан берничә ел элгәре "Казан утлары" журналында нимес һәм совет концлагерьлары мәхшәрен үз башыннан кичергән Гарәф Фәхретдиновның үтә дә гыйбрәтле бер истәлеге дөнья күрде. Һәм ул совет мәхбүсләренең әсирлектәге тормыш-көнкүреше, көрәше турында без укып үскән әдәбиятка бер дә охшамаган иде. Гаян ага да тоткынлыкта Г.Фәхретдиновлар белән бергә булган. Гәрчә, лагерь баландасын бер үк табактан чөмерсәләр дә, бу ике каләмдәшмогикан һич тә кабатланмый, киресенчә, бер-берсен тулыландыра, баета гына төшә.

Мондый хатирәләр кан белән генә языла ала торгандыр. Болар – XX гасырның сират күперләрен исән-аман кичеп, безнең хәтерләрне тутыгудан сакларга тәгаенләнгән ил агаларының гомер китабы. Тиздән Гаян ага Әхмәтшинга 75 яшь тула. Гомер бәйрәмегез мөбарәк булсын, ил агасы! Ходай Сезгә киләчәктә дә бәрәкәтле гомер насыйп әйләсен. Амин.

Газинур МОРАТ.

Гаян Әхмәтшин.
Радик ӘМИНОВ фотосы.

Гаян ӘХМӘТШИН

Гомеремнең исемдә калган мизгелләре*

...1942 елның февраль аенда районыбызның хәрби комиссариаты безне – 15 кешене – хәрби училищега билгеләде. Тәкәнеш һәм Мамадыш районыннан китүчеләрне дә Кукмарага җыйнадылар. Барыбызны вагоннарга урнаштырдылар һәм Кострома шәһәренә китерделәр. Без килеп җитүгә, курсантлар да строй белән җир селкетеп кайтып туктадылар. Якташлар юк микән, дип безнең янга качып кына ике татар егете килде. Алардан хәл-әхвәлләр сораштык, укуларның ничек икәнен белештек. Алар безгә: "Зинһар, егетләр, керә күрмәгез, бик авыр, тәртип тә бик каты, ашаулар да дан түгел", – диде. "Ә ничек кермичә калып була?" – дидек. Керү өчен өч фәннән имтихан бирәсе икән: математика, география, урыс теленнән диктант. Без үзебезнең группа белән кермәскә уйладык, сынауны тиешенчә бирмәскә булдык. Безнең группадан бер полковник малае кереп калды. Безне – уза алмаганнарны – кире военкоматыбызга кайтардылар. Военкомат: "Кайтып торыгыз", – дип өйгә җибәрде. Ярый имтихан бирә алмаганбыз әле, дип шатланышып өйгә кайтсак та, безне ике көннән соң тагын чакырып, Әстерханга пехота училищесына җибәрделәр. Моннан да кире кайтып булмас микән, дип имтиханны бирә алмаганга салындык. Бу юлы хәйлә барып чыкмады, безне Сталинград өлкәсенең Котельников районына учебный полкка җибәрделәр. Шунда сугышка хәзерләнә башладык. Кием бирерләр әле, дип, өйдән начар кием-салым, аякка чабата, иске итек ише нәрсәләр генә кигәлеп килгән идек, ул аяк киемнәре тузып бетте, яланаяк калдык. Яланаяклыларны, сафка тезгәндә, уртага бастыралар иде. Шулай итеп булса да дәрескә алып йөрделәр. Аяклар ташка, пыялага киселеп яраланып бетте. Ә кичләрен йокы алдыннан җырларга алып чыктылар, җырлар гел Сталин бабабыз турында иде.

Ашау бик начар булды. Такта нар өстендә үзебезнең иске бишмәтләребезне җәеп, өскә дә юк-бар нәрсә генә ябынып яттык. Ашханә район үзәгендә иде, май бәйрәмендә яланаяклыларны ашханәгә алып бармадылар, бәйрәм көнне, янәсе, ярамый, диделәр. Яланаяклыларга ашарга ике солдатка алып кайтырга куштылар. Төшке ашны алып кайтканда алар сөртенеп егылып чиләктәге ашны түккәннәр, куесын куллары белән тутырып, безгә 1 май бәйрәменең ашын алып кайттылар. Шулай итеп, бәйрәм ашы 3-4 кашык чамасы гына эләгеп калды, ул да балчыклы иде.

Менә нинди солдатлар идек без, ач булсак та, ялангач булсак та, ил өчен, Сталин өчен, дигән дәртле җырларны барлык көчебезгә кычкырып җырлый-җырлый сугышка хәзерләндек. Бер учебный винтовкабыз бар иде, шуны сүтәбез дә җыябыз, аның төзелешен өйрәнәбез. Очлы таяк белән салам тутырылган капчыкка кадыйбыз.

Ниһаять, киемнәр кайтты, киендерделәр, аякка Англиядән килгән ботинкалар бирделәр. Бик каты, тар ботинкалар иде, аякларны суеп бетерде. Кулга ППШ дигән автоматлар тоттырдылар, ротабызга автоматчылар дигән исем бирелде. Шулай итеп, чын сугышчыга әйләндек. Берничә тапкыр автоматтан атып карадык та, шуның белән фронтка җибәрделәр. Воронеж өлкәсенең Кантимер шәһәренә юл тоттык. Кантимердә каты сугышлардан соң немецләр фронт линиясен өзеп, алга – Сталинградка ыргылган. Безгә барып җитү насыйп булмады. Безнең частьләр дә тар-мар ителеп, шушы районда чолганышта калдык. Чолганышта айдан артык булырга туры килде. Сугыш кирәк-яраклары – патроннар, гранаталар бетте. Чолганыштан чыгарга никадәр тырышып сугышып йөрсәк тә, аннан чыга алмадык. Коралларыбызны дошманга бирмәс өчен яшердек, күмдек. Шулай итеп, безне әсирлеккә алдылар. Үзебезнең як белән элемтә булмады, командирлар да юкка чыкты, көтүчесез сарыкларга әйләндек.

Шушы көннән "атабыз" Сталин бездән ваз кичте һәм "илне сатучы" ярлыгын муеныбызга элде.

ӘСИРЛЕКТӘ

1942 елның август айлары иде. Чолганышта калган солдатларны немецләр йөзәрләп, меңәрләп кенә җыеп, бер урынга туплый башладылар. Абзарларга, утарларга җыеп, сак астында тоттылар.

Якынча мең кеше чамасы җыелгач, безне Миллерово дигән шәһәр янындагы лагерьга җәяүләп алып киттеләр. Юлда хәлсезләнгән әсирләрне атып кына калдыралар иде.

Ачлыктан, сусаудан интегеп, исән калганнар Миллерово лагерена килеп җиттек. Шәһәр читендәге бик зур иңкүлеккә 12 мең әсир җыелган. Бу санны шушы лагерьда полицай хезмәтен үтәүчеләр әйтәләр иде. Тауның өске ягы чәнечкеле чыбык белән әйләндереп алынган, аның әйләнәсендә пулемет нокталары урнашкан. Әгәр үргә таба югарырак менәргә маташсаң, пулемет утына эләгәсең.

Шушы лагерьда мин үзебезнең район кешеләре белән очраштым. Берсе – Сабиров Сөләйман – Мәмәшир авылыннан, 1906 елгы иде. Ядегәр авылыннан Сабит исемле кеше, Вахит авылыннан Шәйхи исемле кешеләр иде, болар икесе дә колхоз рәисе булып эшләгән. Сөләйман һәм Сабит абыйлар белән, илгә кайткач, исән вакытларында күрешергә дә насыйп булды.

Миллерово лагерен "Үлем чокыры" дип атап йөртәләр иде. Чөнки бу лагерь ачык һавада булгач, көндезләрен кояш җылытса да, төнлә бик салкын, җитмәсә, минем шинелем дә юк иде. Сөләйман һәм Сабит абыйның шинельләре белән дүртебез ябынып яттык. Шәйхи абый үзенең шинелен картага оттырды. Шулай итеп, ул да ялангач иде. Бу "Үлем чокыры"нда ашарга тәүлеккә бер тапкыр гына бирделәр – 300 грамм янган бодай суы. Янгыннан калган колхоз складларыннан җыйган ашлыкның артык каты янмаганнарын лагерь халкына ашарга пешерү өчен кулландылар.

Бу лагерьда ике айдан артык булырга туры килде, хәлсезләнүчеләр, үлүчеләр күп булды. Мин тәмәке төпчеген тапсам, җыеп бардым һәм икмәк кисәгенә яки ашка алыштырып алырга тырыштым.

Хәллерәк кешеләрне лагерьның тышкы ягына яки шәһәр тирәсендәге складларга, юллар төзәтергә эшкә алып чыгалар иде. Алар үзләре белән ашар-дай нәрсә дә эләктереп кайта алдылар. Шушы кешеләрдән мин тәмәкене ике консерв банкасына алыштырдым. Банкалардан ашлык ваклый торган тегермән эшләдем. Шуның белән булган кешеләрнең ашлыгын ярма итеп ваклый идек. Биш кружка ашлык вакласаң, бер кружкасын хезмәт хакына – тегермән өчен бирәләр. (Кружканың зурлыгы 300 грамм чамасы). Шушы хезмәт хакы ярмасыннан ботка сыман апара пешереп, дүрт кеше йөрәк ялгый идек. Лагерь эчендә бернинди үлән, хәтта аның тамырлары да калмады. Үлән тамырын кашык яки берәр очлы әйбер белән казып чыгара һәм аны киптереп, ягулык итеп куллана идек.

Эшкә чыкканнарның лагерь эчендә каршы алырдай кешеләре булмаса, аларны таладылар, ач бүреләрдәй һөҗүм иттеләр. Аларны таптап үтерү хәленә китергән очраклар да булгалады. Меңләгән ач кеше төркеменә капчыкка әйбер салып алып кайтып кара әле. Бу бик тә куркыныч эш иде. Лагерьда көн саен үлеп тордылар. Аларны "капут команда"сы аякларыннан бау белән бәйләп, лагерь читендәге зур чокырга илтеп ташлады. "Капут команда"сында эшләүчеләрнең тамаклары тук булды, чөнки үлгән кешеләрнең кием-салымын салдырып, юып саттылар. Шуның белән тамак туйдырдылар.

Бу лагерьда әсирләрнең бернинди исем-фамилиясе булмады. Ул чокырда кемнәр генә булмагандыр, аларның туганнары, балалары, ата-аналары үзләренең кадерлеләрен әле дә булса исән түгелме икән, дип, бәлкем, көтәләрдер дә. Әсирләрнең мәетләрен ташлый торган чокырлар үләт базларын хәтерләтә иде. Җил шул яктан искән чакта сасы ис аңкып торды.

Көннәр акрынлап көзгә таба авыша башлады, төннәрен салкын, явым-төшемнәр дә булгалый, без һаман да шушы ачык һавада хайваннар кебек ята идек. Терәлеп ышыкланыр әйбер дә юк иде. Иптәшләре булмаган ялгыз кешеләр шушы такыр җир өстендә эчке киемнән яки гимнастеркадан гына корышып, үлгән кешегә терәлеп ятарга да риза иде.

Октябрь ае җитте. Ниһаять, акрынлап лагерьдан әсирләрне чыгара башладылар. Лагерь читенә вакытлыча поезд юлы эшләделәр, вагоннарны лагерь кырыена кадәр китереп, шуларга әсирләрне төяп озатырга керештеләр. Көн артыннан көн узды, лагерьда халык акрынлап кими башлады. Кайда алып китәләрдер, анысын без белмибез, вагоннар килеп тора, аларны тутырып җибәрә торалар.

Лагерь тышына 50-60 чамасы кешене чыгарып тезәләр. Немес тәрҗемәчесе кәгазеннән укып, түбәндәгечә аера башлады: офицерлар, урыслар, хәрби заводта эшләгәннәр, "Катюша"да хезмәт иткәннәр, крәстиәннәр, эшчеләр, татарлар, чуашлар, марилар, мордвалар, удмуртлар, Урта Азия халыклары, Кавказдагы милләтләр. Гомумән, барлык азчылык милләтләрне аерып таркаталар һәм 60 кеше итеп төркемнәргә җыеп, читкә утырталар. Шәйхи абый белән Сабит абый крәстиәннәр төркеменә эләкте. Без Сөләйман абый белән заводта эшләүчеләр ягына киттек. Бәлкем, тыныч кына заводта эшкә урнашып булмасмы, дигән уй белән китү иде бу. Ә азчылык милләтләрне кире армиягә алалар икән, дигән имеш-мимеш сүзләр дә йөри иде. Безнең шуннан качуыбыз да булды бу.

Шулай итеп, заводта эшләүче булып, урыслар төркеме белән вагон көтеп утырабыз. Шунда Сөләйман абый миңа татарча эндәшеп куйды. Шул вакыт яндагы күрше урыс: "Менә монда татарлар качып утыра", – дип полицайга кычкырды. Полицай ике метрлы күсәген күтәреп, ажгырып, безне төркемнән куып чыгарды. Без йөгереп татарлар төркеменә киттек...

Поездда 13 тәүлек чамасы бардык. Ничек кирәк алай безне Германиягә, Мозбург дигән шәһәргә китереп җиткерделәр.

Бу лагерьда нинди генә илдән әсирләр юк. Германия кайсы ил белән сугышкан булса, барысыннан да әсирләр бар иде. "Шталаг VII – А" дигән лагерь иде бу. Лагерь территориясе бик чиста, бараклар типовой проект белән эшләнгән. Бәдрәфләр чиста, аерым кер юу урыннары бар. Баракларда өч катлы нарлар, вак кәгазь тутырылган матрацлар куелган. Баракның тирә-ягы чирәм белән әйләндереп алынган, юлларга вак таш җәелгән.

Әсирләрне стансага алып килгән вакытта, безнең арттан машиналар урамны юдырып, дезинфекцияләп бардылар. Шәһәр урамнары да бик чиста иде.

Лагерьга килү белән баракларга кертмәделәр, мунчага алып бардылар, барлык киемнәрне газ камерасына тапшырдык. Мунчадан чыккач икенче кием бирделәр, чиста, ләкин ямаулы, куе яшел төскә манылган киемнәр иде. Бик яхшы итеп санитария эшкәртүе уздырдылар, беттән арындык, яңа киемнәрне кигәч, тәннәр хәл алгандай булды.

Без әле карантин чорын уздыра идек. Шулай булса да, теләгән кешеләрне лагерь тирәсенә эшкә алып чыккаладылар. Лагерь эчендә агач колодка, салам чабата ясый торган цех бар иде. Мин шунда азрак эшләп алдым. Аякларыбызда үзебез эшләгән колодкалар иде. Ә салам чабаталарны немецләр постта аяк тыгып тору өчен файдаланганнар.

(Дәвамы бар).

* **Гәзит варианты.**

Сау бул, утлы корал!

Казанда милиция бүлекчәләренә корал китереп тапшыру дәвам итә. Үз теләге белән утлы корал тапшырган кешеләргә 1997 елда 60 млн. (иске акча белән) сум акча бирелгән. Соңгы вакытта гына Шәйдуллин дигән берәү милициягә РПД пулеметы китереп тапшырды. Воронов – танкка каршы ата торган кул гранатометы, ә Динмөхәммәтов бер тапкыр гына атышлы "Муха" гранатометы китереп бирде. Бу өч кешенең һәрберсе милиция бүлегеннән кесәсенә 1,5 млн. сум акча салып чыкты.

Милиция органнары үткән ел үзләре дә шактый корал җыйды. Алар кешеләрдән 330 төрле утлы корал, шул исәптән, 35 револьвер һәм пистолет, 205 ау мылтыгы, 26 обрез, 57 "самопал" тартып алды. Салкын корал да шактый җыелды: пычак һәм башка кадыйкисә торган коралларның саны 363кә җитте. 1998 ел башында инде 29 кеше утлы корал тапшырды. Аларга 2837 сум 98 тиен (яңача) акча бирелгән.

("ВК").

100 яшьлек әби кемгә кирәк?

Брест өлкәсе (Белоруссия) Столин районының бер авылында карак 1894 елда туган карчык өеннән 5 млн. белорус акчасы урлап чыккан. Карчыкның акчасына ия булгач, җинаятьче әбинең үзе белән дә "шаярып алырга" карар кыла. Һәм 103 яшьлек әбине көчли. Җинаятьченең эзенә төшәләр, кулга алалар. Ул 20 яшьлек, инде берике тапкыр төрмәдә утырып чыккан һәм беркайда да эшләмәүче шушы район кешесе була.

("М").

Киллерга да киллер табыла

Кырым республикасының Югары суды Керчь шәһәрендә яшәгән А.Плужникны 15 елга, аның өннесе А.Уманецны 14 елга ирегеннән мәхрүм итте. Болар Мәскәүгә килеп 3 кешене үтерәләр. Корбаннары – Казан җинаятьчел төркеменең ике әгъзасы һәм шуларның берсенең хатыны. Казан "авторитетлары" Плужник һәм Уманецны үлем җәзасына хөкем итәләр. Ләкин Мәскәү милициясе киллерларны үлемнән коткарып, суд эскәмиясенә утыртты.

("Коммерсант").

Өшегән "куян"

Бакудан Лондон аэропортына килеп төшкән "БОИНГ-767" самолетыннан (шасси люгыннан) "техник яктан тикшерү вакытында билетсыз сәяхәт итүче "куян"ның үле гәүдәсе табыла. Очу 7,5 мең чакрым биеклектә 5 сәгатьтән артык дәвам итә. Шасси кертеп ябыла торган люкта температура минус 50 градус була. "Куян" боз кисәгенә әйләнгән. Аның кем булуы, исеме, һөнәре турында полиция әлегә берни дә хәбәр итә алмый.

Хәйләкәр мәче

Лондон шәһәрендә яшәүче банк хезмәткәре Маргарет Чемберлен гаиләсе 10 ел элек мәчеле була. Бер-ике ел үтүгә Базиль исемле бу ата мәче (ул урамда да йөри) күзгә күренеп симерә башлый. Шул тирәдәге бер йортта яшәүче Линда Берриның да Том исемле ата мәчесе бар. Ул да, симереп, күтәрә алмаслык хәлгә килә. Ә бер көнне Базиль бер атна югалып тора да кайта. Бераздан Линда Берри мәчесе дә бер атнага югала. Ул да өенә кайта. Линда бу юлы мәче муенына "Том" дип язылган муенчак кидерә. Маргарет Чемберлен, мәчесе бер югалуыннан кайткач, аның муенындагы "Том" дип язылган каешны күреп ала. "Том"ның адресы да бар. Чемберлен Линданың фатирына мәчесен күтәреп килеп керә. Ике хатын хәйран калалар: Базиль дә, Том да шул хәйләкәр бер үк ата мәче икән ләбаса! Ике хуҗада да сыйланып йөреп шулай симергән икән ул! Базильнең хуҗабикәсе мәчесен Линдага калдыра.

Динозаврларны урлаганнар

Русия Дәүләт Думасы депутаты Юлий Рыбаков РФ Генпрокуроры Ю.Скуратовка запрос җибәрде. Анда Русия Фәннәр академиясенең Палеонтология институтыннан яңа акча белән 1 млн. доллар торган экспонатларны урлап, яшертен чит илгә чыгару турында сүз бара. Урланган экспонатлар арасында лабиринтодонт амфибияләренең 30га якын баш сөяге, 5 динозавр баш сөякләре, 6 мамонт теше, борынгы амфибияләр һәм рептилияләргә багышланган фәнни материаллар бар. Депутат бу экспонатларны эзләү һәм Русиягә кире кайтару хөстәрен күрүне таләп итә.

("Культура").

Эт консервы – ит консервына әйләнә

Уфа ит комбинаты, чит ил бизнесменнары ярдәмендә, җирле ит комбинаты калдык-постык ит кисәкләре, сеңер һ.б. нәрсәләрдән этләр өчен "Тобик-Бобик" консервы чыгара. Җирле "бөек комбинаторлар" шундук, халык аны-моны шәйләп алганчы, банкларга "Говядина тушеная" дигән ярлык ябыштырып, сатуга чыгаралар. Әлбәттә, комбинаторларның эзләренә төшәләр, кулга алалар. Ләкин ялган "говядина тушеная" консервлар инде сатылып беткән була.

("КП").

Тарас Бульба бурычы

Лас-Вегас (АКШ) шәһәре янында Көнбатыш Ральстон медицина Үзәге урнашкан. Күптән түгел Мәскәүгә, данлыклы Петровка, 38 (МУР) адресына шул медицина үзәгеннән хат килеп төшкән. Хатта андагы табиблар бер ай эчендә медицина үзәгенә 154 доллар 63 цент акча күчерергә тәкъдим итәләр. Баксаң, бер мут урыс кешесе боларда сәламәтлеген тикшерткән булган икән. Шунысы да кызык: үз сәламәтлеге турында үзәктән мәгълүмат алган урысның фамилиясе ... Тарас Бульба икән. Н.Гогольнең әсәрләрен укымаган америкалылар, әлбәттә, моннан бернинди мәкер көтмиләр, ә инде 1-2 атна үтеп тә, кассага акча кермәгәч, Мәскәү милиция органнарына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булалар, чөнки Америкада вәгъдәсез кешеләрдән бурычны полиция аша түләтәләр. Петровка, 38, әлбәттә, Тарас Бульба өчен бурыч түләргә җыенмый.

("МК")

Күгәрчен караклары

Мәскәү янындагы Муромцево авылында җинаятьчеләр бер пенсионер картның 19 күгәрченен, хуҗаның күз алдында капчыкка салып алып киткәннәр. Картны, үтерү белән янап, куркытып, болар өстәвенә, аның өеннән 3 иконасын да чәлдерәләр. Күгәрченнәр бик кыйммәтле булып, иске акча исәбеннән һәркайсы миллион сум тора икән. Җирле милициягә бу җинаять турындагы хәбәр берничә көннән соң гына барып җитә, чөнки Русия авылларының күбесендә телефон юк. Җинаятьчеләрне эзләү бара.

Дивар аша күрәләр

Америка галимнәре һәм белгечләре үзенчәлекле электрон "фонарь" уйлап тапканнар. Бу фонарь калын дивар аркылы "күрү" сәләтенә ия икән. Фонарь белән стена артында ниче кеше барлыгы һәм хәтта кешенең тын алуына кадәр күренеп тора икән.

Бу "фонарь" милиция һәм төрмә хезмәткәрләренә, разведчикларга гына түгел, табигый бәла-казалар, зилзиләр булганда, кешеләр хәрабәләр астында калган вакытта коткару командаларына да ярдәм итәчәк дип уйланыла.

Тоталитар сәясәт өстенлек иткән дәүләтләрдә бу коралның куллланылу даирәсе тагын да киңрәк булачак, билгеле.

("Радио-1").

Татар энциклопедиясе битләреннән

ӘСӘДУЛЛИН Илдус Шәукәт улы (1947 елда туган), архитектор, Татарстанның Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт комитеты рәисе (1991-95), Татарстанның атказанган архитекторы (1984), "Татгражданпроект" институты архитекторы, баш белгече (1972-75, 1976-86). Алабуга шәһәре баш архитекторы (1986-88). Аның проекты нигезендә "Татнефтепроводстрой" администрациясе бинасы, Казан шәһәрендә 47 торак, җәмәгать биналары төзелгән.

ӘСӘДУЛЛИН Ринат Сөләйман улы (1934 елда туган), генерал-майор (1982).

ӘСӘНБАЕВ Нәҗип (Николай Васильевич) (1921 елда туган), язучы. Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1977). Башкорт академия драма театры директоры (1963-65). Иҗаты: "Рәйсә" (1957), "Фәйзи" (1962), "Канат йәйгәндә" (1969) "Кызыл паша" (1982) пьесалары. С.Юлаев исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1983).

ӘСГАТЬ Мәҗит (Мәҗитов Әсгать Гариф улы) (1900-1946), драматург, режиссер һәм театр эшен оештыручы.

ӘСФӘНДИЯРОВА Шәхсәнәм Ибраһимбәк кызы (1926-96), актриса, Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты (1970, 1977), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1967).

ӘҮХӘДИЕВ Ильяс Вәкъкас улы (1904-68), дирижер, скрипкачы, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1939), Татарстанның халык артисты (1965), 1936-41, 1948 елдан Казан музыка мәктәбе директоры. Татар опера һәм балет театры дирижеры (1941-44) һәм 1948 елга кадәр директоры. Җ.Фәйзинең "Башмагым", У.Бҗибәковның "Аршин мал алан" музыкаль комедияләрен, Ф.Яруллинның "Шүрәле" балетын сәхнәләштерә.

ӘХИЯРОВА Резидә Зәки кызы (1956 елда туган), композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993). Иҗаты: "Моңлы сазым" симфоник поэмасы (1986), җырлар, романслар.

ӘХМӘД Хан – Кече Мөхәммәд улы (туган елы билгесез-1481), Олы Урда ханы (1465-81). 1472 елда Олы Урда алга китә һәм Бөек Литва кенәзлеге белән килешү төзи. Төркия белән дәүләтара мөнәсәбәт урнаштыра (1476). Урыс хәрби диңгез көчләренең Сарай әл-Җәдидне талавына каршы чыга (1472). Мәскәүгә салым түләтү таләп итеп һәм Иван IIIнең Урда кенәзлегенә таныклык алырга килүенә хәбәр җиткерү өчен вәкилләр җибәрә (1476). Урыс дәүләтенә һөҗүм итә (1480). Себер ханы Ибәк һәм Ногай морзалары Муса, Ямгурчий белән сугышта һәлак була.

ӘХМӘД Хуҗа әс Сараи (14 йөз), төрки-татар шагыйре. Иҗаты: шигырьләр, газәлләр (С.Сараи, аның шигырьләре "Гөлстан би төрки" җыентыгына кергән (1391).

ӘХМӘД Ясәви (Кол Хуҗа Әхмәд) XI йөз ахыры-1116), төрки шагыйрь, фәлсәфәче.

ӘХМӘДБӘК (XYIII йөз ахыры XIX йөз башы), шагыйрь. Иҗаты: "Мәҗмуга илаһи" (1905), "Әлвидагъ", "Вәйсел Карани".

ӘХМӘДИЕВ Илдар Каюм улы (1935 елда туган), нәкышче, график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985). "Азат хатын", "Чаян" журналлары баш рәссамы. Иҗаты: "Сабантуй– хезмәт бәйрәме" (1961), Г.Ибраһимовның "Тирән тамырлар" романына багышланган рәсемнәр (1962-64), "Туй" (1974), "Шагыйрь Г.Тукай" (1976), "Тәфтиләү" (1976).

Дүшәмбе

2 МАРТ

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан" информацион программасы.
17.55 Балалар өчен: "Тамчы".
18.10 "Эшмәкәрлек телевидениесе".
18.45, 20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. Гүзәл Мөхәммәтҗанова.
19.45 Яңалыклар.
20.00 "Л.Гумилев җире этносы". Мөселман суперэтносы тууы. 1 нче тапшыру.
20.35 "Әлли-бәлли-бәү".
21.00 "СТАРШАЯ СЕСТРА". (21.45 – Яңалыклар).
22.20 "Барыбыз өчен дә хоккей".

"ЭФИР"

6.00, 2.45 "Музыкага чикләр юк".
6.15 "Динле кешенең тантаналы тавышы".
6.45, 5.20 "Республика". Информацион-аналитик программа.
7.15 "Уян һәм җырла".
9.00 "ТЕЛОХРАНИТЕЛЬ".
10.50 Атна спорты.
11.30, 14.30 "ТСН-6".
11.50, 17.50 Яратсаң – кара.
12.10 "ОСП" студиясе.
12.55 И.Демидовның "Музыка күзәтүе".
13.55 "Тамаша залы".
14.40 "РАЗНЫЕ СУДЬБЫ".
16.30 Мультфильмнар.
17.00, 19.30, 22.00, 3.20 "Шәһәр". Информацион программа.
17.15 Даруханә.
17.35, 22.35, 1.00 Юл патруле.
18.00 Тегеләр Кемнәр.
18.55 Атна һәлакәтләре.
20.05 "ПОГОНЯ ЗА БРИЛЛИАНТАМИ".
21.40 Мультфильмнар.
22.55 "ЗОЛОТО ПАРТИИ".
0.45 Диск-канал.
1.15 Теледискотека.
3.00 Мультфильмнар.
3.50 Нәфис фильм.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә!"
9.15 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
10.00 "Могҗизалар кыры".
11.00 "Сәламәтлек".
11.30 "Бу көйне беләсеңме?"
12.00, 15.00, 18.00, 1.20 Яңалыклар.
12.15 "Бергә".
13.00 "КиВиН-98".
14.35 Футбол күзәтүе.
15.20 Мультсериал: "Розовая пантера".
15.45 "Марафон-15".
16.05 "Йолдызлар сәгате".
16.40 "НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ РОБИН ГУДА".
17.10 "16га кадәр һәм өлкәнрәкләр өчен..."
17.30 "Дөнья тирәли".
18.20 "РОКОВОЕ НАСЛЕДСТВО".
19.05 "Җавап тотар чак".
19.30 "Бу көйне беләсеңме?"
20.00 "Битлекле кеше".
20.45 "Тыныч йокы, нәниләр".
21.00 "Вакыт".
21.40 "ПОЛТЕРГЕЙСТ".
22.45 "Атаклы кешеләр тормышыннан" сериалында Т.Шмыга.
23.20 "ДВОРЯНСКОЕ ГНЕЗДО".

"РУСИЯ"

7.00 Мультфильм.
7.15 Уян.
7.30, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.30 Хәбәрләр.
8.00, 23.55 Кизү бүлеге.
8.15, 0.40 Почта аша әйберләр.
8.20 "Стронг" тәкъдим итә.
8.25 Хәтер өчен.
8.30 Акчалар.
8.45 Графоман.
8.55 Православие календаре.
9.00 "Аншлаг һәм Ко".
10.05 "САНТА-БАРБАРА".
11.35 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
12.35 Урмас Отт Нонна Мордюкова белән.
13.30 Яңа бишенче көпчәк.
14.35 "УСНУВШИЙ ПАССАЖИР".
16.00 "МАЛЕНЬКИЙ БРОДЯГА"
17.30 РТР почтасы.
18.00 Кроссворд.
18.30 "РЕБРО АДАМА".
20.30 "Нечкәлекләр".
20.45 "САНТА-БАРБАРА".
21.50 "ДА, ГОСПОДИН МИНИСТР".
22.20 "ПЕТЕРБУРГСКИЕ ТАЙНЫ".
0.10 Автошоу.

"КУЛЬТУРА"

8.05, 14.00, 0.00 Мәдәният яңалыклары.
8.20 "ВОЛШЕБНЫЙ ГОЛОС ДЖЕЛЬСОМИНО".
9.25 Видеофильм-эссе: "День рождения".
10.00, 12.00, 16.00, 18.00 Яңалыклар.
10.05 "Если бы знать!" МХАТның 100 еллыгына.
